# Казан утлары

1 январь 1968

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
КЫРЫК ҖИДЕНЧЕ ЕЛ ЧЫГА

1
ГЫЙНВАРЬ
1968

## Бу санда:

БӨЕК ЛЕНИН ТУРЫНДА
ДӨНЬЯ ШАГЫЙРЬЛӘРЕ

Лэнгстон Хьюз. Ленин турында баллада . . . . . . . . . . . . 3
Петрос Антеос. Канәфер чәчәкләре . 4
Уилтон Джон Браун. Ленинчы күрәшергә. . . . . . . . . . . . 4
Ясумаса Кисида. Ленин китаплары . 5

ПОВЕСТЬ, ХИКӘЯ, ШИГЫРЬЛӘР

Ә. Касыймов. Бир кулыңны, дустым! . 6
Н. Дәүли. Кеше турында монолог . . . 39
Р. Батуллин. Мираж. Хикәя . . . . . 43
С. Хәким. Эмблема. Белгәннәр тик тора. Шигырьләр . . . . . . . . . . 50
К. Фәсәхов. Үлем аша үлемсезлеккә. Шигырь . . . . . . . . . . . 51

МУСА ҖӘЛИЛ ЭЗЛӘРЕ БУЙЛАП

Р. Мостафин. Кичер, илем. Беренче очерк . . . . . . . . . . . . . 53

БЕЗНЕ ОКТЯБРЬ ҮСТЕРДЕ

И. Салахов. Давыллар, утлар аша. Очерк . . . . . . . . . . . . . 67
Ә. Хәмидуллин, В. Скоробогатов. Коммуна улы. Очерк . . . . . . . 76

ДУСЛАР ҖЫРЫ

М. Ногман. Караимнар янында . . . . 82
Җ. Камалетдин. Багдадтан сәлам. Шигырь . . . . . . . . . . . . . 86

ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ

Н. Юзиев. Музалар туганлыгы . . . . . 87

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫННАН МАТЕРИАЛЛАР

З. Максудова. Онытылган шагыйрьләребез . . . . . . . . . . . . . 96

Ф. БУРНАШНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Ф. Бурнаш. Яшь йөрәкләр. Либреттодан өзек. Хатлар . . . . . . . . . . 102

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

ХАЛКЫБЫЗНЫҢ БАТЫР УЛЛАРЫ

С. Алишев. Бәхтияр Канкаев . . . . . 109

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

М. Госманов. Мәрҗани турында берничә сүз. . . . . . . . . . . . 116
Җ. Фәйзи. Виртуоз мандолинчы . . . . 122
Г. Бакир. Язучы һәм педагог . . . . . 126

ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ

Х. Мәхмүтов. Яңа табышмаклар . . . 127

ТӨРЛЕСЕННӘН

Н. Хәкимуллин. Һиндстанга сәяхәт . . 130

БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ

Г. Латыйп. Балыкчылар җылым тарта. Үз дигәнен итә ул. Безнең урам чатында. Бала белән ата. Шигырьләр . . . . . 142
Яңа китаплар . . . . . . . . . . . . . 146

САТИРА ҺӘМ ЮМОР

Ш. Галиев. Әз-мәз мәзәк. Язучының көен дәфтәреннән . . . . . . . . . 148
Г. Мөхәммәтшин. Габделхәйнең бәхетсез көне. Хикәя . . . . . . . . . . 150
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . 156

*Редакциягә килгән кульъязмалар кире кайтарылмый*

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-68-21, бүлекләр — 2-39-52.
Хатләр өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63, Редакция «Казан утлары».*

*Лэнгстон Хьюз*

Негр шагыйре. АКШ

## Ленин турында баллада

Минем рус иптәшем, Ленин,
Син бит мәрмәр кабердә.
Дәвам ит зур көрәшеңне,
Табутың миңа бир дә.

Мин — Иван, иген игәмен,
Итекләрем балчыкта.
Өйрәт яңа көрәшләргә,
Уянып торып чык та.

Минем рус иптәшем, Ленин,
Син исән, син йөрәктә.
Табутыңа мин ятыйм да
Яңадан чык көрәшкә.

Мин — Чако, Африка улы,
Шикәр камышы кисәм.
Син нур сиптең безнең җиргә,
Син безнең белән, исән!

Минем рус иптәшем, Ленин,
Эшең өчен җан атам.
Син уян да көрәшкә дәш,
Ә кабереңә мин ятам.

Мин — Хуан, Куба эшчесе,
Көрәштә арып калмам.
Революция эше өчен
Җанымны да кызганмам.

Рус иптәшем, Ленин, сүзең
Яңгырый һәр якларда:
«Эшчеләр белән мин мәңге
Яшим алгы сафларда».

*Петрос Антеос*

Грек шагыйре

## Канәфер чәчәкләре

Кичке шәфәкъ яна. Әйдә, янсын,
Ул хаклы гел шулай янарга.
Ә кешеләр мавзолейга төшә
Тормыш язы тамырын табарга.

Алар белән бергә мин дә төшеп
Карыйм синең тыныч йөзеңә.
Әнә яшь кыз каушап, оялып кына
Кызыл чәчәк куя үзеңә.

Ә мин сиңа нәрсә калдырыйм соң?
Бакчам көеп беткән бүгенгә.
Җырлар туды — яшь балалар каны
Канәфердәй шытты күңелдә.

Борынгыдан бирле гел яшь халкым
Сине җырлый, сиңа очына:
Сагыш белән тулы йөрәк җырын
Ул канәфер чәчәкләре итеп
Суза синең аяк очыңа.
Кабул ит син, Ильич...

*Уилтон Джон Браун*

Австралия шагыйре

## Ленинча көрәшергә

Россиядә шундый урыннар бар,
Исең китеп кенә карарлык,
Безнең изге җирләребез, диеп,
Атап йөри халык аларны.

«Бу урында Ленин басып торган...»
«Бусы Ленин туган калабыз...»
«Бу — көрәштә утлар кичкән байрак,
Аның белән алга барабыз...»

Ленинградта большевиклар туган.
Ә Смольный — Ленин штабы.
Броневикка басып күргән Ленин
Көчле ракеталар очканын.

Россиянең башкаласы — Мәскәү,
Ә Мәскәүдә, Кремль янында,
Ленин йөргән чыршы арасында
Кешелекнең яңа таңында.

Россиядә шундый урыннар бар....
Чит-ят җирдән шулар янына
Иксез-чиксез тын бер ташкын булып
Хөрмәт белән халык агыла.

Ленин баскан җиргә бас та, туган,
Турист булып түгел, бүгеннән
Трибунамы, залмы, һәрбер җирне
Исеңдә тот бөтен күңелдән.

Ленин баскан изге җиргә басу —
Антың булып йөрсен йөрәктә!
Син Ленинча яшә,
Син Ленинча
Җиңүче бул бөек көрәштә!

*Ясумаса Кисида*

Япон шагыйре

## Ленин китаплары

Шәһәрләрдә, авыл җирләрендә,
Япониянең бистәләрендә
Ленин иҗат иткән бөек эшләр
Балкый китап киштәләрендә.
Кара урман, караңгы төн аша
Якты таңга юллар салганда
Китапларын аның ала халык,
Бәла-казалардан арыганда.
Гади японнарга зур дөньяны
Китаплары ача Ленинның;
Шомлы төннәр аша уттай янып
Хәбәр итә таңын илемнең.
Ышанабыз, һаман янып, балкып
Торган кояш безгә киләчәк,
Аның уты көмеш елга кебек
Яшәү көче, дәрте бирәчәк.
Шатлык тавышы,
Җанлы булып гөрләп
Ишетелә ирек җырында.
Кадерлебез Ленин!
Әйтче, бүген
Язасың син ниләр турында?
Әйе, Ильич, синең һәрбер сүзең
Җиңелмәс көч безнең көрәштә,
Мәңгелек ут кебек алга өндәп,
Янып балкый алар йөрәктә.
Туры юлга чыккан яшь көчләргә
Дәрт бирәләр кыю атларга,
Алар өмет, тормыш тамчылары
Өметләрен җуйган картларга.
Яхшы беләм: хак, ялкынлы сүзләр
Язасың син, Ильич, бүген дә,
Дошманнарның җанын тетрәтәсең,
Дәрт уятып безнең күңелдә.
Син тынычлык, бәхет, ирек өчен
Яндың, Ленин, көчле ялкында.
Йөрәкләрдә мәңге яшәрсең син,
Яшәрсең син япон халкында!

МӨХӘММӘТ САДРИ тәрҗемәләре.

*Эдуард Касыймов*

# БИР КУЛЫҢНЫ, ДУСТЫМ!..

*Повесть*

## «Чуртаннар йолдыз аулаганда...»

Тулай торак тәрәзәләрендә күренгән сирәк утлар сүнә бара, сүнә бара... Кызның кайнар сулышы егетнең йөзенә бәреләә:

— Керим инде мин, Әхсән. Вахтерша апа тагын ачуланыр... Тагын ишекне бикләп куюы бар...

Егет эндәшми, сөйгәненең татлы иреннәренә иелә...

Кала өстендә әкренләп тынлык урнашып килә. Тик таш урамнардан ара-тирә дөбер-шатыр чапкан трамвайлар һәм югарыда, сыек карангылыкта, тыгыз һаваны ярып-сызгырып үткән самолетлар гына зур калага тәмам йокымсырап китәргә ирек бирми кебек.

— Ашыкма инде! Әнә сезнең тәрәзәдә ут та сүнмәгән әле...

— Гөлсинә ул. Хәзер без икәү генә калдык бит. Мине көтә.

— Көтсен...— Нык буынлы таза бармаклар кызның куе һәм нәфис чәчләрен аралый. — Алайса, син риза? Ник дәшмисең? Их, нинди матур истәлек булыр иде! ВУЗ ишеген япкан соңгы көннәр... Идел буе, табигать кочагы... Ә һавасы, ә төне?!

— Иртәгә подъемныйларны бирүләре ихтимал.

— Бирсеннәр... Аны алгач, төштән соң яисә кичкырын китсәк тә ярый. Көймәнең җинелрәген сайлармын, элдертербез генә.

— Син анда кунып калырга дисең ич. Әллә ничек... Без бит әле...

— Их, җүләрем, чибәрем син минем! Нидән шүрлисең, я? Бүремени мин? — Егет кызны янәдән ныгытып күкрәгенә кыса, әмма тавышы нечектер калтыранып киткәндәй була. — Ярый, компания белән барыйк, алайса... Син Гөлсинәгә әйт, ә мин Робертны дәшермен... Бәлкем, шунда аларның борчаклары да пешә башлар.

— Света белән Борисны да дәшик. Светага үзем әйтермен.

— Ә мин Бориска.

Торак ишеген кемнеңдер шалт-шолт ачып-ябуына икесе дә сискәнеп куйды, һәм кыз, шундук егет кочагыннан ычкынып, ишеккә йөгерде.

— Иртәгә килерсең... Хуш, Әхсән!

— Сау бул, Әлбинә! Тыныч йокы!

Егет бер мәл тәрәзә яктысында калыккан таныш силуэтка кул изәп торды да, кинәт күңелен каплап алган өмет дулкыннарының рәхәтен тойган хәлдә, асфальтка шакы-шокы басып, җәйге төннең сыек карангысында кайтыр ягына юнәлде.

* * *

Идел битендә, Казаннан шактый түбәнрәк, әллә ни зур булмаган жыйнак-жыйнак кына берничә утрау бар. Куе тал куаклары басып алган һәм урыны-урыны белән яшел хәтфәле ачыклыклары булган бу утрауларда шимбә һәм ял көннәрендә палатка куярга жир таба алмый йөрисең. Ә атна арасында, тегенди көннәрдә сирәк-мирәк жәйләп ятучыларны искә алмаганда, кеше-кара күренми диярлек. Утраулар атна азагында булачак яуны көтеп, тын гына хәл җыеп яталар.

Казан тирәсендә Иделне аркылыга-буйга күп айкаган һәм аның иң әйбәт, иң матур төшләрен яхшы белгән Әхсән иптәшләрен нәкъ менә шул утрауларның берсенә — арада бүтәннәрдән купшы яшеллеге һәм киңлеге белән аерылып торганына — алып килде. Ләкин ул: «Без табигать кочагына чыккан кешеләр, безгә тын булсын!» — дип, көймәсен утрауның Волжка дип аталган аулак ягына борды.

Көймә комлы ярга килеп терәлгәндә, алдагы эскәмиядә утырып килгән Роберт, аягүрә басып, кулларын җәеп жибәрде дә:

— О, исәнме гүзәл хәзинәләр дөньясы! — дип, яшел утрауны сәламләде һәм ярга иң беренче булып сикереп төште.

Аның артыннан бүтәннәр сибелделәр.

Чыннан да, яр менә дигән иде: кызынам дисәң, комы эре, чиста, көн инде сүрәнләнеп килүенә карамастан, әле һаман кайнар, тик менә түбәнгә тәгәри башлаган кояш үзе генә ычкына алмыйча ниндидер вак болытларга эләгеп калган; коеныгра уйласаң, суы җылы, агымы талгын, житмәсә, тирәнлеге дә шәп күренә, инде учак ягып, чәй кайнатып алырга теләсәң, куак араларында коры-сарысы да бөтенләй үк юк түгел... Рәхәтлән!

Мондый чакта студент халкының малай-шалайдан аермасы юк диярлек... Әйе, шул тикле араны колак тондыргыч мотор тавышы астында, дулкыннарда тирбәлә-тирбәлә су өстеннән әлсерәп кил дә, жае чыккач, шул суның рәхәтен, күңел кытыклауларын үз тәнеңдә татып карама, имеш...

Бер минуттан яшьләр, дөньяларын онытып, су эчендә чыр-чу киләләр иде инде. Тик кырыйдарак Гөлсинә генә, калку күкрәген куллары белән каплап, тез тиңентен суга кергән көенчә басып калган: ул йөзә белми иде.

Роберт күзлеген салырга оныткан икән, ярга чыгып, аны бик иплэп киемнәре өстенә куйды да Гөлсинә янына килеп:

— Әйдәле, йөзәргә өйрәтим әле үзеңне! — диде.

Кыз беркадәр артка чигенеп, егетнең кабыргалары беленеп торган чандыр гәүдәсенә карап алды.

— Минеме? Соң мин бит балта кебек: төшәрмен дә китәрмен. Житмәсә, үзеңне дә өстерәрмен, батканыңны сизми дә калырсың...

— Батырмам, курыкма! Монда чоңгыл юк. Әйдәле!

Егет кызның кулларыннан эләктереп алмакчы гына булган иде, кыз житез тилпенеп, иһаһайлап, судан чабып чыгып китте. Роберт аны чак кына куа барды да, кинәт тукталып, кул селтәде һәм сикерә-чума тирәнгә керә башлады.

Тегеннән, эчкәредән, сап-сары башлы Борисның муенына асылынган Светлана, чәрелдәп:

— Гөлсинә дим! Гөлсинә! Я, ни кыланасың инде, пожалуйста... Тирәнгәрәк кер! — дип аваз салды.

Иптәшләре каршысында болай нәүмиз булып, мескен бер кыяфәттә йөрүе күңелле түгел иде, әлбәттә, Гөлсинә, ниһаять, эчке калтырануын басарга тырышып, әкренләп бил тиңентен генә керде дә чирканчык алды. Аннары, бераз вакыт аста куллары белән комны тырмаштырып, үзенчә йөзгәндәй итенеп тә рәт чыгара алмагач, аягына басып,

иптәшләренә кызыгып карап тора башлады. Ах, бу йөзә белмәүләре... Әнә бит аларга ничек күңелле! Хәер, Борис белән Светланага аның әллә ни исе китмәде: алар, ир белән хатын булгач, әдәп дигән нәрсә хакында артык хафаланмыйча, һаман да бер төштә уйный-шаярыша иде. Кызның күз карашы Әлбинә белән Әхсән ягыннан аерыла алмады. Бу икесе, колакка ишетелмәгән ниндидер музыка моңнарына буйсынгандай, бер төрле ип һәм ритм белән әле янәшә йөзеп китәләр, әле читләшәләр, аннан тагы кушылалар, кушылгач, бер-берсенә орынып, тибрәнеп торалар — кояш нурларында каралып янган иңбашлары күренгәли дә шатлыклы елмаешулары балкып куя... Ходаем, су балеты да була микән әллә?.. Ике арада, беркадәр эчкәрерәк, дуадак каз шикелле кемнәргә катышып китәргә белмичә, бер чалкан ятып, бер кире әйләнеп, үз алдына мыштым гына Роберт йөзеп йөри. Ул хәзер Гөлсинә ягына борылып карамый да... «Куарга тотынып та, куып житә белмәде, җебегән... Әллә йөрәге туң микән?»...

Ардылар, ахры. Әхсән белән Әлбинә сайрак җиргә чыгып бастылар. Икесе дә күкрәкләрен тутырып, авыр-авыр сулыйлар. Әхсәннең кабарып торган иңбашларында елык-елык кояш нурлары уйный... Роберт та боларга таба килә башлады. Ләкин Әлбинә аңа артык якынаерга юл куймыйча:

— Роберт, әйдә теге якка йөзеп чыгабыз, — дип каршысына йөзеп китте.

Әлбинәнең Идел буенда туып үскәнлеген әллә каян белеп була: әнә бит ул аккош кебек җиңелчә тибрәнгәләп, йомры беләкләрен суга ничек тигез һәм ыспай салып бара... Монда әллә ни киң түгел, чыгып та җитәрләр... Ах, бу йөзә белмәүләре...

Әхсән, киң, таза җилкәсе белән суны ярып, Гөлсинә янына килде. Елмаеп:

— Ник моңаеп калдың, чибәркәем? Кая, бераз өйрәтеп карыйм әле үзеңне, — диде.

Кызый кулларын егеткә сузып, әкрен генә:

— Өйрәт, — диде.

Бераз эчкәрәк кергәч, егет кызны таза кулларына күтәреп алды да шундый ук йомшак тавыш белән:

— Оho, җиңел генә икәнсең үзең, — дип пышылдады.

— Кая инде...

Гөлсинә үзе дә бик яхшы белә: гәүдәсе бераз гына юантыграк, сөякләре чак кына калынрак аның, шулай да ул үзенең буй-сынына бер генә дә зарланмый. Һәркемгә дә Әлбинә, Светалар шикелле тал чыбыгыдай сыгылма билле булырга димәгән ләбаса...

Чыннан да, егет кулында тирбәлгәндә, Гөлсинә үзен ничектер бик нык җиңеләеп, мамыктай булып калганлыгын хис итте. Бәлкем, ул үзе дә күбәләк кенәдер әле?.. Ах, нинди рәхәт суда тирбәлүләре: бер менәсең, бер төшәсең, куллар, аяклар белән этенгән буласың... Егетнең тыгыз, куәтле мускулларын тоюдан туган сәер ток күңелнең иң аулак почмакларына җитеп, сулышны кысардай булып, кытыклап куя... Их, нинди бәхетле бу Әлбинә: мыштым гына йөрсә дә, тапты бит үзенә егетнең асылын... Бер мәлне, әллә тирәндә аяклары җиргә тимәүдән куркып китте, әллә күңелендә бөтерелгән татлы хисләр өермәсеннән зиһене чуалып куйды, Гөлсинә, үзе дә сизмәстән, «Аh!» диеп, куллары белән егетнең муенын кочып, асылынды да калды...

Геолог егетләр палатка корырга да, коры-сары табып, учак дөрләтеп җибәрергә дә шомарып, остарып беткәннәр — куллары кулга йокмый. Яшел үләндә табын урыны әзерләү, учакка куярга бәрәңге әрчү кебек вак-төяк эшләр кызлар җилкәсенә төште. Кияүдә әле өч-дүрт

ай гына булуына карамастан, Светлана үзен бүтәннәрдән тәҗрибәлерәк дип исәпләде, ахры, монда җитәкчелекне үз өстенә алды. Ләкин Роберт:

— Чәйне үзем кайнатам... Геологлар чәен бер эчеп карагыз әле, — дип, тал куаклары арасына карлыган эзләргә кереп китте. Әмма бу матур утрауда карлыган дигән затлы нәрсәнең исе дә юк иде. Егетләр аптырап, югалып калмадылар. Роберт белән Борис көймәдә аръяктагы әрәмәлеккә чыгып, шуннан табып алып кайттылар.

* * *

Кояш баеп, күктәге сирәк болытлар куе алсу төсләрдә янып торган чагында, исемсез атауның түгәрәк аланчыгында мәҗлес кызып өлгергән иде инде.

Табын алдында да, артында да беркадәрле дирижерлык итү Светлана кулында булды. Бу өлгер һәм житез яшь хатында ире Борисны гына түгел, бүтәннәрне дә үзенә буйсындырып тыңлардай, кирәк чагында ягымлы-йомшак яисә үтенүле-назлы ишетелгән, инде бик кирәксә, мыскыллы-ронияле, хәтта зәһәр ачу белән чеметтереп, үтереп янгырый торган гаҗәеп тавыш бар. Бәлкем, шушы ягы белән ул кырыс һәм тупасрак холыклы Борисны сихерләп куйгандыр да?..

Сәйранга чыгучылар шәрап нәрсәләрен байтак кына алганнар иде. Әмма Светлана эчмәде диярлек. Иптәшләре нинди генә матур сүз әйтмәсеннәр, пластмассадан эшләнгән рюмкасына купшы иреннәрен тидереп кенә алгалады. Дөрес, Әхсәннең яшьлек һәм дуслык хакына әйткән бик матур, бик гайрәтле тостына кушылып, савытындагы алсу нәрсәне яртылаш бушатмыйча булдыра алмады. Хәер, бүтәннәр дә, шайтан коткысына артык бирелмичә, шәрап савытларын бушатудан тыелып тордылар. Бераз каннар кызып, кәеф күтәрелеп китсә, шул җитмәгәнмени?

Борисның гына олы гәүдәсенә сеңеп җитмәде, ахрысы, ул, бер ара каш җыерып, чәчен сыйпаштыргалап утырды да түзмичә:

— Сонгысы-азаккысы булмасын өчен, әйдәгез, бер күтәрик әле, дуслар! — дип өч йолдызлы шешәгә үрелде.

Әмма хатыны Света түземсез җанның җилкәсенә басып, кабынган чаткысын тиз сүндерде.

Ә Роберт табын артында авызын ерып көлемсерәп утырган җиреннән җәһәт кенә сикереп торды да, кайсыдыр шагыйрьнең сүзләрен исенә төшереп, кулларын җәеп җибәрде:

— Сыйламагыз мине шәрап белән:
Мин болай да инде исергән!..

Аннан ул учак җылысында парланып утырган чәйнекне алып, буш бокалларга хуш исле, куе көрән чәй агызып чыкты. Әлбинәнең савытына агызган чагында егет кызга күзлек аша ягымлы карап:

— Карлыганнар салган чәйләремнән
Карлыгандай күзләреңә нур керсен... —

дип такмаклап та алган булды.

Нишлисең, азрак башына китсә, гадәте шул инде аның, шигырь укырга яисә чыгар-чыкмас тавыш белән такмак әйтергә тотына.

Менә хәзер дә ул, иптәшләре хуш исле кайнар чәйне өф-өфләп эчеп утырган чагында, купшы тал куагы төбенә басып һәм кулында гитара булмаса да, куллары белән шул инструментта уйнагандай итеп, үзе генә белгән көйгә шаян җырларын сиптерә башлады. Ә үзенең, шайтан малайның, күз карашы һаман да Әлбинә ягында иде...

Сүнеп барган учак шәүләсендә Әлбинәнең энҗе тешләре елтырап куйды. Һәм бер мизгелгә тынып калган егетнең колагына кызның соклану аша әйткән җылы сүзләре ишетелде:

— Инде дә шәп җырларың, Роберт! Каян беләсең син аларны?

Укыган шигырьләренең яисә җырлаган шаян җырларының бик күбесен үзе чыгарганлыгын әйтә алмый, сер итеп саклый Роберт. Инде берәрсе, артык бәйләнеп, төпченә башласа, «оныттым инде, кемнәндер отып алган идем» ди, яисә исеме бик үк таныш булмаган шагыйрь иҗатын гына искә төшереп куя иде ул...

Тик менә Әлбинә сорагач кына... Ах, бу энҗе тешләр, озын керфекле, карлыган күзләр!.. Шулай да егетнең кемгә багышлап җырлар җырлавын ярып әйтергә кыюлыгы җитмәде, чибәр кызның соравына җавап итеп:

— Безнең авылда йорт саен бер җырчы, Әлбинәкәй, — дип балкып елмайды гына.

Аннары, җиргә ятып, шактый суына төшкән чәен бер-ике йотып карагач, кисәк күңеле тулып киткәнгәме, күптәннән инде йөрәк түрендә саклап йөрткән иң әйбәт, иң хисле шигырен күңел кошына атап сөйләү нияте белән башын күтәреп Әлбинә ягына күз салган иде, кыяфәтечырае шундук караңгыланды: «карлыгандай күзле» кызый кулын Әхсәннең җилкәсенә куеп, тегеңә татлы һәм рәхәт елмаюда балкып утыра иде. Роберт салкын чәен ничек эчеп бетергәнен сизми дә калды... Ул арада Әхсән җырны яратудан бигрәк, киң сулыш, калын тавыш белән җырлау өчен бик тә кулай булган «Бродяга»ны сузып җибәрде...

Аңа иң әүвәл Гөлсинәнең зеңгелдәве, аннан бүтәннәрнең тавышы килеп кушылды.

Җырларның очы-кырые булмас иде кебек, ләкин алар да бетте, һәм яр буенда сихри тынлык урнашты.

Нишләп шулай икән: учакта биешкән җитез һәм комсыз ялкын телләренә үрелеп, кешенең уйлары әллә кайларга китеп баралар икән.

— Ян учагым, ян, тик белеп ян: соңыннан без сине бик тә сагынып искә алырбыз, — диде Светлана, сихри тынлыкны бозып.

Аңа җавапка Гөлсинә авыр сулап куйды:

— Янса да белми шул ул: тагын бер айдан, тагын бер елдан кайда булырбыз, ни хәлдә булырбыз... Егетләрнең хәле шәбрәк: өчесе дә бер үк җиргә, бер үк Берләшмәгә китә. Әлмәтне зур кала диләр хәзер. Света, сиңа повезло...

— Әйттең сүз, — дип күзен агартты Света. — Берләшмә дигәч тә, аның трестлары әллә ни хәтле, ди әнә... Әлмәттә калдырырлар дисеңме?

— Шулай да... Нефть җирләре — гөрләп, кайнап торган җирләр инде ул... Ә без?

— Соң сез дә икәү бит: Әлбинә дә син... Бер үк районга китәсез ич. Баргач, егылып үтенсәгез, бәлкем икегезне бер мәктәпкә урнаштырырлар, — диде Борис, хатынын алай күләгәдә калдырырга теләмичә.

— Белмим, бер мәктәпкә ике рус теле укытучысының кирәк булуы бик шикле. Аның районы тагы: җәһәннәм тишегендә.

— Бүгенге заманның техникасы барында Татарстанда җәһәннәм тишекләре каян булсын, ди? Оптимист булыйк, дуслар. Шулай бит, Әлбинә? — Моны күтәренке тон, гайрәтле тавыш белән Әхсән әйтте.

— Әлбәттә, күңелләр якын булсын! — дип кушылды тегесе.

— Бик дөрес! Ә син ник дәшмисең, Роберт?

Светлананың бу соравына Роберт сискәнеп куйгандай булды. Әмма тиз генә җавап бирмичә, учактагы ялкын телләренә уйчанланып текәлеп торганнан соң гына, күзлек пыяласында якты шәүләләр чагылдырып, иптәшләренә берәм-берәм карап чыкты.

— Беләсезме, мин ни әйтмәкче булам, — диде ул, ниндидер серле пышылдау белән. — Менә без китәрбез, таралышырбыз. Тормыш шулай

куша. Әмма, Әлбинә әйтмешли, аралар якын булып калсын безнең... Хәбәрләшеп торыйк. Әйбәт эшләсәк, матур яшәсәк, бер-беребезнең бәхетенә куанышып, дигәндәй. Ә инде берәребез бәла-казага дучар булса яки анда бер төрле кайгы-хәсрәткә калса, шундук ана ярдәм куллары сузыйк, дим... Кайда булсак та, үзебез ни хәлдә торсак та... Мәслихәтме?

— Бик мәслихәт! — дип күтәреп алды Светлана.

— Менә бу тост булды бу, ичмасам! — диде Әхсән, Әлбинәнең иңбашыннан кысып.

— Алайса, алайса... — Роберт, башын боргалап, әйләнә-тирәсенә күз йөртеп чыкты. — Безнең бу вәгъдәгә әнә кызарып, янып калкыган ай шаһит булсын!.. Кем әйтмешли, тутырыйк бокалларны!

Барысының да күзләре Идел аръягыннан, офык читен алсу-сары төсләргә манчып, күтәрелеп килгән айга төбәлде...

* * *

Ай үзенекен итте: әкренләп алтынсу-сары төсен җуя барып, саф көмешкә әверелде һәм җир өстенең карасу-тонык пәрдәсен күтәреп, су битенә көмеш келәмнәрдән тар сукмаклар салды. Болай да йомшак, нәфис һавасы, күк гөмбәзендә сыек караңгылыкта җемелдәгән бихисап йолдызлары һәм куе үлән арасында берөзлексез сайрашкан талымсыз чикерткәләре белән күңелләрне ямьләндереп, оетып торган бу гаҗәеп җәйге төн күк җисеменең сихре белән тәмам әкиятләрдәге тылсым дөньясына охшап калды.

Әмма Светлана бүтәннәр күк төннең сихри кочагында алай озаклап иркәләнеп утырыр хәлдә түгел иде: иснәнә башлады, озынборыннардан зарланырга тотынды. Көндез күп йөреп арыган иде, күрәсең. Ә бәлкем аның йөрәге астында бөреләнеп, инде тибәргә әзерләнеп яткан икенче бер җанның әнкәсенә үзенең яши башлавы, үзенең беренче ихтыяҗлары хакында белгертүе генә булгандыр бу?

Ниһаять, түзмәде Светлана:

— Үлеп йокы килә... Әйдә, Борис, булмаса, кереп тыныйк без, — диде.

Борис авыр сулап көрсенеп кенә куйды.

Палатка эчендә аларның пыш-пыш сөйләшүләре тынар-тынмаста, Әхсән Әлбинәнең беләгеннән тотып, эчке бер дулкынлану белән:

— Ә без... ә без ни торабыз? Әйдәле, көймәдә бер йөртеп килим әле үзеңне. Мәңге онытылмаслык истәлек булсын әле, — дип пышылдады.

Әлбинә берсүзсез риза булды.

— Әйдә, киттек.

Алар, кулга-кул тотынышып, ярдан аска таба төшеп барганда, Гөлсинә: «Туктагыз, мин дә сезнең белән!» дип тилпенеп кычкырып җибәрүдән чак кына тыелып калды. Юк, ярамый... «Их, нинди бәхетле бу Әлбинә!..»

Яр читендә тукталып калган Гөлсинә янына Роберт та килеп басты. Егетнең күкрәген ялкын чорнап алган иде, һәм ул көймәгә утырышкан ике шәүләгә текәлгән көе, үзе дә сизмәстән, тырнак очын кимерә иде.

— Утырыйк, Роберт, — дип эндәште Гөлсинә басынкы гына. Алар йөреп кайткач, бәлкем без дә бер әйләнербез, ә?

— Ярый, утрау тирәсеннән бер әйләнербез, — дип сүзен кысып кына чыгарды егет.

— Ә ник бер генә?

— Бик теләсәң, ике тапкыр әйләнергә дә була...

Мотор гөрелтесе төнге тынлыкны ярып, көймә сыек караңгылыкта күздән югалганчы дәшмичә утырдылар.

— Бик ерак киттеләр, ахрысы: әнә мотор гөрелтесе чак кына ишетелә хәзер, — диде Гөлсинә, тавышында калтырау сиздереп. — Әхсәнне әйтәм әле: шундый шәп йөртә ул көймәне.

— Шомарып беткән инде...

Беркавым тын гына утыргач, сүзне янәдән кыз башлады:

— Мин әнә шул ай салган сукмактан теге якка йөгереп чыгып китәр идем, юк, әллә кайларга китәр идем. Тыным беткәнче...

— Япа-ялгызыңмы? Андый сәфәрдә әйбәт юлдаш та кирәк иң. Әмма синең юк шикелле ул...

— Ә синең бармы? — дип сорады кыз, үпкәли язып, һәм кинәт дорфа гына әйтеп салды: — Кызларның жылы куенын син үзең дә хыялыңда гына йөртәсең шул әле... Күрәм мин, сизәм мин...

— Тормышка ашмас хыял түгел... Ә хәзергә, хәзергә... ни көтә мине... — Роберт җиргә авып, беравык тыңлап яткандай булды. — Ишетәсеңме, ишетәсеңме? Җир-әнкәнең үзәккәе ничек ялкынланып, гөләп, шаулап тора? Ай-һай, зарыккан да соң!

— Америкада твист биегәннәрен ишеткәнсеңдер лә син!

— Кем ни белә, шуны әйтә инде... Әхсәннең дә телендә гел шул: твист та джаз!

— Билләһи, телеңә билчән чыккандыр синең, Роберт... Ярар, тик торганда әрепләшмик. Бар, Әхсәннең транзисторын көйләп җибәр булмаса. Алар кайтканчы, музыка тыңлыйк, ичмасам.

— Менә монысында алтын бәһасе торырдай сүз әйттең син, Гөлсинә!

Егет белән кыз арасында, икесен ике якка аерып торган стена булып, юк, һәркайсын аерым футлярга бикләп, транзистордан талгын музыка моңы агылды, һәм алар, әнә шул футлярларына томаланган хәлдә, төнге Идел өстендә көймәдә тибрәлгән бүтән җаннар турында татлы да, ачы да уйларга чумдылар...

* * *

Киң су өстендә ак, кызыл, сары, яшел төсләрдә йөзләгән утлар балкый. Аларның бер төрлесе, үзара серләшеп күз кысышкандай, бер янып, бер сүнеп тора, икенчеләре басынкы гүелдәгән, шыбырдаган тавышлар астында бертуктаусыз хәрәкәттә, каядыр — югарыга, түбәнгә таба — ашыга... Әнә шул калын, басынкы тавышлар һәм төрле төсләрдә балкыган утлар ягыннан, караңгылыктан бер төрле ип белән өнсез дулкыннар шуышып килеп, көймәне жай гына тирбәлдерә. Әллә шул ук яктан, әллә кара кучкылланып, күңелгә шом кертеп утырган урман-куаклы ярлар ягыннан салкынча дымлы һава бөркелеп, кисәк-кисәк тәнне калтыратып куя... Аның саен бер плащ астына поскан ике җанның гыйшык ялкыны көчәеп киткәндәй була һәм алар бер-берсенә тагын да ныграк елышалар...

Агым уңаена байтак төштеләр инде алар. Мотор күптән инде сүндерелгән. Ишкәкләр суда. Ә үзләре, дәшми-тынмый гына төнге Иделне күзәтеп, бер-берсенең сулышын тыңлап, кымшанмыйча утыра бирәләр...

Ниһаять, Әхсән алгы эскәмиягә күчеп утырды да каерып-каерып ишәргә тотынды. Каршыларында караңгылыктан олы кибән сыман карачкы калкып чыкты, һәм көймә борыны чыжылдап ул карачкыга килеп төртелде.

— Бик кечкенә генә, бик купшы гына утрау бу. Көндез күрсәң, күктән су өстенә төшкән яшел эшләпә кук... — диде егет, көймәдән ярга

төшкәч. — Әйдә, без аны синең исем белән атыйк, Әлбинә... Изге Әлбинә атавы... Русчасы бигрәк матур: остров святой Альбины. Шулай бит?

— Шулай... Әмма аның бу исемен без генә белербез ич... Ә бүтән кешеләр ничек дип йөртә?

— Бүтәннәргә иseме юк аның... Безнең утрау булыр бу. Без аңа һаман да килгәләрбез... Ел саен... Дөрес бит?

— Ие, җәй саен...

— Төш, акыллым... Үзебезнең атауда сызылып таңнар атканын күзәтеп утырыйк әле...

Кыз, күбәләк җиңеллеге белән егет кулларына кунып алгач, җиргә төште. Әхсән көймәдән плащ белән ниндидер төргәкне табып алды да кызны җитәкләп, бәләкәй утрау түбәсендәге тигезлеккә менде. Анда плащ җәеп, төргәген чишеп җибәрде, аннардан бер шешә белән ике бокал һәм конфет-печенье ише нәрсәләр чыкты.

— Бу ни хәл бу, Әхсән? — дип гаҗәпсенде кыз.

— Бумы? Икебезгә сый... Икәүдән-икәү генә тотыйк әле, вәгъдәләребезне ныгытыйк әле, дидем... Синең атауда... Синең өчен...

— Соң... соң... алай килешерме?.. Тегендә безне югалтканнардыр инде...

— Алармы? Исләренә дә китермиләрдер әле... Тот, әйдә...

«Бүген шулай кирәктер, шулай тиештер... Әхсән юкны уйлап чыгармас», дип, күңелендә куба башлаган каршылыгын басып, күнде, буйсынды кыз...

— Ярый, шулай булсын...

Әчкелтем-татлы шәраптан соң авызларына каптылармы-юкмы, бер мизгелдән егет кызны шашынып кочарга, үбәргә тотынды. Кызый аның таза, нык гәүдәсендә аңарчы булмаган ниндидер калтырану, хәрәкәтләрендә ниндидер ят нәрсәләр тоеп, ачынып ялынды:

— Әхсән, җаным, нишләвең бу? Без бит әле... Җибәр дим...

Битләрен кайнар сулыш өтеп алды.

— Бүгеннән башлап ир белән хатын булыйк, акыллым, җан кисәгем...

Шашкын, исерткеч хисләр өермәсендә үз сулышыннан тыны кысылып куйды, зиһене чуалып китте, хәтта кызның күз карашына күктә йөзгән көмеш айга тиклем тоныкланып калгандай күренде. Ә күк җисеме, чыннан да, бу минутта әкрен генә юка канатлы болыт артына посып бара иде...

* * *

Транзисторда музыка тынуга, Гөлсинә кинәт сискәнеп куйды. Аркасын корыган агач төбенә терәгән килеш ничектер оеп, йокымсырап киткән икән. О, инде таң беленеп килә... Кызның гәүдәсендәге өшү-калтырану тавышында да чагылып алды:

— Тегеләр һаман юкмы әле, Роберт?

— Юк, күренмиләр...

— Ай аллам... Транзисторы да тынчыкты, имгәк... Роберт, әллә шигырь укып күрсәтәсеңме?

— Транзисторның дублеры булып, бәлкем, җырлап җибәрергә кирәктер?

— Яратмыйсың син мине... Юк, хәтта дошман күрәсең...

— Бар, әнә битеңне-башыңны юып мен, акылыңа кил... Тик ни... чуртаннарны куркыта күрмә...

— Нинди чуртаннарны? Кайда?

Гөлсинә яр читендә аякларын салындырып утырган Роберт янына күчеп килде.

— Әнә терә... су эчендәге куак әйләнәсенә кара... Әллә ничә бугай алар... Әнә тагын чупылдатты...

— Вак балык аулый торганнардыр алар...

— Вак балык микән? Минемчә, йолдыз аулый алар...

— Йолдыз?

Кыз караңгы су өстендә бик тонык кына җемелдәгән бер йолдызга текәлде һәм, егетнең сүзен куәтләгәндәй, нәкъ шул минутта су яман бөтерелеп, чупылдап куйды — йолдыз юкка чыкты...

— Әнекәй генәм!

— Чүпләп бетерәләр инде, күп калмады инде... Кояш чыкканчы тырыша алар, аннары икенче караңгыга тикле тынып яталар...

— Хыялый кеше син, Роберт...

Елганың түбән ягыннан таныш гөрелте ишетелде. Гөлсинә, алтын таңкә тапкан кеше кебек, куанычын яшерә алмыйча:

— Югалган малларыбыз кайта инде, — дип кычкырып куйды.

Көймәдән төшеп, болар янына килгәч, Әхсән бик алҗыган кыяфәт белән терсәкләренә тикле көрән тапларга буялган кулларын алга сузды да:

— Мотор чыгымлап маташты. Тәмам теңкәгә тиде, нәгълэт... Бераз яктыра төшкәч кенә рәтләп булды, — дип зарланып алды.

— Ә мин сезне пароход астына эләкмәделәр микән дип куркып торган идем. Ярый инде исән-сау килгәч, — диде Гөлсинә, Әхсәнгә ягымлы карашын текәп, һәм Роберт ягына кул изәп күрсәтте. — Монда Роберт безнең акылыннан шашкан: төн караңгысында чуртаннар йолдыз аулый, ди...

Әхсән баскан җирендә катып калды:

— Йолдыз?.. С... с... сөйләр ул...

Ярга менеп килгәндә, Әлбинә, Робертка карамыйча-нитмичә, хәтта озын керфекләрен чак кына да селкетмичә, тын гына үтеп китте.

## «Нинди җилләр ташлады моны?..»

Авыл халкы ябырылып бәрәңге казый.

Тышта кояш, җиләс, рәхәт...

Бәрәңге әллә ни уңмады быел, әмма, аның каравы, җыяр өчен көннәре нинди!.. Идән астына коры керә, череп-нитеп әрәм булмас...

Тагын өч-дүрт сәгать актарынса, бәрәңге казуын бетереп тә куяр Рабига җиңгәгез. Юк, бу авыр эштән болай ансат кына котылырмын дип исенә дә китермәгән иде ул. Ярый инде теге кыз булышты. Укытучы башым, нечкә билем, нәзек сыйрагым дип өйдә көязләнеп-назланып ята белмәде, ничәмә көннәр буена мәктәптән кайтуына ук ябышып, җиңгәгез белән тиңләшеп бил бөкте, маңгаеннан кара тирләр агызды... Аның бит тегендиләре дә була... Болын кадәр бакчаңда япаялгызың нишләр идең?

Инеш аръягында, җиләс тынлыкны бозып, бала-чаганың чыр-чуы купты: мәктәптә дәресләр бетеп, кайтырга чыкканнар.

Рабига җиңги җир өстендә сибелеп, җилләп яткан сары һәм кызыл бәрәңгеләргә күз йөртеп алды да, кулларын алъяпкычына сөртә-сөртә, ашыгып өенә таба атлады. «Бүген соңлармын димәде. Кайтуына әзерләп куймый ярамас», дип күңеленнән сөйләнә-сөйләнә, сүнеп утырган самоварына җан кертте, учак астын көйрәтеп, казанга бәрәңге салып җибәрде. Аннары, корыга килешмәс дип, алгы яктагы өстәлгә кыярын, помидорын турап куйды, нәүрәпкә төшеп, каймак чүлмәген дә алып менәргә онытмады. Тамагына ризык булып үтсен...

Озак көтәргә туры килмәде, кайтты.

Үзе белән урамнан кояш нурларын ияртеп кергәндәй булды; матур, тигез тешләрен күрсәтеп, балкып елмайды да йомшак тавышы белән:

— Исән-сау гына тордыңмы, апа? — дип эндәште.

— Бик әйбәт әле.

Өстен-башын салгач, капрон оеклары белән буялы идәнгә жинел-жинел басып, түр якка үтте һәм сумкасыннан кочагы-кочагы белән дәфтәр, ике-өч китапны өстәлгә бушатты. «Бүген тагын төн ката утырасы икән», дигән көнелсез һәм кызганулы уй Рабига жингинең йөрәген яндырып үтте...

Чаршауны күтәреп, нигәдер урын-жиренә күз төшереп торды. Исәбе нидә икән моның? Караваты астыннан чемоданын чыгарып, аннан сарылы-кызыллы йон яулыгын алды. Бер мизгел стенадагы көзге каршында күз атып торгач, борылып, янәдән озын керфекләреннән нур сирпеп, ачык итеп елмаеп куйды.

Ишек янагына сөялгән хәлендә яулык очын авызына кабып торган Рабига жинги:

— Самовар да кайнап чыкты, бәрәнге дә кайнар... Әйдә, суытмыйк инде, Әлбинә кызым, — диде.

— Хәзер апа, хәзер...

Табын артында апа сорамыйча түзә алмады:

— Әллә бер-бер кая барырга жыенасыңмы?

— Әйе, апа. Тигәнәклегә барып кайтырга исәп.

— Нигә тагы? Кемнәр белән?

— Бу юлы үзем генә... Бер укучым ике көн инде дәрескә килмәде. Барып хәлләрен белеп кайтыйм әле, дим...

Рабига жинги сөтле чәен бер-ике йотып алгач, чынаяк тәлинкәсен өстәлгә куеп, бер мәл тын торды.

— Ә нигә, дәрескә килмәгән саен артыннан барырга димени?

Кыз ихтыярсыздан көлемсерәп:

— Алай димиләр дә бит. Аларны мин укытам ич. Класс житәкчеләре дә мин, — диде. — Өйдәге хәлләрен юньләп белмичә, ничек итеп әйбәт укытасың, ди?

— Соң теге атнаны гына Баярсаздан йөрөп кайттыгыз бит, алай бик ешламыйсыңмы, диюем... Былтыр миндә торган кыз ата-аналар жыелышына да көч-хәл белән генә барып кайткан иде.

— Ә ние бар аның? Көн коры, жылы, рәхәтләнеп йөре... Ә син апа, хафаланма: икәүләп тотынсак, бәрәнгене иртәдән калдырмабыз, актарып бетерербез.

Рабига жинги, каш-күз жимереп, кул селтәргә тотынды:

— Әйттең сүз! Инде бик күп булыштың, бик... Рәхмәтләр яусын! Бакчамда өстәл тиклем жир калган икән, аны инде үзем дә этмәлләп чыгармын. Инде бәрәнгене ташып та тормыйм: хөкүмәт жыя, ди, энә, хакын да әйбәт түли, ди. Бакчадан гына төяп озатырмын, дим. — Кисәк апаның тавышы йомшарды. — Ә син Тигәнәклегә барыр юлынны беләсеңме? Өйрәттеләрме?

— Беләм шикелле: олы урам белән чыгып, зиратны узгач та, уң кулга тауга менеп китәсе, ди.

— Әйе, Тегермән тавы... Өскә менгәч, каен посадкасы буйлап барасы. Ара ерак түгел, өчме-дүртме чакрым гына... Ипле йөр инде, юлларың уң булсын!

— Рәхмәт, апа...

Кыз, киенеп-төзәтенеп чыгып киткәч, Рабига жинги урам як тәрәзәдән аның артыннан карап калды. Бил турыннан кысып бәйләгәнгә күрә микән, карасу тимгелле яшел плащы астыннан да гәүдәсенең сылулыгы әллә каян беленеп тора. Атлаулары, жиргә басулары тагы! Шундый да жинел, шундый да ыспай — тыкрык чирәме өстеннән жәй

гына очып бара сыман... «Былтыргы җан көеге түгел бу... Юк, бөтенләй башка бу...»

Беркавым тын алырга ниятләп, баш астына мендәр салды да канәфигә сузылып ятты.

Менә бишенче елын инде, иреннән тол калгач, Рабига җиңги гомер сәгатьләрен шушы шактый ук искерә төшкән алты почмаклы өйне саклап уткәрә. Күңелләме картлык көнендә?

Үз гомерендә алты бала китерде ул. Өчесе бик яшьләй, әле дөнья яктысын, дөнья ямен юньләп танымас борын ук кара гүргә керде. Өчесен үстерде, кеше итте. Ире сугыштан бик таушалып, бик бетешеп кайткан иде һәм шуннан инде саулыкка туя да белмәде. Аңа рәнҗеп тә булмый, авыр туфраклары җиңел булсын инде мәрхүмкәйнең... Балалар үстерү хәсрәте бөтенләе белән Рабига җиңгинең үзендә булды. Колхоз эшендә йөреп, өй җылысын, кояш яктысын күрмәгән көннәрен кем санаган да кем белә? Йөрәгенә аз саугандырмы кан?.. Ә хәзер менә япа-ялгыз.

Ярый, кызы кияүдә. Аны, бер канатлангач, очырмыйча булмый. Бәхетенә, күрше авылга гына китте, ире белән тату гына, тигез генә тормыш кора белде. Олы малае, унынчыны бетергәч тә, училищега китеп, офицер булды. Хәзер Германиядә. Дошманнардан Ватан хакын саклый. Куанычы шул: ай саен хат салып тора, сирәк-мирәк акча җибәргәли, аннары ике елның берендә хатынын һәм үз ана телләреннән ләм-мим белмәүче, әмма русча, немецча шытырдатып сөйләшүче ике кызын ияртеп, дөнья хәтле күчтәнәчләр төяп кайтып төшә дә ярты ай кунак булып китә...

Рабига җиңгинең бар үпкәсе кече улы Вильданда. Төп нигездә калырга тиешле бу җан иясе: «Укытучы булам», — диде. Укыды, булды. Аз гына укыткан иде, армиягә китеп барды. Аннан былтыр кәөз өйләнеп тә кайтты. «Инде бер түбә астында гомер итәрбез», дип куанып торган чагында, анасының ялваруларын колагына да элмичә: «Монда физкультура укытып ятаргамы? Юк, мин үз фәнем математика белән физика укытачакмын», дип, районның җәһәннәм тишегендәге бер авылына китеп барды. Анда да озак тотмадылар юньсезне: чакыртып, «райком комсомол» итеп куйдылар... Китүе үз башына булган: артына ут капкан кук йөри менә хәзер район буйлата чабып... Кайтса, анасы яккан мунчага кереп чыгарга да вакыт табалмый... Жәл, бик җәл малай... Күршеләр әйтә: «Райком комсомол булгач, төшеп калмый инде ул, күрерсең менә, малаең зур түрә урынына утырыр», ди... Бик исе китте ди Рабига җиңгәгезнең... Алай түрә булырга бик кызыга икән, әнә мәктәп директоры сырхаудан котыла алмый, кайтсын да алмаштырсын... Өйләнеп тә җибәрсә, хатыны да укытучы булып, култыклашып кына эшләренә барырлар, култыклашып кына кайтырлар иде... Әллә үзенең дә җылы урынга үрмәлисе килә инде, бер кайтуында анасы пешергән бөккәннәрне бик тәмләп бөгеп утырганда: «Әни дим, Высший партийный школага китеп укысам, ничек булыр икән? Ике ел укыйсы, Мәскәү каласының үзендә...» дип сүз катып маташа... Үз оясын кора белмәс микәнни шулай итеп. Анасы ел тәүлегендә гелән-гелән фатир ачып, чит-ят кешеләр асрап ятар микәнни?

Хакы өчен түгел, җанга юлдаш, колакка адәм авазы ишетелеп торсын дип кенә кертә бит ул югыйсә...

Былтыр кергән кыздан уңмады ул. Сабагын ничек укыткандыр, ул хәтлесен тикшермәде, белмәде, әмма Рабига җиңги аны «җан көеге» дип атады. Әйләнеп чыккан ялкау, йокы чүлмәге булуы әле бер хәл, моның өстенә бик тә мут күзле, телчән, җиңел холыклы бер нәрсә иде. Бер мәл хәтта егетләр ияртеп кайта башлады... Иһаһай да миһаһай... Сирәк-мирәк Вильдан кайтып төшкән көннәрдә, ялгыш казага юлыга күрмәсен тагы дип, бик уяу булырга туры килгәләде аңа... Бәхеткә кар-

шы, җәйге ялга киткән җиреннән кире кайтмады ул кызый: кияүгә чыгып калган, диделәр...

Шул «җан көеге»ннән соң, Рабига җиңги «инде фатирга кертмәм, ялгыз башым, тыныч колагым, ничек тә яшәрмен әле» дип, күңеленә бик ныгытып куйган иде. Ләкин август урталарында мәктәп завучы Хөсәен килеп, гозерләп ялынгач, күнмичә булдыра алмады... Һәм үкенми дә менә; монысы, Әлбинә дигәннәре, ничектер бик тиз арада сихерләде дә куйды үзен...

Юк, теге «җан көеге» түгел бу: эш, ди, мәктәп, ди, балалар, ди, тормыш, ди... Юкса, бу да кала җиреннән бит, Идел буендагы Волжск каласыннан, ди... Әнисе китап кибетендә эшли икән, үги әтисе агач комбинатында, ди... Акыл бирә белгәннәр, рәхмәт төшкерләре... Күршекүләнгә тикле: «Бу ел киленнән уңдың син, җиңги... Тик малаең гына кайдадыр ыштан төбе туздырып, йоклап йөри», диләр... Ием, озак йөртмәсләр мондый җанны, иркендә озак тотмаслар, иясе тиз табылыр... Ах, Вильдан, Вильдан... Әллә авыруга сабышырга инде? Ул чакны ешрак кайтмыйча булдыра алмас иде... Чуртым булса да, «райком комсомол» булмасын икән лә адәм баласы!..

* * *

Тегермән тавы артык биек тә, текә дә түгел. Әмма кызуланып, ашыгып менгәнгә күрә, тау түбәсенә җиткәндә, Әлбинәнең йөрәге тамак төбенә килеп терәлгәндәй булды.

Түбәдә тын алырга туктамый чарасы калмады.

Якында гына кибеп саргаеп утырган алабуталар арасында, кайчандыр канатлары белән һава ярып, гөрләп гомер кичергән җил тегермәненең хәтирәсе булып нигез ташлары таралып ята, ә түбәндә, үзәнлектә, ул яшәячәк авыл...

Авыл матур гына, күңелгә ятышлы гына. Өйләр мул гына сулы инеш буена сибелгән. Инеш ярларында карт тирәкләр. Мәктәпне нишләптер нәкъ шул тирәкләр артына, инеш аръягына, чыгарып салганнар. Агач куелыгыннан аның яшел түбәсе чак-чак кына күренә... Элгәрерәк, язгы ташу котырганда, мәктәп юллары өзелә торган булган. Аптырагач-йөдәгәч, моннан берничә ел әүвәл кайсыныңдыр акыллы киңәшен тотып, ярдан-ярга асылмалы басма ясап куйганнар. Хәзер белем алырга, белем бирергә шуннан йөриләр... Әлбинә торган йортка якын гына ул: мәктәбенә биш минутта барып өлгерә... Әнә Рабига апасының тыкрык түрендә утырган өе Тегермән тавы түбәсеннән аермачык күренә икән: иске йорт, яңа капка, өч тәрәзәсендә дә кояш нурлары балкый...

Урамнарда җан иясе күренми диярлек. Бөтенесе бакчаларда. Инде байтак бакчалар актарылып, бушап та калган. Мондыйларда бозаулар, казлар чемченеп йөри.

Авылның аргы очында шифр түбәләре белән елтырап, җәелеп утырган ферма каралтылары артында, саргылт-яшел төстәге басуда нинди карачкы икән ул? Әнә кузгалып та китте... Ни дисә, кукуруз комбайны икән ләбаса... Болар да чәчкәннәр, үстергәннәр икән ул нәрсәкәйне... Тартмасына комбайн «чәйнәгән» яшькелт-сары азыкны түбәләмә төягән автомашина әнә, карачкыдан аерылып, фермага таба юл алды, аның каршысына тагы икенчесе, буш чаба... Көн корысында ашыга, кабалана халык...

Клуб тирәсендә дә кеше заты күренми. Ул кичке караңгыны көтә. Тик аның каршысындагы кибет нигезенә генә, сөяп куелган ала-кола капчыклар сыман, карт-коры сырышкан. Көн килсә, алар шунда инде: клуб маңгаена ябышып торган репродуктордан ни нәрсә агылыр икән дип, таяк очларын иякләренә терәгән халдә, кымшанмый-нитми оеп утыра бирәләр. Күкнең кояшы гына җылы булсын...

Юк, бу авылга эләгүенә үкенми Әлбинә. Матурын да матур, аннан килеп, халкы да әйбәт: тырыш, күндәм, сабыр... Электры-радиосы бар, киносы бар, алай бик үк иркен булмаса да, уңайлы гына мәктәбе бар... Калага да әллә ни ерак түгел — нибары егерме чакрымнар, олы юлга чыксаң, автобуста бер сәгать дигәндә барып житәсең...

Тукта, алар тыкрыгыннан иңенә зур букча аскан берәү бара түгелме? Почта кызы... Әйе, нәкъ үзе... Әнә алар капкасыннан кереп тә китте... Бу авылга килгәч тә, ничектер абайламый калды Әлбинә: кирәкле газета-журналларына тиешле вакытында языла белмәде. Ана тагын ике атна үткәч, октябрь числосыннан гына китерә башлаячаклар... Димәк, хат... Кемгә, кемнән? Әлбәттә, аңадыр, Әхсәннәндер... Бәлкем Рабига апасынадыр, Германиядәге улы жибәргән хаттыр? Юк-юк, Әлбинәгә булырга тиешле. Шул тиклем зарыгып көт тә...

Күкрәгендә кинәт купкан дулкыннар айкалуыннан кызның йөрәге Тегермән тавына менгәндәгедән дә атлыгыбрак тибәргә тотынды... Әллә кире борылыргамы? Ярамый, кеше көләр.

Әлбинә тау түбәсендә, сулышы кысылып, тагын беравык басып торды да кинәт кенә барыр юлына борылып, ашыгып каен посадкасы буеннан сузылган сукмак белән китте. Күңелендә купкан хисләр өермәсен таратырга теләп, жиргә каты-каты басып атлады ул.

Менә бер ай яши инде Әлбинә бу авылда. Шул арада ул Әхсәнгә ничәмә-ничә хат язып салды. Ә аңардан берәү генә килде. Әлмәткә барып урнашкач та язып жибәргән иде. Аннан соң өч атнага якын вакыт үтте бит инде... Хаты да нишләптер бик коры, бик кыска иде. «Берәр ят кеше кулына эләкмәгәе» дип шүрләгәндер, күрәсең... Аның хатыннан Әлбинәнең аңлаганы шул булды: Әхсәнне Берләшмәнең үзендә геология бүлегендә калдырганнар икән, ә Борис белән Робертны икесен дә бер калага жибәргәннәр, ләкин аларның эш урыннары төрле икән. Әлбәттә, Светлана да сөекле сөяге Бориска тагылып киткән, аның кайда эшләячәге әлегә билгеле түгел, ди... Аннары Әхсән эшнең бик күп булачагыннан зарланган: «Спорт дигәннәре монда бөтенләй тузып-таралып беткән, эт — баш, сыер — аяк, менә шуны рәткә салуны миңа йөкләделәр», дигән дә, Әлбинәнең хәл-әхвәлен сорашкач, эшендә уңыш теләп, азакка: «Кулыңны кысып, Әхсән», дип куйган. «Кулыңны кысып»... «Үбеп» тә түгел...

Чыннан да шулай уйлагандыр, хаты ят кешегә юлыгыр дип курыккандыр... Әлбинә үзен әнә шулай юатты. Бүтән төрле уйлар, «бәлкем, бәлкем»... дигән шөбһәле-караңгы тойгылар аңардан читтә йөрделәр... Ә бүген менә аңардан хат... Нилләр генә язды икән, ничек итеп язды икән?

...Тигәнәкле авылы бер уентык кына жиргә посып утыра булып чыкты. Авыл артыннан ук вак урманлык башланып китә. Өйләр бик сирәк, кырыктан артык түгелдер. Нишләптер монда яңа йортлар андасанда гына күренә. Күбесендә жил капка, искереп, каралып беткән салам түбәле каралты-кура... Әй, нигә шаккатты соң әле ул: бу бит башка колхоз, димәк, тормыш та монда бүтәнчә...

Аның классында Тигәнәкледән биш бала укый иде: икесе малай, өчесе кыз. Шулардан Мөнип Хәмзин дигән укучысы турында аңа: «Бавырыңа таш булып утырыр әле ул малай», дип алдан ук кисәтеп куйганнар иде. Усал, имеш, астыртын, имеш, кире, имеш... Ике атна укыту дәверендә Әлбинә алай ук куркыныч нәрсә сизенеп өлгермәде өлгерүен, әмма баштан ук үгезне мөгезеннән эләктереп алу яхшы... Тикмәгә ул малай бишенчедә икенче елына утырып калмаган, тикмәгә Әлбинәне коллегалары кисәтеп куймагандыр ич...

Авыл урамына кереп, беренче очраган йорт каршысында тукталып, эшен каян башларга, кемнән сорашырга белмичә аптырап торган чагында, күреп алды Әлбинә: якындагы коедан бәләкәй, әмма имән

төбе кебек тыгыз, юантык гәүдәле бер кызчык, көянтә-чиләгеп иңнәренә салып, аңа таба килә башлады. Якынрак килсә, ни күрсен: укырга аның классына йөрүче кыз бала.

— Һай, Фәйрүзә, акыллым, бу тиклем мөлдерәмә тутырмасаң, ярамый идемени? — диде Әлбинә, чын-чынлап хәйран калып.

Кызчык кисәк килгән җирендә туктады, беравык каушап, тотлыгып торды, аннары көчәнүдән бүртенгән йөзендә чак кына елмаю күренгәндәй булды.

— Ә мин өченче класстан ук ташыйм инде, апа...

— Ай-һай, ай-һай, — дип баш селкеде укытучы апасы. — Авырга килмәгәе дим... Ә сезнең өегез шушымыни?

— Ие...

— Өегездә кем бар соң?

— Мин үзем... Аннан соң бәбәй... Йоклый әле ул...

— Әтиең-әниең өйдә юкмыни?

— Юк. Әни басуга колхоз бәрәңгесен алмага киткән, әти тракторда җир сукалый бугай.

— Бүтән кешегез юкмыни?

— Әби бар. Ул кибеткә йомырка здавайт итәргә төшеп китте. Озак тормас, кайтыр инде.

— Ярый, акыллым, бар кер инде... Тик ни, моннан болай суыңны чиләкләрнең җиңелрәге белән ташы, я булмаса, шушы чиләкләреңә яртылаш кына салып ташы. Ишеттеңме, яме, акыллым? Икенче килүемдә мин сорашырмын...

— Ишеттем, я... Ә сез безгә кермисезмени?

— Керермен, акыллым, әбиең кайтсын инде...

Фәйрүзә, авыр кузгалып, җил капкадан кереп китте, ә укытучы апасы урам буйлап атлады. Кара, бу кызчыктан Мөнипләрнең өе кайсы икәнен сорарга да онытты бит әле ул. Әһә, урыс капкалы йорттан бер әби башы күренде. Әйтми калмас...

Тар, озын бакчаның урта бер төшендә күлмәк җиңнәрен терсәк тиңентен сызганган, таза, тыгыз гәүдәле хатын бер төсле ашкынулы гайрәт белән бәрәңге казый. Анардан бераз арткарак калып, тузгып яткан сабаклардан бер кыз белән бер малай бәрәңге чүпли. Әлбинә кычкырып исәнләшүгә, алар, өчесе дә башларын җирдән алып, бер мизгел хәрәкәтсез катып тордылар. Хатын кеше янәшәсендә һич уйламаганда пәйда булган яшь һәм чибәр киенгән кызга баштанаяк сөзеп карап алды, аннары кинәт кабаланып ачык изүен эләктерергә, маңгай өстендә таралып төшкән чәч бөртекләрен яулык астына кыстырырга тотынды, әмма үзенең резин ботылы аягы җиргә сеңдерелгән сәнәккә ныгытып баскан көйгә кала бирде.

— Исәнмесез!.. Кем дип әйтим микән инде? — диде ул, ачык елмаеп.

— Мин сезнең малаегызның укытучысы булам. Класс җитәкчесе... Эшегездән бүлгәнгә гафу итегез инде, хәлегезне белешим дигән идем.

— Шулаймыни? Бик шәп, бик әйбәт... Кичәгенәк малай бармаган иде шул, үзем җибәрмәгән идем: менә эш бит, эш... Сез шул хактадыр әле?

— Шулайрак... Тик ул өченче көнне дә мәктәпкә килмәде бит.

— Өченче көнне? Нишләп, букчасын асып чыгып киткән иде лә ул... Ах, малай актыгы, алдаган икән, тагын былтыргысын куа башлаган икән!.. Кил әле монда! — Хуҗа хатын зәһәр бер караш белән җирдә чүгәләп утырган малайга кадалды.

Кая ул килү! Малай җирдән күтәрелде дә әкренләп артка таба чигенә барды, чигенә барды, аннары капылт кына борылды да, ямаулы чалбар төбен елтыратып, бакча буйлап сыпыртты...

— Тукта! Тукта дим, иблис өшкергән нәрсә!

Мөнип җан-фәрманга чабуын гына белде. Ниһаять, түбән баштагы киртәгә җитеп, бер селтәнде дә күздән югалды. Анасы малае артыннан куарга бер ымсынып та караган иде, әмма моның файдасы булмасын шәйләп, ачу белән җиргә төкерде.

— Атасыз баланың шул инде! Кирәгенчә чыбыркы-каеш эләкми шайтанга... Ярый әле: монысы кыз булып туа белде.

Каршыларында нәүмиз бер кыяфәттә басып торган кызчыкның әнисенеке шикелле үк сирәк сипкелле йөзенә куе кызыллык йөгерде, керфекләре аска бөгелде.

Әлбинә аптыраштан ни диярге белмичә:

— Әтиләре белән ни булды соң? — дип сорап куйды.

— Алланың каргаган бәндәсе булып чыкты. Рисвай итте ул безне... Өченче елны ерак түгел бер урыс авылында кул эшенә ялланып эшләп яткан җирендә бер марҗага йортка кергән. Үзенекеләрне ташлап, ике бала өстенә. Ниенә кызыккандыр... Шул... Йорт-җирләрен сатып, Кустанай ягына шылганнар иде. Монда торырлык итмәгәннәр иде... Әмма бер азса, адәм баласына көн киләме соң? Тора-бара марҗасы да кемлеген күрсәткән, ахрысы, былтыр язлыкта кайтып төште бу. Кертмәдем мин аны. Авылда ике-өч ай буталып йөрде-йөрде дә, эчәрен эчеп бетергәч, тагын батты... Камчаткадамы, Сахалиндамы хәзер — шайтан белсен... Алименттан качып йөрүе инде...

Укытучы кыз тирән сулап куйды да бу нужалы хатынга теләктәшлек итү хисеннән:

— Шундый хәлдә калдырсын әле, бар бит бәндәләр, — диде.

— Ничава, сеңелем, кыен дип, алай кайгырмыйбыз, дөньяның кендеге аңарда түгел, билләһи... Тик менә малай гына... Былтыр әтисе хәсрәтеннән сабагын да юньләп укый алмады, утырган партасында утырып калды, үзем дә вакытында абайламаганмын... Ну, быел, ходай кушса дигәндәй, тезгеннән ычкындырмабыз... Һич югында тракторга утырырлыкмы, шофер булырлыкмы анда, гыйлем алдыртасы килә бит.

— Әлбәттә. Болай зиһенле генә, үткен генә малайга охшаган бит ул.

— Әйтәсе юк... Тырышса, барын булдыра. — Хатынның тавышында беркадәр горурлык хисләре сизелде, әмма ул авыр гына көрсенеп тә куйды: — Бөтен курыкканым, үскәч әтисе юлыннан китмәгәе дим...

— Китмәс... Сез аны гелән-гелән тиргәп, орышып кына тормыйча, кирәк чагында салпы ягына салам да кыстыра белсәгез, ул вакытта...

Әллә каян килгән берәүдән мондый нәсихәтне ишетергә теләмәде, ахры, хуҗа хатын каш җыерып, сәнәк сабын яңадан ныгытып кысып тотты да:

— Ярый, сеңелем, ул ягын ничек тә үзебез белербез инде, — дип кисте.

Авыл урамы белән атлаган чагында Әлбинә үзенең булдыксызлыгына, күп нәрсәне белмәвенә, хәтта тиешле тактны да саклый алмавына пошынып барды. Бәхетенә, бүтән өйләрдә, бүтән укучылар янында мондый хәлгә тап булмады. Киресенчә, аны һәр өйдә күптән көтелгән бер кунак рәвешендә каршы алдылар, ачылып һәм тәмләп сөйләштеләр, әйткән киңәшләренә, алтын сүзләр ишеткәндәй, бик хөрмәт белән колак салып тыңлап тордылар. Дөрес, крестьян тормышында бер кешенең кырыкка ярылган чагы, шунлыктан артык кинәеп китәргә, җәелеп киңәш-табыш итәргә уңайсызрак иде. Ул бүген нибары танышырга гына чыкты, һәм беренче уңышсызлыкның авыр тәэсирен соңрак ясаган күзәтүләренең матурлыгы, җылысы әкренләп эретә, юа барды.

Фәйрүзәнең әбисе укытучы кызны өстәл өстендә шаулап утырган самовары, «эсвәжи» балы, мае белән, аннан да бигрәк майдан да йомшаграк, балдан да татлырак теле белән каршы алды. Карчык «мөгаллимәләрне яшьли үк яратып килгән» икән, сүзне төенләндерми дә, кат-

лауланып китсә, чишми дә, үзе алган бер җайга, күңеленә ни килсә, шуның хакта агыла да утыра икән. Әлбинәгә тәки бер самовар чәен эчертеп бетерә язды. Өстәвенә, киткән чагында:

— Менә боларны тык әле... Суык тиеп, сырхауласаң-нитсәң, моннан да шифалысы булмас. Урманга барып, Фәйрүзәң белән икәү җыйган нәрсәләр, — дип, юмартланып, кура җиләге кагы белән кипкән юкә чәчәге төреп бирде.

Карчык кешене үпкәләтеп булмый, алмый нишлисең?

Инде кайтырга да бик вакыт: әнә кояш офык читенә кызылланып барып кунарга да тора... Өендә хат көтә... Ничек болай артык онытылып китте соң әле бу? Ә Мөнип Хәмзин белән ни хәл кылырга? Ул аны өркетте генә... Шул килеш калдырыргамы? Алайса, нигә дип килеп йөрде?.. Бакчаларында күренмиләр инде алар. Әнә калай моржаларыннан сыек зәңгәр төтен бөркелеп тора... Ә хат көтәр, көтелгән нәрсә тансык та, кадерле дә була, ди... Ләкин ни сәбәп белән барып керергә?..

...Авыр хезмәттән соң, кайнар булы бәрәңгегә ни җитә? Мөнип белән сеңелесе Мөхсинә уралар гына. Авыз эчләре артык кайнарланып, тыннары буыла-нитә башласа, кәҗә сөте белән генә йомшартып, юл ачып җибәрәләр. Әниләре бүгенге тырышлыклары, уңганлыклары өчен мактый-мактый сыйлый үзләрен. Хәтта Мөнипнең әнкәсеннән шүрләп качып китүен дә телгә алмый, ачуын бакчада калдырып кергән, ахрысы. Юк, онытмас, вакыты җиткәч, әйтер ул аны, җилгә җибәрмәс... Их, ник бу хәтле тәмле микән салкын сөт белән кайнар бәрәңге? Укытучы апалары беләме икән?

Табын артында дөньядагы иң тәмле ризыкны әнә шулай рәхәтләнеп ашап утырган чагында, кинәт кенә ишек шакылдатып һәм рөхсәт сорап, әлеге дә баягы яшел плащ кигән укытучы апасы килеп кермәсенме!.. Мөнип, бәрәңге кайнарлыгын да тоймас хәлдә, чәйнәвеннән шып тукталды, гүя аларның өенә ходайның әҗәл фәрештәсе үзе басып килеп кергән иде...

— Әйдүк, әйдүк! — дип, утырган җиреннән капылт кына кузгалды әнисе. — Баягынак дуамалланып өйгә чакырырга да башыма килмәгән... Менә бит тинтәк... Әйдә дим, әйдә, мактап йөрүләрең икән!

— Рәхмәт апа, мин әлерәк кенә өстәл артыннан чыккан идем. Фәйрүзәнең әбисе бер самовар чәен эчертеп бетерә язды. Мөнипкә бер йомышым бар иде, шуны гына әйтим дә...

— Әйтерсең, качмас! Ризыктан өстен булырга ярамый, — диде хуҗа хатын, укытучының беләгеннән тотып, һәм өстәл артыннан шыларга торган малаен, аяк тибеп, кире үз урнына кадаклап куйды: — Кузгалма дим! Укытучы апаң сине тотып ашамас, курыкма!

Нишләмәк кирәк, Әлбинә теләсә-теләмәсә дә өстәл кырына үтеп, табуреткага утырды.

— Инде хәзер йомышыңны әйтсәң дә була, — диде хуҗа хатын, бер төсле канәгатьләнү аша тавышын йомшартып.

— Йомыш дигәч тә, ул хәтле зурдан түгел ул... Безнең классның указкасы юк, шуны Мөнип ясап китермәсме дигән идем. Кулы андый эшкә ябыша ахры, сыерчык оялары да нинди матур, ничек бизәп ясаган... Ишек алдыгызда тагын әллә ниләр бар.

— Ие, кулыннан килә аның. Узган бер кеше хәйран кала. Ясап бирерсеңме, улым?

— Ясармын, — дип пышылдады малай һәм укытучы апасына ялт кына күз төшереп алды. — Ә нинди агачтан? Юкәдәнме?

— Юкәдән булса, бик әйбәт инде ул, — диде Әлбинә, ягымлы елмаеп, һәм, «Бу юлга указка да бик җиткән», дип уйлап куйды да, ризыктан авыз итеп алгач, — Кояш та баеп килә, юл кешесенең юлда

булуы хәерле, диләр, мин китим инде, — дип табын артыннан кузгалды.

— Иркенләп утыр дисәм, үзем дә ашыгам шул: бозауларым янына барасым бар. Бүген болай да соңга калынды, — диде хуҗа хатын, үзе дә кузгалып, аннары: — Көзге байлыкта тагын бер әйләнми калмассың әле, анысында, алла боерса дигәндәй, йөзгә кызыллык китермәбез инде, — дип каш сикертеп алды да улына төбәлде: — Мөнип, улым, эңгер-меңгер таралырга тора, әллә апаңны озатып куясыңмы? Җамай чокырын уздырып җибәргәнче генә, ә?

Үткен дә хатын икән. Әлбинә, тынын кысып, малайның ни җавап бирәсен көтеп торды. Теге әллә кирелеген җиңә алмыйча азаплана идеме, әллә бераз ялындырасы килә идеме, бер тын ара эндәшмичә утырды, аннары шунда түр эскәмиядә үк аунап яткан кепкасын җәһәт кенә башына киеп алды.

— Ярый, озатсам озатырмын...

Сүзчән малай түгел икән. Укытучы апасы ни рәвештән генә сүз катарга тырышып карамасын, Мөнип юлның юл буена: «Ә», «Ие», «Юк» дип кыска һәм өзек-өзек җаваплар биреп, кулындагы озын чыбыгы белән селтәнгәләп баруын гына белде. Әмма тар һәм текә сукмак белән Җамай чокыры аша үтеп, өскә менгәч, малайның теле ачылып китүенә сәбәп чыкты.

Әлбинә аңардан:

— Мөнип, син белми калмассың, бу чокырны нишләп шулай атадылар икән, ә? — дип сорап куйды.

— Монымы? — диде малай, кисәк кенә җанланып китеп. — Монда Җамай атлы бер комсомол абыйны колхоз төзегәндә үтереп ташлаганнар. Шуннан калган... Аның җыруы да бар...

— Җыруы?

— Ие... Безнең әни белә аны... Фәйрүзәнең әбисе тагын да тулырагын белә...

Бу хәлгә Әлбинә куанмыйча булдыра алмады. Серле бер мәгънә белән малайның сипкелле йөзенә текәлеп:

— Карале, акыллым, гаҗәеп бит бу, — диде һәм үз тавышында үзе үк табигый бер калтырану тойды. — Син ул җырны язып алсаң иде менә! Әлбәттә, тулырагын. Кемнәр үтергән, ни өчен үтергән, җырны кем чыгарган — бөтенесен дә язарга кирәк... Бәлкем, Фәйрүзә белән бергәләп тотынырсыз. Эшләрсеңме, булдырырсыңмы шуны?

— Булдырырмын... Ә нигә ул?

Мәктәпнең стена газетасына бирербез. Үзебезнең тарихны бүтәннәр дә белеп торсын. Бик кызык булыр ул, шулай бит?

— Ие... Ярый, апа, Фәйрүзәләргә мин бүген үк керермен, — дип ышандырды Мөнип, күрәнсу күзләрендә очкын елтыратып.

Бераз юл алгач, Әлбинә борылып беравык карап торды: Мөнип Җамай чокырын кичеп өлгергән, кичке эңгердә аның, баш өстендә озын чыбыгын болгый-болгый, авылына таба чапканы күренде. Хәер, Әлбинә, каен посадкасы буеннан сузылган сукмак белән атлаганда, үзе дә аякларының җиргә тигәнен тойдымы икән?..

...Рабига апа аны олы якка ут яндырып, сәер елмаеп каршы алды һәм гадәтенчә хәл-әхвәл сорашып та тормастан:

— Көн саен хат дия идең... Инде көткәнең килде. Куанычлы хәбәрләр булсын, — дип матур чәчәкле конверт сузды. — Кемнән икән?

Әлбинә, бөтен гәүдәсе буйлап рәхәт бер дулкын йөгерүен тойган хәлдә, конвертка күз йөртеп чыкты һәм кинәт тавышы сынып:

— Светадан... Иптәш кызымнан, — дип куйды.

Рабига апасы:

— Эһе, — диде һәм күңеленнән «Егет кешедән түгел икән» дип тынычланып, алгы якка үз эшләрен карарга чыгып китте.

Әхсәннән түгел... Хәер, дус кызы, кече күнелле Светлананың да хаты кадерле бит аңа. Әле килгәне юк иде.

Тормышларының әйбәт кенә башланып китүе турында язган, әмма мәктәптә балаларның тәртипсезлегеннән, дәреслекләр житмәвеннән зарланган, тагын әллә ниләр: сагыну-пошынулар, өметләр... «Икебез дә малай булса икән дип көтәбез», дигән. Тиздән ана була бит кеше... Хәтта Әлбинәне уйланырга мәжбүр иткән мондый юллар да бар иде: «Моннан дүрт-биш көн элек безнең шәһәрдә Әхсән булып киткән. Берләшмәдә калды бит ул. Ни йомыш белән килгәндер, белмим. Нишләптер безгә сугылмады. Аның белән очрашкан көнендә Борис ресто-раннан бик шәбәреп кайтып керде. Янәсе, очрашуларын юмыйча ярамаган... Ну, үзенә дә бирдем жарны... Әхсән шул көнне үк китеп барган. Эше ашыгыч булган, күрәсең...»

Әлбәттә, эше ашыгыч булгандыр. Юкса, аның якын дусты Светлана белән күрешмичә китәр идемени?.. Шулай юатты үзен Әлбинә...

Ләкин кичен дәфтәрләр тикшереп утырган чагында, бер мәлне ручкасын кызыл карага манчып алды да, ничектер онытылып, уйга калды. Әллә артык йончылган, әллә сагынып көтүләрдән талган иде, кисәк күнеленә «Бәлкем...» дигән шомлы уй кереп, бәгырен көйдереп үтте... Әле беренче тапкыр.

* * *

Бүген Әлбинәнең дүрт дәресе бар. Өченчесенә, грамматика дәресенә, ул һич уйламаганда, завуч Хөсәен Гарафеич килеп керде. Гадәтенчә, баштарак каушап китсә дә, Әлбинә үзен тиз кулга алды: дәресенә ныклап әзерләнеп килгән, житмәсә, бишенчедә элек өйрәнгәннәрен генә кабатлыйлар — бу юлы да сынатмас әле. Укучыларның өйгә бирелгән эшне ярыйсы гына үтәп килгәнлеген белгәч, ул тәмам тынычланып калды һәм, ара-тирә күз кырые белән генә завуч ягына күз салгалап, дәресне ипле генә дәвам иттерде.

Бу авылга килеп, укытучылар белән танышып чыккач та Әлбинәнең күнеленә иң ошаганы кәкре имән таякка таянып йөрүче, кырысрак чырайлы һәм нишләптер трубка гына тартучы завуч булды.

Танышкан чагында ук ул Әлбинәгә:

— Сеңелем, мин сине үз канатым астына алырмын, — дип кисәтеп куйды.

Яшереп тормады, шундук сәбәбен дә аңлатып бирде:

— Рус телен укытачаксың син. Ә ул безнең икенче ана телебез хәзер, ягъни якты дөньяга иң кирәкле ачкыч. Син моны миннән шәбрәк беләсеңдер... Ни өчен татар мәктәпләре берәм-берәм ябыла, кими бара? Ата-аналар балаларын рус мәктәбенә бирергә телиләр. Әллә татарлар үз ана телләрен, үз культураларын яратмыйлармы? Түгел! Һич алай түгел!.. Рус телен бик тә алама укытабыз, чиле-пешле халык чыгарабыз... Шуннан килә бөтен бәла. Татар кешесе үз баласының һәр яклап гыйлемле, һөнәрле булуын теләмимме? Бик тели... Техникумгамы, институтка-фәләнгәме янсә башка берәр жиргәме анда жырлап барып керсен, жырлап укысын, эшләсен, ди ул... Әйе, яшәсен безнең үз ана телебез, мең кат яшәсен милли мәктәпләребез, әмма ул мәктәпләрнең яшәвен теләсәк, халык бездә үз балаларын ышанып укытсын дисәк, без укучыларыбызга рус телен дә әйбәт укытып, якты дөньяга чын ачкыч тоттырып чыгарырга тиешлебез... Әйе, үзебез утырган ботакны үзебез үк кисмик инде, дим...

Моны ул мәктәп ишек алдында юан нарат бүрәнәсендә утырган жирендә таяк очы белән туфракны бораулап казый-казый әйтте, гүя миендә кайнаган нәрсәләрне жиреп үзеннән актарып ала иде...

Рус теле һәм әдәбияты дәресләренә көн саен ук булмаса да, көп аралаш кереп утыруларының тора-тора тагын бер сәбәбен төшенде Әлбинә: былтыр бу мәктәптә рус телен укыткан һәм җәен киткән жирендә кияүгә чыгып калган кыз нишләптер тапшырылган эшенә салкын карап, «җирне сай сөргән, чи калдырып сөргән, имеш»... «Бу елны да андый хәл кабатланмагае ди торганнардыр, шуңа күз-колак булырга тырышуларыдыр...» — дип уйлады Әлбинә.

Дәрес болай шома гына үтте кебек, һәрхәлдә, алай ябырылып бәйләнердәй нәрсә чыкмады шикелле... Тик менә өйгә биремне һаман да шул звонок шалтыраган чакта, ашыгыбрак аңлатып бирде. Төшенеп життеләр микән?.. Аннан тагы, астыртын, усал карашлы бер кызыйга, әйтеп утырганы өчен, шартлатып «икеле» куйды. Дөрес иттеме? Педагогикада укытучының ачуы исәпкә алынамы? Юк, боларны завуч кеше күрми калмас, сеңеренә сеңәрлек итеп төшендереп куяр...

Дәресләр бетеп, укытучылар бүлмәсе бушап калгач, Әлбинә түр почмакта өстәл артына сыенып утырган завуч янына килде һәм тавышында ваемсызлык, хәтта кырыслык сакларга тырышып:

— Хөсәен Гарафеич, дәресне тикшерәсезме? Вакытыгыз бармы? — дип текәлде.

Теге башын күтәреп, сыңар күзен чак кына кыса төшеп, карап куйды.

— Вакытым бар, әмма ләкин бүген тикшермибез...

— Нишләп?

— Ә нәрсәсен тикшерәсең? Үзегез сизмәдегезмени? Ярыйсы гына узды. Алай үтереп мактарлык түгел, үтереп хурларлык та түгел... Мин болай исәп иттем әле, сеңелем: ул класска мин кабатлау дәресләре беткәнче керәчәкмен, аннары бергәләп диктант яздырырбыз... Минем дә беләсе килә бит: чит авыллардан безнең бишенчегә нинди багажлар белән килделәр икән, алар белән нишләрбез, ниләр бирербез, ничек бирербез... Баш ватасы көннәребез алда әле безнең... Ә тикшерү дисәң, аны соңыннан кабатлау циклы беткәч, ясарбыз... Син ризамы, сеңелем?

Завучның кашлары гадәттәгечә җимерек, әмма зур соры күзләрендә җылы, ягымлы нур балкый.

— Ярый, алайса, шулай итәрбез...

Хөсәен Гарафеич сүз белән ботка пешерергә яратучылардан түгеллеген һәркем белә, әмма аның бүген әллә теле кычытып китте, әллә инде бу озын керфекле, ничектер моңсу карашлы, ләкин бик матур елмаючан яшь укытучы белән гәпләшүне гомумән ярата иде, кинәт кулы белән киң бер хәрәкәт ясап:

— Вакытың булса, утыр әле, бер сөйләшик әле, — диде һәм, кыз, плащы төсендәге үк кара бөрчекле яшел сумкасын тез өстенә куеп, каршысына утыргач, бөтенләй икенче яктан китереп сорау бирде: — Кичә Тигәнәкледән урап кайткансың икән. Соң, ничек, юлың уңдымы?

— Уңды шикелле...

Әлбинә артык киңәймичә һәм сузмыйча сөйләп чыккач, теге ягымлы елмаеп, ым какты:

— Кире әйләнеп, шәп иткәнсең... Мөнип син теләгән калыпка тиз генә кереп утыручылардан түгел. Шулай да өметсез димим мин аны... Соң, әйткән йомышыңны әле үтәдеме?

— Үтәде. Бүген указкасын алып та килде. Ә җырны Фәйрүзә белән икәү язып алганнар. — Аны мин бер тәнәфестә бөтен класска кычкырып укыдым... Бәлкем, бүтән авылларда да белүчеләр бардыр... Гаҗәп кызыклы җыр булып чыкты ул.

Хөсәен йөнтәс бармакларын өстәлдә биеткәләп алды, авыз читендә елмаю сызыклары хасил булды.

— Әйе, бик тә кызыклы. Ул җырны хәзерге буын балалар беләмени? Белми... Әлбәттә, мәктәп стена газетасына бирергә кирәк. Укысыннар. Бүгенге рәхәтнең тамырлары кая барып тоташканын күңел күзләре белән тагын бер күрсеннәр. Аннан килеп, ул канлы вакыйгага тиешенчә ачыкланып, җыры тулысынча кәгазьгә төшсә, бәлкем аны Казан фольклорчыларына да җибәреп карарбыз, ә?

Әлбинәнең йөзендә куаныч балкыды:

— Шулай итәрбез, Хөсәен абый!

— Җамай-комсомол кыш башланганда үтерелгән шикелле, — диде завуч, уйлана төшеп. Бәлкем, безгә шул канлы чокырга пионер дружинасының чаңгы походын оештыруны да күз алдында тотарга кирәктер? Анда, ачык һавада, юк, хәтта Тигәнәкленең үзенә барып, урамда халык алдында зур бер сбор үткәрү яхшы булмасмы?

— Бик күңелле үтәр иде ул. Уйлашыйк-киңәшик, — дип җуплады Әлбинә, завучның карап торырга вак кына күренердәй бер нәрсәдән әллә ниләр китереп чыгаруына гаҗәпләнеп.

— Дөрес, уйларлык, баш ватарлык нәрсә бу... Без «программирование» дибез, тегесен таләп итәбез, монысын гозерләп үтенәбез. Бүгенге заманда мәктәпнең кирәкмәгән нәрсәсе юк диярлек. Замана куша, бер кая китәр хәлең юк... Әмма шул ук вакытта үз канатыбыз астында булган бик күп нәрсәләрне онытып җибәрәбез. Ярыймы алай?

Әмма кыз, алсу иреннәрен түгәрәкләп, беравык дәшми торды да коңгырт күзләре белән Хөсәен абзасына текәлгән хәлдә, озын, нәзек бармакларын өстәл читенә тидергәләп бер-бер артлы тезеп алып китте...

«Программирование» сүзен ишетсә, шулай инде ул: перфокарталарны һәр укытучы да кулланырга тиешлеме? — тиешле, чөнки бик файдалы нәрсә; күргәзмә әсбапларның бик күп төрлесе кирәкме? — кирәк, чөнки аннсыз укыту сукыр тәкә уены гына була: мәктәпнең бердәнбер килделе-киттеле магнитофоны бар, ул гына җитәме, аның бер үзенә бераү кирәк, әле акча гына туплый алмый, билләһи, үзе алып куяр иде... Ә яңа программага яраклы дәреслекләр? Кайчан була, кайчан кайта? Нигә шулай итәләр микән: иң әүвәл программаны үзгәртәләр, мәктәпләрне сүтеп, яңача корырга тотыналар, аннан соң гына дәреслекләр, әсбаплар турында уйлый башлыйлар. Яңа капкалы, әмма почмакларыннан җилләр ыжгырып торган иске өйдә яшәве кемгә рәхәт? Безгәме, укучыларгамы?.. Миләрендә ни кайный икән ул министрларның, бүтәннәрнең... Тагын әллә ниләр, әллә ниләр...

Хөсәен кызганнан-кыза барган бу акыллы карашлы кызны бүлмәде, тик авыз читендә чак кына калыккан елмаюы әкренләп киңәя барды, киңәя барды... Кара син, ә! Юкса, күренеп торган чибәрлеге генә бар, кыяфәтеннән бер төсле дә дәрт-ялкын сизелми диярлек... Нинди җилләр ташлаган соң әле мондый тынгысыз җан иясен? Вакытыннан иртә сүнә-сүрелә генә күрмәсен, мәктәп өчен дә озын гомерле булсын...

Әлбинә әйтәсен әйтеп бетергәч, тирән сулап тынып калды. Хөсәен житди, уйчан төс саклап:

— Хак сүзгә җавап юк, диләр. Ләкин без «юрганыңа карап аягыңны суз» дигән сүзне дә онытмыйк инде, Әлбинә сеңелем! — диде. — Әкренләп барына да ирешербез, алай өметебезне кисмик әле...

— Ә мин кисмим дә...

Кыз кинәт озын керфекләрен сирпеп, завучка балаларча самимилек белән карап куйды. Аннары, тамак төбенә кунган төенен йотып, йомшак кына игеп эндәште:

— Хөсәен абый, сез мине иртәгә шәһәргә җибәрә алмас идегезме? Иртәгә минем ике генә сәгатем бар иде. Тик берсе соңгы дәрес. Аны алыштырып булмас иде микән?

— Ярый, барырсың, — диде завуч, өстәл пыяласы астындагы расписаниегә күз салып. — Ул сәгатькә мин үзем дә керә алам икән... Ә ни йомыш?

— Шул инде: сигезенчеләргә әдәбияттан укыр нәрсәләр таба алмаммы дим. Үзегез беләсез, эш бик хөрти бит. Анда методик кабинетта бераз ышандырганнар иде... Аннары врачка...

— Нигә? Әллә авырып киттеңме?

Кыз соңгысын ашыгып ялгыш ычкындырды, ахры, кисәк каушап калды:

— Юк... ни... әйе, нигәдер ашказаным борчый, врачка күренмичә булмый, — диде ул, ниһаять, һәм, зур, гафу ителмәслек ялган өстендә тотылган кеше кебек, чәч төпләренә тикле кайнар дулкын йөгергәнен тойды...

## «Ниләр генә итим, ни генә?..»

Шәһәр әллә ни зур түгел — борынгы өяз каласы. Ул салмак агымлы киң һәм мәһабәт елга ярына, сөзәк үр битенә сыенып утыра. Эре таш түшәлгән урамнардан, үрдәк бәбкәләре сыман ава-түнә, бәләкәй, сары автобуслар узгалый. Райком һәм кибетләр урнашкан үзәк мәйданда соры тузанга күмелгән газиклар, бүселгән артлы «Волга»лар жыелып, хәрәкәтсез тора... Әллә берәр киңәшмә микән? Йортларның күбесе иске, әүвәлге нык һәм эре кирпечләрдән салынган, әйбәт итеп акшарлаган матур кәрнизле бай сәүдәгәр өйләре. Ни гомер инде, жил-давылга, янгыр-явымга карамый чыдап утыралар. Тик кайберләренең төсләре генә ала-кола... Хатын-кызлар консультациясе шундый йортларның берсендә урнашкан икән. Әлбинә аны бер узды, ике узды, аннары тагын әйләнеп килде. Юк, күренмичә, тәгаен белмичә ярамый... Үз-үзеннән кача, яшерә алмый бит инде ул. Ә гәүдәсендә, тәнендә элек булмаган, тоелмаган сәер һәм үзгә билгеләр, торган саен ныграк һәм ачыграк сиздереп, күңелендә купкан хафаны көчәйтә бара иде... Инде ике айдан ашып китте бит... «Әхсән, Әхсән, нишләттең син мине, нишләттең?..»

Ниһаять, жинде үзен, кереп язылды, кулына талон тотып, тиргә батып, кире урамга чыкты. «Врач сезне сәгать икедә караячак», диделәр. Әле вакыт күп. Кыз агарынган, нәүмиз бер кыяфәт белән урам буйлап атлады. Кирәсе жирләрен уйларга тырышты. Ләкин юлы әллә ни унмады: методик кабинетта эшләүче апа аңа сигезенче класслар өчен рус әдәбиятыннан нибары өч дәреслек-хрестоматия таба алган икән, алары да хан заманыннан калып, тузып беткән китаплар. Шулай булмый ни, районда сигезенче класслар бихисап, яңа дәреслекләр юк, искеләренә дә зур кытлык. Ярый инде, болары өчен дә зур рәхмәт. Бәлкем, аңа Волжскидан әнисе бераз табып жибәрә алыр әле. Ә хәзергә, бу өчне дә кушсаң, класста дүрт балага бер китап булачак. Аңарга ярардай магнитофон да кибеткә кайтмаган икән әле. Сатучы егет:

— Бу айда булмас... Киләсе кварталда су юллары өзелгәнче контейнерлар кайтырга тиеш, — диде.

Су юлы өзелгәнче тагын айдан артык әле. Тик әйбәтрәге кайтсын гына иде...

Әлбинә вак кара бөрчекле яшел сумкасын селкеп, елга ярына килде. Монда сирәк сәрби агачлы кечкенә генә бакчада ду килеп бала-чага уйный. Көн кояшлы, жылы — аларга рәхәт. Аулаграк почмакта, елга ягына ачыграк урын табып, эскәмиягә утырды. Түбәндә күзләрне камаштырып киң елга көзгесе ялтырый. Ләкин салкын ул. Аръякта, жәйге ямьнәрен жуеп, сары-соры төскә кергән болын-тугайлар, әрәмәлекләр күңелдә авыр, моңсу хисләр кузгаталар. Тик елга битен берөзлексез

шадралатып чапкан җитез катерлар һәм салмак йөрешле ак теплоходлар гына җанны жылыта. Ә менә койрыгына тау-тау күбекле дулкыннар тагып, «Метеор» выжлатып үтте... Әнә шундый өлгер су кошына утырып кайта торган иде Әлбинә сөекле энисе янына. Волжск каласына... Сау-сәламәтме икән ул? Баш авыртуыннан әле һаман интегәме икән? Хатларында үзенең хәле турында ник бер сүз әйтсен. Кызымны хафага салмыйм әле ди торгандыр инде...

Еракта, кояш чыгышы ягында, зәңгәрсу урман. Офык артына китеп югала. Бер чите күе рәшәдә күк белән үк тоташкан кебек... Әнә шул урман артларында, бик-бик еракта, Татарстан нефтьчеләренең үзәк шәһәрендә аның Әхсәне... Хәзер нишли икән, кайда икән? Нигә хат язмый микән? Әллә бер-бер хәл булганмы үзенә? Юк, язгандыр инде, хаты юлдадыр...

Аларның якыннан танышып, сөешә башлауларына менә инде биш ай булды. Светлана белән Борис туена хәтле дә Әлбинә аны белә иде. Белмәскә, университетның атаклы волейболчысы иде бит ул Әхсән... Әлбинәләр институтының җыелма командасын бер мәлне ничек пыранзаран китереп, туздырып киттеләр алар. Әхсәннең уйнавына сокланмаган, гаҗәпләнмәгән кеше калмады. «Дошман» командасында уйнаса да, таза беләкле, җитез хәрәкәтле егет, һавага күтәрелеп, тупны каршы як мәйданга кадаклап куйган саен Әлбинә дуамалланып кул чабып утырган иде. Ул чакны уена да китермәгән иде аны үзенең сөйгән яры булыр дип... Бөтенесе Светлана туеннан, апрель уртасыннан, башланып китте...

Аерылышкан чакта Әлбинәнең рәсемен алды. «Кайткач, әни белән этигә күрсәтеп, бөтенесен дә сөйләп бирәм. Сине ошатмый калмаслар», дигән иде. Әтисе дә, әнисе дә — врачлар, Ижевск каласында танылган кешеләр, ди... Ошаттылармы, яраттылармы икән аны? Нигә шуны ачык итеп хат язмый соң ул? Ник җәфалый микән? «Хисләребезне сынашыйк», дигән иде ана Әлбинә теге «изге» утраугa барып әлеккәнгә кадәр үк... Әллә шул сүзне исенә төшергәнме? Әмма сынашып торырга соң бит инде. Ах, аллам...

Сәгать ике тулып киткән. Бармыйча ярамый... «Их, Әхсән җаным, бу сәгатьтә кояш сиңа да менә болай ягымлы карый торгандыр. Беләсенме-сизәсенме Әлбинәнең кая кергәнен?..»

Йөзе-кыяфәте әле яшь күренсә дә, чәчләренә сирәк бәс кунган хатын, гинеколог, Әлбинәне артык азапламады. Эшен бетереп өстәл янына утыргач, ваемсыз бер тавыш белән:

— Дөрес чамалагансыз... Ике айлык, — диде һәм төсе-кыяфәте агарынып-күгәренеп калган яшь хатынга сәер генә карап куйды.

Әлбинә, кинәт кызу ялкын капкандай, кызарынып озын керфекләрен түбән иде. Врач карточкадагы «незамужняя» дигән сүзгә янәдән күз салды да, авыр көрсенеп, әмма йомшаграк тавыш белән эндәште:

— Табасыңмы?.. Әллә?.. Мин сезгә табарга киңәш итәр идем. Беренче бала бит...

— Белмим...

Нурлы, якты бүлмәне кинәт караңгылык пәрдәсе басты...

Урам.

Урам кояшлы.

Урамда кешеләр...

Ә ул ана буласы кеше, ишетәсезме: АНА буласы!..

Тукта, бу икешәр катлы ала-кола йортлар ник биешә соң әле? Теге сары сыртлы авыр автобус килгән җирендә ник хәрәкәтсез калды? Ә нигә киң һәм талгын елга бер яссыланып, бер тараеп китеп елтырый? Күк йөзе тагы: әле зәңгәрсу иде, инде сорыланып өскә ябырылып төшәргә тора... Ие, ул бит ана булырга тиеш, кияүгә чыкмаган килеш, АНА булырга тиеш... Ә ул еракта, ул белми дә, көлми дә, сөенми дә,

көенми дә... Юк белергә тиеш!.. Иптәшенә-юлдашына кул сузып, аны ут эчендә ялгыз калдырмаска тиеш!.. Телеграмма сугаргамы? Әллә эшләгән җиренә бүген ук, менә хәзер ук шалтыратып хәбәр итәргәме? Сабыр, сабыр, сабыр... Хат кына языйк, чаң сукмыйк. Моннан салса, ике-өч көннән барып та җитәр. Инде укысын, белсен, елмайсын, сөенсен. Әлбинәсе кебек сыгылып төшмәсен... Универмаг чатында киоскада тулып пешкән алма битле, вак энҗе тешләрен елтыратып елмайган бер сабый сурәтен күреп үткән иде. Белмәде шул, аласы калган икән... Кайда соң әле боларның почталары? Кайда универмаг чаты?.. Бәхетенә, киоскадагы сабый сурәте исән: әлегә иясе табылмаган. Бак, күзләренә тикле ачык-зәңгәр — нәкъ Әхсәннеке төсле...

Хатны кыска язды. Шулай-шулай, диде, шатлансаң да, кайгыга бирелсәң дә, безнең кызлык-егетлек чагыбыз артта калган, диде, хәзер инде мин ана, син ата булачакбыз, тагын җиде ай көтәсе генә калды, диде. Ә чибәр бала сурәте төшерелгән открытка артына: «Безнең малай да шушындый булыр бит, иеме?» — дип язып куйды...

Почта залының бер почмагында торган сары герблы озынча ящик үзенең тар, караңгы авызыннан төпсез карынына йөзләгән, меңләгән адәмнәрнең шатлык һәм кайгыларын бертөзлексез сеңдереп утырган җансыз нәрсә — бүген, бу минутта тагын берәүнең зәңгәр конверт эченә яшерелгән шатлыгын-хафасын йотып алды...

* * *

Йокысыз, борчулы төннәрнең, сагышлы көннәрнең озынлыгын һәм авырлыгын кем үлчәгән?

Өрсә, кайнар сулышыннан дөнья йөзе кабынып китәр кебек иде.

Ләкин Әлбинә сынатырга теләмәде. Бар ихтыяр көчен җыеп, эчендәге ялкынның куәтен басарга тырышты. Әллә шуңа микән, тышкы кыяфәтендә бер төрле басынкылык, хәтта йомыклык билгеләре күренгәли башлады. Әмма моны да кешеләрдән яшерергә, сиздермәскә кирәк иде. Тәнәфесләрдә, буш дәресләре — «тәрәзәләре» булганда, ул укытучылар бүлмәсендә калмыйча, я класска укучылары янына кереп бутала, яисә тышка, саф һавага чыгып, мәктәп тирәләреннән, инеш буйларыннан әйләнеп кайта.

Ничек тә сабыр булырга, онытылырга, артык хафаланудан котылырга кирәк иде. Китапханәдән «Солдат Швейк» китабын табып алды. Бераз ярдәм иткәндәй булды. Кинода ешрак күренә башлады. Кызыклырак, күңеллерәк фильм булса гына барды, әлбәттә. Авырын карап, нигә чүп өстенә чүмәлә өстәргә?

Дәрес бирүләре авырайды. Дәфтәр тикшергәндә уйга бирелеп, төпсез караңгы упкыннарга чумуларны әйтәсе дә юк...

Сизенмәделәр түгел. Укытучылар Әлбинәнең тәрәзәдән тышка карап кисәк-кисәк уйга батканлыгын яисә төсен җуйган моңсу йөзен күреп алалар да:

— Ни уйга чумдың әле?

— Төсләрең калмаган, ни булды сиңа? — дип сорашып бәгыренә тиярләр.

Һаман ялганларга мәҗбүр, һаман кызу ялкын чәч төпләрен көйдереп ала.

Соң, ялганламый нишләсен ул? Килеп, ныклап торып эш күрсәтергә өлгермәде, авылда телгә керсенме, яман атын таратсынмы?

Ә нигә ата буласы кешенең хаты килми соң әле? «Килер, килер... Әхсән начар җаннардан түгел. Өметтән өзелмик»... Ә бәлкем түзмәс, үзе үк килеп төшәр, ара ерак димәс. Килеп төшәр дә, җәйге күк йөзе сыман ачык-зәңгәр күзләрендә шатлык нурлары балкытып, аңа яратып карар һәм таза, ныклы ышанычлы куллары белән аның иңбашыннан кысар... Ай, никадәр кирәк бу аңа хәзер!..

Ниһаять, килде.

Матур малай сурәте төшерелгән открытка салганнан соң ун көн тулгач килде.

Мәктәптән төш тирәсендә тамак ялгап алырга кайткан чагы иде. Вакыты бик тар иде: дәресләр бетүгә, барып класс җыелышы уздырасы бар иде.

Рабига апасы өйдә юк иде.

Почтальон кыз елмаеп, саубуллашып чыгып киткәч, матур роза чәчәге төшерелгән ак конвертка куанычлы карашын текәде: ниһаять... Калтыранган бармаклары белән кабаланып конвертны ертты, күзләре ашкынып зәңгәр сүзләр өстеннән йөгерде...

Тукта, ни бу? Өнме, әллә төшме?.. Гәүдәсен биләгән куанычлы тойгылар дулкыны кинәт юкка чыкты, йөрәгенә кайнар агулы хәнҗәр тыгып бутагандай тоелды — авыртуына чыдый алмый ыңгырашып куйды...

«Ни сөйлисең син, Әлбинә? — дигән. Нинди ата, нинди бала? Юк инде, шаярма син, дигән, уен эш түгел, дигән... Кем әйтте аны минеке дип? — дигән. Мин аны каян белим, дигән. Минем үземдә сиңа карата берни юк, ничектер барысы да таралды, тузды, бетте, дигән... Безнең арада нидер булган икән, шуның белән киселсен, бала-чага булмыйк, үз-үзебезне алдамыйк, күрәсең, сукмакларыбыз кушыла да, янәшә бара да алмас инде безнең, дигән. Турысын язганга үпкәләмә, мин гомумән алдауны яратмыйм, чыннан да араларны өзсәк, әйбәтрәк булыр, дигән...» Җитмәсә тагын: «Алдагы тормышыңда уныш телим, синең бәхетле булачагыңа ышанам», дип тә язып куйган...

О, адәм баласы...

Әлбинә, яшел тугайга ямь сибеп утырган хозур бер чәчкәне үткен чалгы кискән шикелле, түшәгенә барып сыгылып төште...

* * *

Класста егерме алты пар күз. Кызлар, малайлар... Күзләрдә нур бар, өмет бар, ышаныч бар... Әлбинә аларга иптәшлек, дуслык, татулык турында сөйләде. Аңнарына сеңдерә алдымы? Белмәде. Үссеннәр, беленнәр... Бәлкем, юньләп сөйли дә алмагандыр? Хәтерләми. Хәтеренә сеңгәне саби-сабыйларның үзенә текәлгән нурлы, ышанулы күзләре булды...

Инеш буе, тау битләре, вак артыш куаклары... Һава алмашыныр, ахры: баш өстеннән тузгып соры болытлар агыла, җил ачык изүдән плащ, күлмәк асларына үтә, ләкин Әлбинәнең кызган тәне аның салкынлыгын тоймый... Кичке караңгылык иңә башлады. Күк йөзендә болыт ертыклары арасыннан кәкре ай сыныгы күренгәләп куя. Тонык, ямьсез... Теге чакны, Иделдәге ялгыз утраудa да ул бар иде, ләкин тулы иде... Алдакчы ай, хыянәтче ай... Ана барыбер шул... «Изге Әлбинә атавы», имеш, «ир белән хатын булалар», имеш... Ә хәзер сукмаклары хәтта янәшә дә бара алмый икән. Димәк, аның теге чакны ук уе аны таптап, изеп китү генә булган. Хәзер кеме бар икән, кемгә сыланды микән? Ах, җир-анакай гынам, нигә күтәреп йөртәсең син шундый бәндәләреңне? Нигә, нигә, нигә?..

Инеш өстенә ярдан ярга салынган сыгылмалы тар басма. Сыгылмалы тар басмада сыгылып ла төшкән кыз. Түбәндә, яр төбен кимереп, ургылып-сугылып су ага. Ишелеп-убырылып төшкән яр да, авыртуга чыдый алмыйча, ыңгыраша кебек... Әлбинәнең дә күкрәгендә боз гына... Олы бер шагыйрь:

> Кайсыгызның кулы җылы? —
> Бәйлисе бар йөрәкне... —

дигән...

Кемгә барып сыенырга, кемгә бушанырга? Әнисе еракта. Якын булса да, ничек сыенасың: болай да авыру, сизенсә, тәмам акылын җуяр... Ә монда? Иң якын кешесе — завуч Хөсәен. Ләкин ир-атка ничек итеп андый нәрсәне чишеп саласың, ди?.. Ие, Гөлсинә бар бит әле. Каладан нибары ун чакрым гына укыта. РОНОда бер очрашкач, бик чакырган иде ул. «Бер иркенләп серләшербез, кил, яме!» дигән иде. Аңлар иде ул аны... Шулай да оят, оят, оят...

Әллә шушы караңгы яр арасында аккан кара сулы инешкә сыенырга-мы? Аның кеше күмелерлек чоңгыллары юк түгел шикелле... Тукта, ни уйлый соң ул? Әллә акылы җиңеләя инде... Әнисе нишләр, классын-дагы нурлы күзләр ни уйлар, дөньяда калган иптәшләре ни дияр?.. О, юк, юк, юк...

Өйдә тавык шулпасы исе таралган. Каладан Рабига апаның улы Вильдан кайткан икән. Апаның куанычы эченә сыймый. Әлбинәне дә көчләп табынга утыртты. Кыз тамагына ризык үтәрлек хәлдә түгел-леген сиздерәсе килмәде. Әйе, бераз вакытка гына булса да, белми торсыннар... Вильдан киң маңгайлы кара кучкыл егет, каш астыннан бораулап карый. Әмма тавышы йомшак. Йөри-йөри алҗыган, ахрысы. Әнә бит ул бу авылда да актарынып-казынып алырга өлгергән. Монда комсомол эшләренең таркау булуыннан зарланып та куйды һәм Әлби-нәгә сынаулы карашын текәгән килеш кинәт кенә:

— Укытучы яшьләрдән сездән дә уңай кеше юк, диләр. Үтереп мактыйлар. Чын. Әллә киләсе елга сайлап куябызмы үзегезне! — дип ярып сорады. — Ичмаса, бер тынычлап сулыш алыр идек.

Комсомол секретаре булырга? Ни сөйли бу кеше?

— Юк, юк, булмыйм, булдыра алмыйм, уйламагыз да... — Әлбинә тамак төбенә утырган төенне йота алмыйча азапланды. — Ичмаса, беренче елымда тимәгез, кагылмагыз миңа... Болай да, болай да...

Вильданның кичен чыгып йөрисе җире юк идеме, нишләптер өйдә утырып калды һәм квартирант кызны тегеләй дип, болай дип сөйләш-тергәләп алгач:

— Берәр партия шахмат уйнап алырга исәбегез юкмы, ә? — дип эндәште.

«Юк, дәфтәр тикшерәсем бар. Аннары башым да авыртып тора», дип, кыз егетнең тәкъдимен кире кагарга ният итте, әмма шундук, бәлкем, җиңеллек килер шуннан дип, ниятеннән баш тартып, егет кар-шысына утырды.

Вильданның элгәрерәк кайтуында бер уйнап караганнар иде инде алар. Анысында Әлбинә ярыйсы гына тартышып уйнаган, хәтта бер партиядә «ничья» ясауга ук ирешкән иде. Әмма бу юлы һич тә зиһенен туплый алмый.

Тегеннән, алгы яктан, ара-тирә аларга Рабига апа күз төшергәләп куя. «Бәлкем, шушыннан башлап китүләре булыр», дигән уйдан күңе-ленә рәхәт дулкыннар кереп тула аның...

Әлбинә берне оттырды, икене оттырды, өченчесен тагын... Табигый кимчелекләреме, нишләп кызлар егетләрдән гелән-гелән җиңелә дә, кызлар аларны ота алмый?..

Төн. Вильдан койка пружинасын шыгырдатып, йокыга китә алмыйча боргаланып ята. Сандык өстендә әнисе дә тирән-тирән сулап, ухылдап куйгалый. Аларны да ниндидер уйлар борчый, ахрысы. Ниһаять, икесе дә тынып, хәрәкәтсез калдылар... Чаршау артында Әлбинә ята. Аның да тавышы-ние юк. Ләкин аның күзеннән йокы качкан. Кыз, юеш мен-дәрен кочаклаган хәлендә ачынып:

—Ниләр генә иттим, ни генә?.. — дип күңеленнән һаман бер нәр-сәне кабатлый иде...

## «Буш җибәрмә, дустым!»

Гөлсинәнең куанычлы көне: бүген беренче хезмәт хакын алды ул. Беренче!..

Аны ничек бүләргә, ничек тотарга? Авылга әнисе белән әтисенә бүләк салырга кирәкме? — Кирәк. Казанда техникумда энесе укып ята, аңа җибәрергә кирәкме? — Кирәк. Ул чәүкә баласының авызына җим салырга тотынуы шуннан башланып китәр дә инде... Әйткән нәзере дә бар: туган авылындагы чыбык очы карендәше Мәһибәдәр әбисенә, әйбәт кенә җиргә эләгеп, әйбәт укыта башласа, берәр матуррак бүләк алып җибәрергә ниятләгән иде. Теләгәне тормышка ашты һәм ашып килә: барып төшкән җире каладан әллә ни еракта утырмаган бай гына совхоз, аның да үзәк усадьбасы, өр-яңа мәктәп, культурасы-ние тагы... Җиң сызганып тотынгач, укыту эшләрен дә матур гына башлап җибәрә алды. Кем белә, эше-тормышы шулай бер җайга салынып китсә, монда төпләнеп, гомерлеккә утырып калуы да бик ихтимал... Әйе, әйткән нәзеренне үтәмичә ярамый: картлык көнендә бер куанып дога кылсын әле Мәһибәдәр әбисе...

Аннан килеп, беренче хезмәт хакыннан ук үзенә килешле генә бер йон күлмәк алырга исәп иткән идеме? Аңардан да баш тартырга ярамый... Кибеткә әнә кыш өчен җылы аяк киемнәре кайткан, ди. Хәзер хәстәрен күрмәсәң, соңыннан үкереп җыласаң да таба алмассың.

Шулай бүлә-нитә торгач, алган акчасы нибары өч бөртек калганлыгын күрде Гөлсинә. Юкса, каерып ук алмаса да, кулына байтак кына кергән иде бит... Нишләмәк кирәк, акча хәле шулайрак инде ул... Ярар, монарчы сыналмаган, күнегелмәгән нәрсәсе түгел, бераз кысылыбрак кына торыр.

Гөлсинәгә дәресләрне шактый күп тактылар: ике алтынчы, бер җиденче һәм болар өстенә кечке мәктәпнең тугызынчы классына керә ул. Аз түгел, бигрәк тә рус теле һәм әдәбияты укытучысы булсаң... Кичке мәктәпнең унынчы классын да аңа бирмәкчеләр иде, ләкин ул, «болай да муеннан күмдегез, беренче елымда бик житкән» дип, дәресе, чыгарылыш классның җаваплылыгыннан куркып, аңардан баш тартты. Әмма соңыннан мона үкенеп тә куйгалый торган булды: бүтәннәр җиңгәнне ул җиңмәс идеме?

Беренче хезмәт хакларын бераз «юып алырга» да ниятләре юк түгел иде. Совхоз мәктәбендә, Гөлсинәдән кала, тагын ике кыз беренче елларын укытырга керешкән, шулар алдан ук җенләнеп куйганнар иде. Ләкин җылы уч төпләренә акча кергәч, борыннарына акча исе тигәч, теге ниятләрен әллә оныттылар, әллә ни, тоттылар да авылларына туганнары янына кайтып киттеләр. Кинәш-табыш итик дигәннәрдер инде... Бәхетләренә, авыллары якын, бәхетләренә, шимбә көне туры килде тагын...

Гөлсинә туган авылына кайтып киткән әнә шул кызларның берсе белән тора иде. Бүлмәне аларга совхоз үз барагыннан бушатып бирде. Бүлмәдәше Рая юлга чыгып китәр алдыннан ярым шаяртып, ярым житди итеп Гөлсинәгә: «Аулак өйдә каласың, жебеп ятма. Котдусың үпкәләрлек булмасын», дип мутланып, сәлам кыстырып маташкан булды. Теленә шайтан төкергән нәрсә. Гөлсинә, аулакта калдым дип, өенә егет чакырып ятсынмы? Коридордагы күршеләренең күзенә чалынып, телләренә керсәң... Юк-юк. Ә нигә куркырга? Үз фатиры, үз-үзенә хуҗа кеше ләбаса ул. Шулай да, шулай да... Егет кешенең үзенең дә әллә ни уйлавы бар...

Зиһенендә әнә шундыйрак уйлар чуалып, кибеттән кечтәнәчкә кирәк-ярак нәрсәләрен алып кайтып килгән чагында, Гөлсинә ерактан ук күреп алды: барак баскычы төбендә яшел плащлы, яшел сумкалы

бераү басып тора. Адымын шундук тизләтте: Әлбинә түгелме соң бу? Әйе, нәкъ үзе...

— Һай, нинди җилләр ташлады сине, Әлбинә җаныкаем? — дип, Гөлсинә, таза кочагына алып, кунакның җиңел гәүдәсен бөтерергә тотынды.

— Ара ерак түгел бит, хәлеңне белеп кайтыйм әле дидем... Үзең килмисең бит, — диде Әлбинә, шатлыклы елмаеп.

— Хыялымда тотам, Әлбинә, хыялымда... Котдус мотоциклына утыртып, бер җилтерәтеп алып кайтам әле мин сине шул яклардан дип ышандырган да иде... Көне генә менә бозылып китте, — дип Гөлсинә акланырга тотынды һәм шаһиткә чакырган шикелле соры болытларга күз йөртеп алды.

— Нинди Котдус?

— Котдусмы?.. Һай, нишләп катып торабыз соң әле без монда? Әйдә өйгә керик, әйдә! Шунда сөйләрмен барын да...

Гөлсинә, кунакны баракның икенче катына менгезеп, бәләкәй генә, әмма бик җыйнак, бик пөхтә күренгән бүлмәсенә алып керде. Ян-як стена буйларында ике койка, түрдә тәрәзә янындарак киң генә бер өстәл, берничә урындык, бер кием шкафы — бүтән җиһазлары юк та... Кая карама, өем-өем китап, дәфтәр...

— Шушында торып ятабыз инде. Безгә, ялгыз башларга, тагын ни җитмәгән? — диде Гөлсинә басынкы гына.

Бүлмәсенең бушрак, шәрәрәк булуыннан бераз уңайсызланды, ахры, ул.

— Бик шәп, бик әйбәт ич бу! — диде Әлбинә дусларча җылы һәм эчкерсез ягымлы тавыш белән.

Беравык шулай хәл-әхвәл белешкәч-ниткәч, хуҗа кыз, күрән күзләрен кыса төшеп, кунакка текәлде һәм ярым пышылдап кына эндәште:

— Әллә дим, аулакка кибеттән берәрне алып кайтабызмы? Безнең очрашу хөрмәтенә, беренче зарплата хөрмәтенә, ә? Кызылны гына...

— Зинһар, кыланмыйк әле, Гөлсинә. Күрәсем дә килми, хәтта элекләрен дә искә төшерәсем килми... Ансыз гына, яме!

— Ихтыярың — бәрәңге, дигәндәй, ярый алайсам.

Ишек янындарак кухня сыман бер почмаклары бар икән, Гөлсинә шунда кереп, ризык хәзерләргә кереште, ә кунак исә ишек яңагына сөялгән хәлдә, сынаулы карашы белән аңа текәлде.

— Әйе, Котдус дигән идең бит әле син, — диде Гөлсинә, урамда өзеп калдырган сүзен үзе үк исенә төшереп. — Кем дип аңлатыйм инде сиңа? Хәер, синнән нигә яшерергә, миңа муеннан гашыйк булган бер егет инде... Монда килеп төшүемә үк күз атарга тотынган иде. Былтыр армиядән кайткан, хәзер совхозда механик. Мактавым булмасын, техникадан белмәгән нәрсәсе юк, ди. Кеше шулай сөйли. Чибәрлеге, гәүдәсенең сылулыгы ягыннан да... Хәер, ни сөйлим, үзең күрерсең әле, кичен танцыда таныштырырмын мин сезне, яме? Тик ни... Кыюсызрак ул... Ә бер ачылып китсә!.. Бер мәлне шулай...

Тезеп алып китте, тезеп алып китте...

Гөлсинә сабакташ дусына хәтта шунысына тикле әйтте: Котдус чынчынлап өйләнергә исәп итә икән, өйләнеп, башлы-күзле булуга ирешсә, яңа өй салып, әти-әнисеннән башка чыгарга ниятли икән. Лесхозга барып, агачка заявка да ясап кайткан, ди. Өйләре шыңгырдап торган нарат бүрәнәләреннән булачак, ди... Гөлсинә боларны бер төсле ирония аша, күзләрендә шаян очкыннар сибеп сөйләде, ләкин аның йөргән егете белән чиксез канәгать булуы, чамасыз горурлануы тышка нурланып бөркелеп тора иде. Янәсе, дөньяда без дә төшеп калганнардан түгел, монда килеп, күрдеңме, үзебезгә нинди асыл егетләр таптык...

Әлбинә Казанда Әхсән белән йөргән чагында Гөлсинәнең аңардан үлеп көнләшкәнлеген сизгән, белгән иде. Хәзер менә кунакның хәл-

әхвәлен ныклап сорашмый-нитми авыз суларын корытып, тик үзе турында гына сөйләве, сөйгән ярын мактаулары аның әлгәреге хәлаттән өстен торганлыгын, хәтта, кирәк икән, хәзер аның үзеннән дә көнләшергә мөмкин икәнлеген күрсәтү өчен кебек тоела иде. Әлбинә бик хаклы рәвештә шулай уйлады һәм шул уеннан күңелендә: «Сөйләп бирсәм, аңлармы мине? Бер-бер киңәш бирә белерме?» дигән авыр шөбһә кузгалды...

Түзмәде, Гөлсинәнең сүз сөрешен икенче җайга борырга ниятләп:

— Ә эшләрең ничек соң? Мәктәбегез ничек? — дип сорап куйды.

— Эшме? Мәктәпме? Бәлмәгән, күрмәгән нәрсәбез түгел лә ул. Бара. Әйбәт бара. Тик җиденчеләре бик тә җәфалы класс икән. Ну, мин аларны шундук боргычларга тотындым. Аларга ирек күрсәтсә-ә-эң!..

— Ә дәреслекләр, кулланма әсбаплар ягы ничегрәк? Бик интекмисезме?

— Юк. Ә нишләп интегик, ди? Безнең директор бик уңган кеше бит. Аннан, мәктәбе дә күптәнге мәктәп, таза нигездә утыра...

Элек-электән үк яшәп килгән урта мәктәпләрдә хәл ничек тә җиңелрәк инде ул, ә менә Әлбинә укыткан мәктәпнең сигезьеллык булып оешуына да күпме генә вакыт, ди әле...

Ләкин Гөлсинәнең эш турында, мәктәп турында сүзне артык куертасы килмәде:

— Ярар, Әлбинә, бүген соң инде, әнә караңгыланып та килә. Иртәгә көн яктысында мәктәпкә дә сугылырбыз, барын да үз күзләрең белән күреп китәрсең, — диде дә: — Һава начар чакта туры килдең шул. Бәлкем, ачылып китәр әле. Ачылса, Идел буйларыннан бер дөнья гизеп кайтыр идек. Котдусның кулы астында теләсәң — мотоцикл, теләсәң — газик, җәйрәп утыр да кит, — дип сүз агымын янәдән үзе теләгән ярлар арасына борып җибәрде.

* * *

Танцы дигәннәре клуб фойесында, тәбәнәк түшәмле, стеналары кычкырып торган кызыл лозунг-плакатлар, төрле диаграммалар һәм сурәтләр белән чуарланган киң генә бер залда оештырыла икән. Чишенеп тормыйлар: урамда кем ничек йөрсә, шул хәлендә кереп бинсе килсә, бии, инде почмак-стена буйларына сыенып, авыз ачып карап торудан уздыра алмый икән, рәхим итеп карап тора. Соңгылары күбесенчә кылтай ир егетләр, мыек та чыкмаган әче телле яшүсмерләр. Арада чишенеп, аякларына махсус җиңел туфлиләр киеп алган берничә пар кыз әйләнсә дә, алар җыен карга арасына эләккән күгәрченнәр сыман, күренешне артык бизәмиләр иде.

Котдус шактый озак күренмәде. Гөлсинәнең борчылуы йөзенә үк чыкты. Танцыда әйләнгән чагында, нәзек кашларын җимереп, Әлбинәнең җилкәсе аша һаман-һаман ишек ягына күз салып ала.

— Килми калмас, килер. Тагын берәр кайда машиналары ватылгандыр, ахрысы, — дип пышылдады ул Әлбинәнең колагына һәм уфтанып: — Аның белән шул ягы кыен булыр да инде: көн димәс, төн димәс, машинадан төшмәс, — дип, егет белән әле кавышмаган булса да, булачак-туачак хафасын белгертеп куйды.

Ниһаять, Котдус күренде. Гөлсинә балкып китеп, Әлбинәне ишек ягына өстерәде. Гәүдәгә әллә ни калку булмаса да, калын күкрәкле, таза муенлы, ягымлы карашлы егет икән. Өстендә күк плащ, аягында керзовый итек, башына кыңгыр төшереп кепка кигән.

Әлбинә белән танышкан чагында, кара май сеңгән кулын шундук плащ кесәсенә тыгып куйды. Нигә уңайсызлангандыр, юкса тормышта таяну өчен нәкъ менә шундый кулларны кадерле, диләр түгелме?..

Әхсәннең дә куллары таза иде, көчле иде, волейбол уйнаганда аңардагы куәткә сокланмаган кеше калмый торган иде, ләкин аның куллары аксөяк иде, таяныр өчен түгел, уйнар өчен генә ярашкан куллар булып чыкты... Хәер, каян беләсең, бәлкем аның куллары да кемгәдер таяныч була алыр? Әмма Әлбинәгә түгел инде...

Гөлсинә белән Котдус яңа музыка тавышы яңгырауга биючеләр арасына кереп кысылдылар. Әлбинәгә ия чыкмады. Ул бер читтә япаялгыз басып калды. Котдус хәрәкәткә салмак икән, танцыда әйләнгәндә, сазга кереп баткан машина кебек, дерт-дерт селкенеп ала. Үзенең чырае ук сытылган. Танцыга ул бүтәннәр шикелле җаңга рәхәт, күңелгә хуш бер нәрсә итеп карамый, киресенчә, башына ирексездән эләккән бер җәфа итеп кабул иткән, ахры...

Залда дистәләгән, йөзләгән күз. Барысы да Әлбинәгә текәлгән сыман. Яндырып, бәгырен бораулап карыйлар... Гөлсинә аның кемлеген, каян килгәнлеген күпләргә әйтеп өлгергән инде, кайберләрен хәтта: «Урта бармактай егете бар, сезнең өчен өметсез ул», — дип кисәтеп тә куйган. Әлбинә боларны белми, тик берөзлексез үзенә таба очкын сипкән ут нокталарын гына күрә... Элегрәк, студент чагында, кичәләрдә шушындый хәлгә эләксә, үзен сәер, җиңел дулкыннарда тирбәлгәндәй хис кылып, күңеле татлы бер кытыклanudан бушанмый торган иде. Ә хәзер... Ах, кешеләрнең бораулы күзеннән дә яман нәрсә юк икән лә!..

Менә Әлбинәнең үзен дә танцыга дәшә башладылар. Кеше күзенә арпа кылчыгы күк кадалып торганчы, биючеләр арасында буталып йөрүең күп яхшы... Ләкин дәшкән егетләр артык такылдык, артык әрсезләр булып чыккангамы, Әлбинә алар белән әйләнүдән җанына рәхәт урынына өстәмә газап кына ала иде кебек.

Кунак — хуҗаның ишәге. Үз авылында булса, кайтып кына китәр иде. Гөлсинә белми шул аның хәлен. Әнә ул Котдусының иңбашына ике кулын куйган да, дөньясын онытып, тын гына, әкрен генә әйләнә. Ә күзләр һаман бораулый, һаман бораулый...

Әлбинәнең бәхетенә, озакка сузылмады бу газап. Әллә кунакның хәлен аңлап алдылар, әллә үзләре дә клубка очрашу-күрешү өчен генә киләләр иде, Гөлсинә белән Котдус аны урамга дәштеләр.

— Монда тузан эчендә буталганчы, саф һава сулаек, — диде Котдус, маңгай тирләрен сөртеп.

— Ие шул, — диде Әлбинә, җиңел сулап.

Урамда Котдус аларны култыклап алды. Егеттән бензин исе, машина мае исе, юл һәм тузан исләре килә. Канына, гәүдә-буыннарына хәтле сеңгән, ахрысы. Гөлсинә шуны гомер буена иснәп яшәячәк. Үзенә дә сеңәр...

Күктә тагын ай. Инде ул кәкре урак түгел, тулып килә. Җенләнеп агылган болыт сәләмәләре арасында гамьсез генә йөзә бирә...

Юллары кыска иде: барак баскычы төбенә хәзер кайтып җиттеләр. Тукталып, авызларын йомдылар. Котдус папиросына ут алды. Егетләрнең эшләре рәхәт: сүз чыкмаса, папирос төтәтәләр... Араларыннан җил дулкыны аргылып үтте... Әлбинә, иңбашларын тартыштырып, калтыранып куйды.

— Булмаса, керим мин, Гөлсинә. Нишләптер туңам, — диде ул сыныk тавыш белән.

— Туңарсың да шул. Бу суыкта, бу кадәр юка плащ киеп чыгамы кеше? Пальтоң булмаса, бер хәл иде, — дип дусларча тиргәп алды аны Гөлсинә һәм бүлмә ачкычын сузды. — Мә, кер инде алайсам... Кер дә плитәгә чәйнекне куеп җибәр. Чәй эчәрбез. Мин озакламам.

Гөлсинә кайтып кергәндә чәйнек әллә кайчан кайнап чыккан, ул хәтта сызгыруыннан да туктаган, ә кунагы исә өстәл артында бер кулына таянган хәлендә йөзен тәрәзәгә таба борып тын гына утыра.

Өстәлдә ачып куелган китап ята, ә тышта тәрәзә артында җил ыжгыра...

— Әлбинә!

«Әллә шул килеш йоклап киткән инде, ходаем?» Гөлсинә пальтосын ишек катындагы чөйгә элгән арада Әлбинә кымшанып куйгандай булды.

— Әлбинә дим, я ничек, Котдусны ошаттыңмы?

Әлбинәнең сулыгып пышылдавы ишетелде:

— Ошаттым... Әйбәт егет.

«Тукта, ходаем, ни булган моңа?» Гөлсинә, түргә үтеп, кунакка текәлеп карады. Ни күрсен, тегенең күз төпләрендә мөлдер-мөлдер яшь...

— Һай җаным, нишләдең син, ни булды?

— Эшләмәдем, — кулъяулыгы белән кызарынган күз төпләрен сөр-теп алды да өстәлгә капланды.

— Миңа сиңа кирәк булса!.. Ник дәшмисең?

Гөлсинә өстәлдә яткан көрән тышлы китапны шундук танып алды: Һади Такташ җыентыгы. Тукта, ачылган битендә ни икән? «Мәхәббәт тәүбәсе»... Гөлсинәгә кызык булып тоелды:

— Студент чакны исеңә төшердеңмени?.. Шәп укый торган идең шул син Такташ шигырьләрен... Такташ кичәсендә аерата шәп сөйләдең син... Бу китап та шул кичә хәтирәсе. Кая барсам да, калдырмыйм мин аны... Ничек әле? — Гөлсинә, кулларын күкрәгенә куеп, үзенчә тирән хисләргә бирелгәндәй булып, ярым пышылдау белән тезеп алып китте:

Их, син яшьлек,
Их, син тиле яшьлек!
Шундый кыска булып тоелдың,
Кичен...

Әлбинәнең башы күтәрелде, бинһаят ярсулы пышылдау белән:

— Зинһар, кирәкми! — дип хуҗа кызны бүлде һәм, аңа томанлы, мингерәүле карашын тероп, үз сүзләренә үзе буыла башлады: — Син әйт миңа, әйт... Такташ заманында кешеләр әллә әйбәтрәк булганмы? Гаделрәк, намуслырак?.. Әллә түгелме?.. Юк, Мәхмүт Зөбәйдәсе янына кайтмагандыр, Зөбәйдә уйнаштан туган баласы белән үзе генә утырып калгандыр... Шулайдыр, шулайдыр... Такташ абый юри генә язгандыр, юри генә кавыштыргандыр... Тормышта бөтенләй алай булмый бит... Ник алай язды икән, ник, ник, ник?!

Гөлсинә, гаҗәпләнүе чиктән ашып, бәбәкләрен агартып, Әлбинәгә текәлде. Бер мәл шулай зиһенен җыя алмыйча торганнан соң, тегенең янына утырып, кулын җилкәсенә салды:

— Ни сөйлисең син, Әлбинә? Чыннан, ни булды сиңа?

— Белмисең лә, аңламыйсың ла хәлемне...

— Әллә ниме?..

Әлбинә кинәт йөзе белән Гөлсинәнең иңбашына капланды. Аның бөтен гәүдәсе, бизгәк тоткандагы шикелле, дер-дер калтырана иде.

— Сиңа сөйләми, кемгә сөйлим? Кемем бар монда? Ах, Гөлсинә, алданырдай кыз идеммени мин?.. Син беләсең бит, ничә ел бергә укыдык, ничә ел бергә тордык... Ә бит алдап, ташлады мине Әхсән...

Әйтерсең, Гөлсинәнең тәнен ялкын куырып алды:

— Булмас! Ул бит...

— Син булмас дисең, миңа хаты, миңа мин — озакламый ана буласы кеше... Вәгъдә, диде, гомерлеккә бергә булабыз, диде... Кая гына куйыйм бу җүләр башкаемны?! Укытучы бит мин, укытучы, укытучы... Ә ничек укытыйм, адәм арасында ничек йөрим, күзләренә ничек күтә-

релеп карыйм, укучыларыма ни әйтим?.. Бир син миңа бер-бер киңәш, ничек котылыйм бу хурлыктан?.. Буш җибәрмә, буш җибәрмә, дустым!

Моңарчы көч-хәл белән генә эләгеп-бәйләп торган нәрсә, кинәт юл алып, ташкын булып агып китте. Гөлсинә илереп елаган дусын ничек юатырга белми, ул тәмам каушаган, югалып калган иде. Шулай да, таркалган зиһенен беркадәр җыя алгач, Гөлсинә сабакташын җылы сүз, дусларча мөгамәләсе белән аз булса да тынычландыра алды. Һәм моны тагын да ныгыту уе белән:

— Ничево, үзенең дә койрыгына басарбыз. Комсомол бит ул, вәгъдә иткән икән, өйләнергә тиеш, — дип куйды.

— Бер баш тарткачмы? Чигенер дисеңме? Кешесе ул түгел шул! Монда килгәндә, каладан шалтыратып карадым мин... «Ник бәйләндең әле миңа, ди. Бер киселгән телемне кире ябыштырып буламыни», ди... Юк, Гөлсинә, ялынып кияүгә чыгу, ялынып тормыш кору эш түгел инде ул... Өметләр өзелгән, киредән ялгап булмас...

Гөлсинәнең акылына һаман да сыеп бетми иде әле:

— Вот кабахәт җан, вот кара елан! Шулай ди, ә? Ну, үзен дә буш калдырмаска кирәк!

Әлбинә күз яшьләрен сөртеп, өстәл артыннан авыр гына кузгалды.

— Укытучы булмасам, тагын бер хәл иде... Төн йокыларым качты бит, Гөлсинә, белсәң иде... Шулай ук җүләрләнермен микәнни? Ичмаса, синдә тынычлап йоклап китә алсам иде... — диде ул, тузгыган чәчләре астыннан чигәләрен тотып.

— Йокларсың — ансына пошынма... Кайдадыр Раяның йокы даруы бар иде. Кайчакны ул да интегә... Табып бирермен...

Әллә иптәшенә килеп бушану ярдәм итте, әллә йокы даруының тәэсире көчле булды, ләкин бу төнендә Әлбинә ничә тәүлеккә беренче тапкыр тирән йокыга чумды.

* * *

Бүтән ял көннәрендә ике бүлмәдәш, Гөлсинә белән Рая, шактый озак йокы симертә торганнар иде. Дәрескә барасы юк, алай дөнья мәшәкате дә әле басмаган, студент чакларның рәхәтлеген искә төшереп, бер туйганчы йокламагач та ял буламыни ул?

Ә бүген Гөлсинә бик иртә уянды. Тәрәзә дөм-караңгы, шылт иткән аваз да юк. Тышта җил дә басыла төшкән, ахрысы...

Каршы як стена буенда Рая койкасында Әлбинә йоклый. Сулышы-тыны ишетелми диярлек. Йокласын, күңел кыллары артык нык тартылган, бераз йомшартса, зыян булмас...

Уянды да, бүтән йокыга китә алмаячагын сизеп, кулларын баш астына салып, уйга калды.

Күңел күзе күрмәсә, маңгай күзе — ботак тишеге, дигәннәр. Гөлсинә башына да китермәгән иде шул. Әхсән белән Әлбинә арасы һаман да ал да гөлдер, Әлбинә һаман да бәхетледер дип уйлый иде, югыйсә кунак килеп кергәч, аның хәлен сорашмыйча, үзе турында гына ул кадәр җәелеп сөйләнер идемени ул? Килеп кергәч тә җентекләп карамады, караган булса, бәлкем, кыяфәтеннән үк сизгән булыр иде. Кеше шундый зур, шундый авыр хәсрәтне йөрәгенә асып килеп керсен дә... Я, ходаем, инде ни кылырга, ничек ярдәм кулы сузарга?

Укыган елларын исенә төшерде.

Ничә еллар буена бер үк аудиторияләрдә, бер үк укытучыларны бергә тыңлап йөрделәр, соңгы ике елын хәтта бер бүлмәдә яшәделәр алар. Ак һәм пакь күңелле, саф йөрәкле кыз иде бит Әлбинә...

Менә ул группаларының комсоргы, бу эшне ничек җанлы һәм кызыклы итеп алып бара белде ул. Менә группаларында дуслык һәм мәхәббәт турында кайнар диспут бара. Анда иң кыю, иң үткен һәм иң

матур фикерләрне әйтүче Әлбинә булды. Менә әдәби-музыкаль кичә. Әлбинә ялкынланып, туң йөрәкләрне дә эретерлек хис-куәт белән Муса Җәлил шигырьләрен укый... Ә менә ул, әнисе янына кайтып килгәч, бер кочак күчтәнәчләрен өстәлгә җәеп, бүлмәдәшләрен сыйлый...

Кинәт Гөлсинәнең Әлбинәдән көнләшеп йөргән көннәре хәтеренә килде. Шул Әхсәнгә, шул бәндә кисәгенә үлеп кызыккан, хәтта төшләрендә күреп саташып йөргән иде бит ул үзе дә... Әгәренки Әлбинә язмышына ул үзе юлыккан булса?.. Юк, юк, Гөлсинә акылын җуймас, чөнки ул инде Ул, бөтән түгел... Кисәк Идел битендәге бәләкәй утрау янында Әхсән белән су коенган чактагы хәлате күңеленә кабат әйләнеп килгәндәй булды. Әллә шул таза, нык беләкләре, ефәктәй шома, йомшак теле, томанлы, серле карашы белән сихерли алды микән Әлбинәне дә?..

Тигезлек, диләр, ә табигать тигез яратмаган. Бер ялгыш адымы аркасында никадәр кыз бала, бөтен гомеренә төзәлмәслек җәрәхәт алып, язмышын җәфалы юлга сала? Бер абынуы өчен нинди зур җәза?!

«Сакланыгыз егет халкыннан», — дигән шагыйрь һәм хак сүзләр. Гөлсинә бу сүзләрне дә яшь кызлар үтәсе юл һәм сукмак чаты саен, агач һәм куак саен, тау кыясы һәм яшел тугайлардагы чәчәкләр саен язып куяр иде. Ай тиклем айның көмеш битенә дә шул кисәтүне мәңге җуелмаслык итеп, мәңге кызыл утта янарлык итеп уеп чыгар иде!

«Әлбинә, Әлбинә, җаныкаем, төшеңдә ниләр күрәсең син? Өннәрең бигрәк яман ла икән...»

Берәүләр, ким-хур булудан качып, ашык-пошык кияү табарга омтыла. Табалар да. Кем очраса, шуңа ябышалар. Кайчакны уңышка да ирешәләр — тормышлары бер җайга салына кебек... Әмма яратмыйнитми чыккан кеше белән гомер итүе тагы...

Ә баласын тапса? Азмыни дөньяда ирсез бала китергән аналар? «Ничек укытыйм, кеше күзенә ничек күтәрелеп карыйм, укучыларыма ни әйтим, бу хурлыкларга ничек түзим», дип өзгәләнә бит ул әнә... Чыннан да, үзе укытучы-тәрбияче булсын кеше, үзе ирсез бала тапсын...

Ә бәлкем, баладан котылыргадыр. Берәр ничек яшертен генә, сиздермичә генә?.. Ләкин ничек? Бер көнне күршедәге бер яшь такылдык хатын аларга кереп сөйләнеп чыккан иде: имештер, совхоздагы хатыннарның күбесе калага барып, больницага ятып та тормыйлар, ди. Монда үзләрендә бик шәп бер врач хатын бар икән, шуңа гына баралар, ди...

Озак баш ватты, озак уйланып әмәлләр эзләде Гөлсинә, ләкин бер төрле дә ныклы карарга килә алмады.

Күрше-күләннәр торып, коридорда арлы-бирле йөри башладылар. Аңа да вакыт: кунакка булган сые-нне белән хөрмәт күрсәтергә кирәк.

Озакламады, Әлбинә дә уянды. Башын калкытып, гаҗәпсенгән бер кыяфәт белән тирә-ягына күз йөртеп чыкты, аннары, кайдалыгын төшенеп, ахры, сәер генә елмаеп куйды.

— Йоклый алдыңмы, Әлбинә җаныкаем? Яңа җирдә нинди төшләр күрдең? — дип сорады анардан Гөлсинә, төче теллэнеп.

— Әллә ни шунда... Саташулы төшләр генә... Тукта, берсе бик кызык иде... Әй, оныткානмын да инде.

— Яман төш булса, онытылуы хәерлегә генә ул... Торасыңмы? Ятам дисәң, вакыт иртә әле, ят, пожалуйста.

— Торам.

Чәчләре тузгыган, җәйге кояшта тигез каралган тәне электр уты яктысында елык-елык, буе-сыны тагы... Чибәр, җинел.

Табын хәзерләгәндә дә, табын артында да сөйләшкәннәре җыен юк-бар булды. Әлбинәнең йөзе-кыяфәте кичә төнгедән күп ару күренә:

бит урталарында чак кына алсулык бар, карашында нур бар, тик күз төпләрендәге күгәргәнлек кенә бераз сиздерә... Гөлсинә үткен генә бер мәзәк сөйләп алгач, Әлбинә, кыз чагындагы шикелле ачык яңгыравыклы тавышы белән шаркылдап көлеп куйды.

Ләкин Гөлсинә күңелендә туган нәрсәләрне аңа әйтмичә кала алмады. Койкасына янәшәгә алып утырды да кулын Әлбинәнең иңбашына салды. Беравык шулай дәшми-тынмый утырганнан соң, Гөлсинә, булган кодрәтен җыеп, әмма бәхәс тә, үпкә-мазар да куптармаслык йомшак бер тавыш белән, уйлаган нәрсәләрен дусты алдына берәм-берәм чыгара барды, чыгара барды, ә теге я озын керфекләрен еш-еш каккалап, я тирән сулап-уфтанып, я кысык иреннәре аша теш аралый сыгып, иптәше әйткәннәрне бер-бер артлы кире этәрә барды, этәрә барды... Гөлсинә хак уйлаган: берсе-бер ярамады. Кыен да хәл!

— Бу хәлемдә укытучы булсам, ана була алмыйм, ана булсам, укытуны ташларга туры килә, дисең... Теге врач турында да исәп итсәң дип кенә әйтәм, — дип текәлде Гөлсинә. — Сиңа ничек тә киңәш биреп булмый. Үзең уйла инде.

— Сабыр итим әле, аз гына булса да көтим әле, үзен телефонга тагын бер чакырып карыйм әле... Ах,ниләр төште бу газиз башкаема!

Тагын ватылган, тагын сынган-җимерелгән йөз-кыяфәт...

Мәктәпкә бармадылар.

Әлбинә, икенче рейс автобуска өләгим дип, ашыга башлады. Үзенең эче тулы сагыш-хәсрәт, үзе һаман: «Дәфтәрләрем бер кочак, планнар язасым бар, программирование буенча әңгәмәгә хәзерләнергә кирәк», ди... Бу женен һич нәрсә дә чыгара алмас, ахры, аның.

Чыгып китәр алдыннан Гөлсинәдән ике-өч йоклаткыч таблетка сорап алды.

* * *

Атна үтте, ун көн үтте, Әлбинәдән хәбәр дә, хәтәр дә ишетелмәде. Гөлсинә бу хәлгә инде борчыла да башлаган иде. Әмма нәкъ ике атна тулган көнне — шимбәдә, кич кырын килеп керде.

Өсте-башы мокма, ишек төбендәге табуреткага хәлсезләнеп утырды да зур, дымлы күзләрен Гөлсинәгә төбәде.

— Җүләрләнеп автобус көтмичә, ачык кузовлы машинага утырган идем. Ә ул, каһәр суккан, нәкъ коеп яуганда ватылып ятты, — ди.

— Их, сине, акыллы баш... Шушы пальтоң өстеннән плашыңны киеп алган булсаң, ни булыр иде? Авылда яшисең бит, бераз авылча йөргәндә дә зыян итми ул, — дип тиргәп алды аны Гөлсинә. — Давай, чишен тизрәк... Хәзер мичне ягып җибәрәм.

— Син ачуланма инде, үпкәләмә инде, Гөлсинә... Килдем менә. Бүтән көтәргә дә, түзәргә дә хәлем калмады, — дип пышылдады Әлбинә.

*(Ахыры киләсе санда.)*

● ● ●

*Нәби Дәүли*

# КЕШЕ ТУРЫНДА МОНОЛОГ

Китерделәр аны больницага
Машинага салып тиз генә.
Кеше гомере хәзер кыл өстендә,
Сак булыгыз,
Сак булыгыз,
Кыл дисәң дә — ул кыл өзелә!
— Инфаркт!
Ул кемнәрне екмый бер минутта,
Ләкин,
Корбаннарын сайлап кул суза.
Писсимистка тими,
　　чөнки белә, —
Писсимистның җаны буш була.
Усалларга тими,
　　исерекләргә тими,
Явызларны уза калдырып,
Чөнки белә,
Аларны бит беркем сагынмас та,
Искә алмас беркем кайгырып.
Инфаркт.
Аңа кирәк батыр яки шагыйрь,
Укытучы яки инженер.
Я тынгысыз —
　　минем кебек кеше,
Я Ватанда даны булган ир...
Карыйм да мин дустым йөзләренә,
Тирән эзләр анда сызылган.
Инфаркт —
Йөрәктәге авыр яра диләр,
Авыр яра.
Шул турыда минем сүзем бар.

1

Әйе,
Бәхетсезлек килә, хәбәр итми,
Атлаганда юлда адымны,
Килә дә ул:
　　— төш арбадан — дия, —
Туар шунда арган атыңны.
Ә тормыш?
Тормыш һаман юлын дәвам итә,
Ләкин һәр көн,
　　һәр төн,
Булып тора җирдә үлемнәр.
Вакыт җитә,
　　кинәт авып китә
Меңәр яшьле калын иманнәр.
Ә син кеше,
　　ә кешегә
Күпме генә гомер бирелгән?
Аз да түгел,
　　ләкин күп тә түгел,
Алтмыш, җитмеш диләр — уртача.
Хәер,
　　туксан тугыз ярым
　　　　яшькә кадәр
Яшәгән бит минем кодача.
Юк, борчылмыйм,
　　әгәр шундый бәхет,
Өлешемә минем чыкмаса.
Ләкин әле
　　бик тиз үлмәм кебек,
Аяк чалып язмыш екмаса.
Әмма куркам,
Гайбәтчедән куркам,
Әләкчедән куркам,
Алар, —
Мыштым гына чага торганнар.
Шул явызлар җирдә яшәгәндә
Булмый булмас әле корбаннар.
Кайчан бетәр алар, —
　　беркем белми,
Прокурор да әйтмәс бу хакта.
Ләкин беләм:
　　гасыр арбалары
Гайбәтчене,
Чүп-чарлыкка илтеп бушата.

2

Гайбәтчегә гомер авыр түгел,
Ул бит яши безнең исәпкә.
Пенсиягә инде чыкса да ул,
Саный әле үзен хезмәттә.
Матур кызга әгәр
　　син елмайсаң,
ул да сиңа көлеп караса —
Беттең,

Гайбәтченең кесә дәфтәренә
Төшеп кала инде кара тап.
Йөз граммны түгел,
бер грамм да
Китермә син авыз янына.
Гайбәтченең теле синең хакта
Хәбәр салыр —
Чиләк каккан кебек янгында.
Ләкин кеше,
кеше булган кеше,
Куркамы соң гайбәт сүзеннән?
Иртәнге чык төсле
саф тир белән
Юып ташлый тапны йөзеннән.
Яши кеше,
сөя, хезмәт итә.
Шатлана да, кайчак кайгыра.
Йолдызларга карап хыяллана,
Җанашым, дип әйтә айны да.
Көлә дә ул,
кайчак «сала да» ул,
Исәбе юк яшәп туярга.
Белмим,
Марсияннар ничек тора икән?
Ә чын кеше, —
Ә чын кеше, —
Дөбердәтеп яши дөньяда!
Ләкин дөнья
һаман тыныч түгел,
Кинәт-кинәт куя болганып.
Я сугышы була,
я җир тетри,
Я вулканнар дулый уянып.
Ә кешегә һаман барасы бар,
Иген игеп,
чуен коеп,
тимер кайнатып.
Шәһәр корып,
бала тудырып.
Үз бәхетен җирдән җыясы бар
Йөрәгенә салып,
күзләренә алып,
учларына тулы тутырып.
Кеше,
Космоска да чыгып,
очып китә
Венерага юллар табарга.
Җирдә кала аяк баскан эзе,
Тагын кала —
Юешләткән урыны,
Гайбәтчегә иснәп карарга.
Гаҗәп шунысы,
кеше оныта үзен,
Оныта ул ашын, йокысын.
Әйтерсең, җир —
кинәт туңар төсле,
Алмый калса
кеше кулларының җылысын.
Җир хәйләкәр,
иркә хатын кебек,
Кочагына кергән кешенең.
Тирбәтергә куша,
миллион-миллион бала
Тулып яткан алтын бишеген.
Тартымы бар җирнең,
юкка түгел,
Ул кочаклап тота кешене.
— Китмә, — ди ул, —
яшә минда генә,
Космоста да
Табалмассың минем ишене.
Минем тартым —
сиңа мәхәббәтем,
Син дустым да минем, ярым да.
Көнләшмәсен хатының,
ул үзе да —
Башта туган минем карынымда.
Ә кояш?
Кояш җирнең тирәсендә йөри,
Мәңге уяу сакчы шикелле.
Язлар килә, тагын бозлар эри.
Җил,
Тургайларны куып китерә.
Үлән чыга,
чәчәк йөзен ача,
Гайбәтче дә ятмый тик кенә...

## 3

Гайбәтче, —
ул да яши кеше исеме белән
Паспорты бар,
Фатиры бар,
Ишегенә номер сугылган.
Адресы бар,
Ләкин
Без белмибез, —
Аның кулы кемгә сузылган,
Күзләр күрмәс
Үткен хәнҗәр белән
Кинәт кенә китереп кадарга.
Ә аннан соң
Иң беренче булып
Табутына килеп карарга.
Гайбәтче дә
Яза, яза, яза.
Ак кәгазьгә кара сүз чәчә.
Тәрәзәсен каплап юрган белән
Яза,
Язып аргач каты чәй эчә.
Стоп, кеше,
Стоп!
Стоп!

Аноннимка әзер,
Аноннимка райком кулында.
Аны язган фамилиясез бәндә
Элеккеге малай,
элеккеге солдат,
Бүген инде
Ап-ак чәчле кеше турында.
Гайбәтчегә нәрсә ап-ак чәчләр,
Җыерчыклар кеше йөзендә?
— Билгеле, ди,
юкка кайгырмаган,
Димәк,
Гаепләре булган эшендә...
Сүз бирелә сиңа,
райком секретаре,
Тикшер хәзер кеше язмышын.
Ләкин бел,
синең үзеңдә дә
Кешедәге кебек җан булсын.
Аноннимка —
тимер сейфта ул,
Охшап ята соры еланга.
Бармак белән аңа кагылсаң да
Онытма син,
Сабын белән кулың юарга.
Күзләр зирәк,
сизгер булсын йөрәк,
Кара,
Үзеңне да елан чакмасын.
Аңа каршы әле чаралар юк,
Бер тамчы да дару тапмассың.
Сак бул,
сак бул,
райком секретаре,
сейфтан син аны чыгарма,
Нәрсә булыр безнең йортыбызда
Ирек бирсәк шушы еланга?
Киңәш итәм сиңа
ул еланны, —
Кызганмыйча тотып буарга.
Берәвемгә дә
рөхсәт бирелмәсен
Дегет белән
Капкабызны безнең буярга!
Аноннимка — кагазь.
Алып,
ертып,
ташла кәрзинкага.
Саф кулларның моңа хакы бар.
Киләчәктә туар кеше өчен
Чиста калсын безнең архивлар.
Ә син, иптәш,
райком секретаре,
Төн җиткәнен сизми каласың.
Аноннимка укып баш ватасың —
Лампа түгел, үзең янасың.

Кайт өеңә,
сине хатының көтә,
Балаң сине өзелеп сагынган...
— Юк шул, — дисең, —
мин бит бу хезмәткә
Номенклатурный итеп алынган.
Сигнал килгән,
Тикшерергә кирәк,
Яфрак төшми җилсез куактан.
Йокыларың качар
ярты елга,
Обком абый тартса колактан...
— Әйе,
Дөрес,
Обком бар шул әле,
Ләкин,
Обком өчен ЦКа кыр сыза.
ЦКа өчен
Ленин юл күрсәтеп,
Таң ягына карап кул суза.
Баш өстендә, —
әнә стенадан,
Ленин тора сине күзәтеп.
Һәр иртәдә —
ул каршылый сине
Аталарча җылы сүз әйтеп.
— Хәерле көн! —
дисең син аңарга,
— Хәерле көн! —
ди ул сиңа да.
Онытма син,
райком секретаре,
Тик Лениннан киңәш сорарга.
Сора иртән:
Ничек көн башларга,
Ничек эшне алып китәргә?
Кайсы чакта —
окопта булырга,
Нинди чакта һөҗүм итәргә?
Сора көндез:
Ничек дуслар белән —
Кул бирешеп тату яшәргә?
Дошман белән ничек сөйләшергә,
Нинди телдә аңа дәшергә?
Сора тагын:
ничек ялагайны
Озатырга ишек төбеннән.
Икенче кат —
инде килмәс булсын,
Буямасын,
Исемеңне баллы тел белән.

Аноннимка язып йөргән бәндә,
Булгандыр ул балки бирелә.
Дошманнарны танып була да бит,
Ул бәндәне ничек белергә?
Күпме тора безгә аноннимка?

Санаулары аны бик ансат.
Мәсәлән,
Күпме китәр акча,
бер күперне
Тар-мар итсә төнлә диверсант?
Кемнәр әйтер миңа,
күпме зыян ясый,
Анонимка безнең дәүләткә?
Акча белән түгел —
кеше гомере белән,
Үз хакын ул бездән түләтә.
— Шулаен ул шулай,
дөрес, дисең.
Беләм дисең мин ул турыда. —
Секретарь да
күктән төшмәгән ич,
Алла кебек судья булырга.
Бар иде ул бераү —
үзен алла диде,
Күзгә карап хөкем йөретте.
Бер сүзе дә аның закон иде,
Гаепләргә,
җирдән юк итәргә,
Үз атасы кебек олы картны,
үз баласы кебек егетне.
Ул заманнар инде
узды дисең. —
Куркыныч юк гаделкешеләргә.
Анонимка әгәр баш күтәрсә,
Кылыч әзер
ул еланның угын кисәргә.
Тик шулай да
утсыз төтен чыкмый,
Димәк, ут бар,
Мөмкин, димәк, ялкын булуы...
Янгыннан соң
нигә пожарниклар,
Янып беткәч үзең бер юлы...
— Тыңладым мин сине —
райком секретаре,
Бу уйларың яңа түгел лә.
Күптән инде
сиңа әйтер сүзне
Йөретәм мин күңел түрендә.
Әйе,
Шәхес культы
инде бетте дибез,
Курку дигән нәрсә, —
нәрсә ул?
Йөзебездә үзе күренми дә
Ләкин
Эчтән генә безгә дәшә ул.
Курку, —
Үята ул төнге йокылардан,
Бераүләрне тиргә батырып.
Ә үзләре алар кабинетта,
Сөйләшәләр батыр бакырып.
Кемдер курка
урындыгы өчен,
Пенсиясен уйлап кайгыра.
Валидол да эчә,
курортларга бара,
Авырлыгын сала
Ә куркуны —
үзе белән бергә калдыра.
Бар бит әле
тыныч яшәүчеләр,
Котылалар эштән сүз сөйләп.
Ә куркуны алар —
әкәм-төкәм кебек
Кабык итеп йөри өстерәп.
Үпкәләмә,
райком секретаре,
Бу сөйләшү бары үзара.
Мин үзем дә
бераз куркам бугай,
Күперләрдән төнлә узарга.
Я хулиган
чыгып талар төсле
Сәгатемне кулдан салдырып.
Анонимщик —
шул ук карак бит ул,
Җанны талый шәрә калдырып,
Шундый карак белән
очрашканда
Хакыбыз юк безнең түзәргә.
Ә син иптәш,
райком секретаре,
Телисеңме,
минем дустан гаеп эзләргә?
Әнә бит ул үзе —
синең алда,
Сиңа килде, тыңла син аны.
Үзе белән бергә алып килде
Давыл аша узган деньяны.
Йөрәгендә аның сагышлары,
Кулларында каты сөялләр.
Күзләренә кара —
алар сиңа,
Туры сүзне сүзсез сөйләрләр.
Нәрсә булыр әгәр
син секретарь,
Эзләп алсаң шаблон сүзлеген?
Карап торсаң аңа читтән генә
Гайбәтченең киеп күзлеген?
Дуска кирәк
синең җылы сүзең,
Авыр сүзең —
Авыр яра ул.
Сак бул,
сак бул,
райком секретаре,
Йөрәктә ут,
йөрәк яна ул.

*Роберт Батуллин*

# МИРАЖ

*Хикәя*

Бактагы актык бензин бетте. Машина акрынайды. Бераз төчкергәләп барды да «дырк» итеп туктап калды.

— Тфү, алла колы! — дип сукранып алдым мин эчтән генә. — Менә хәзер утыр инде кайнар чүлдә әлсерәп!

Кояш рәхимсез кыздыра. Җилнең әсәре дә юк. Һава хәрәкәтсез. Машина лаклары чатнап-чатнап куба. Рәүф белән машина астындагы күләгәгә кереп яттык. Тик бу кадәр бөркүлектән качып котылу булмас, ахры.

Берничә мәртәбә машина түбәсенә менеп, тирә-якны карап төштем. Бер генә яшеллек тә, бер генә җан әсәре дә күренми. Офыкка кадәр барханнар...

Ком... ком... ком...

Әйтерсең, бөтен җир шарын ком баскан. Адашканлыгыбыз көн кебек ачык. Бензин беткәндә, сигезенче бораулау посты каланчасына элenгән флаг күренә иде.

«Рәүф запас канистрларны онытып калдырмаган булса, бәлки барып та җиткән булыр идек», — дип уйлыйм.

Ул үзен гаепле санамыймы, әллә чүл уртасында сусыз, ягулыксыз утырып калуның нәрсә икәнен белмиме... тыныч күренә...

— Табын әзер! — дип кычкырды ул, машина астына урын көйләгәннән соң. — Төш, картлач! — Үзеннән бер-ике яшькә олы булганга, ул мине шулай дип атый. — Чәй эчеп җибәр! Кайгырма, баш исән булса, җае табылыр. Арттагы машиналар куып җитәр. Безнең канистрларны күреп, ала чыкканнардыр әле.

Ай-һай, башка шоферлар чүл эченә керергә куркалар. Шуңа күрә әйләнеч юлдан йөриләр.

— Кайнар чәй бу кызуда галәмәт тә шәп нәрсә инде ул, — дип дәвам итте Рәүф, керләнеп беткән кулъяулыгы белән битен сөртәсөртә. Һәм үзе, берни булмаган кебек, җырлап та җибәрде. — Грузинский чәй термоста, рюкзакта башкорт балы. Эсәһең килһә, ярты ла бар, һина ни кәрәк тагы?..

Башка вакытта җилбәзәк дустымның бу шуклыгыннан рәхәтләнеп көлгән дә булыр идем. Әмма бу юлы мин аңар әйләнеп тә карамадым.

— Пәкенне бир әле, — диде Рәүф.

Мин пычак сузарга ашыкмадым.

— Ишетмисеңме әллә? Картлач, пәкеңне кызгансаң, ипине сындырып ашыйм, гөнаһысы сиңа булыр.

— Рәүф, — дим мин салмак кына. Үзем кышлаклар, буровойлар яшеренгән ком тауларына карыйм.

— Нәмә?

— Әгәр дә безгә атна буе ятарга туры килсә, син нишләр идең?

Рәүф бу сүзләрнең чын мәгънәсенә төшенмәде бугай, пычакны да көтмичә, икмәген сындырып ашый башлады.

— Җиһаншиннар бер күрек белән 49 көн яши алганнар. Бездә баллоннар җитәрлек бит. Кис тә аша, кис тә аша. Ха-ха... Алары бетсә, кузовта покрышкалар бар. Между прочим, Әсгать Җиһаншин безнең районнан...

Ул янә икмәккә үрелде. Мин аның җиңеннән тоттым:

— Куй! — дидем. Шаярта дип уйлады булса кирәк, Рәүф кушканны үтәргә җыенмады.

— Экипаж командиры синме, минме? — диде ул, һаман шаярып. — Мин — беренче класс, син — өченче. Димәк — мин командир. Шулай булгач, мин синең боерыкны үтәмим.

— Рәүф! Ягулык бетүдән чамалап караганда, без иң якын буровойдан 50—60 чакрым ераклыкта булырга тиешбез. Әгәр адашкан булсак?!

Рәүф чәйнәвеннән туктады.

— Арттагы машиналар?..

— Әгәр алар безнең арттан чыккан булсалар, ике-өч сәгать элек куып җитәргә тиешләр иде...

— Нишлибез соң?

Мин җавап бирмәдем.

Безнең бер көнгә җитәрлек суыбыз-азыгыбыз бар. Адашуыбыз хак булса... Дүрт-биш сәгать эчендә 60—70 чакрым тизлек белән чүл эченә кергәнбез. Бу хәл күңелгә өмет өстәми иде.

Фәритләр группасы төнге өчләрдә кышлакка барып җитә, ди. Кайтмавыбызны белгәч, эзли чыгалар, ди. Безне тапканчы бер тәүлек уза да уза. Димәк, көтәргә кирәк.

— М-да, — дип куйдым бераз уйлап торгач, — бер-ике тәүлек кызынырга туры килә...

Мин әйтеп тә бетермәдем, Рәүф шашкандай кычкырып җибәрде:

— Картлач, вертолет! Ә-әнә теге бархан артыннан күтәрелде!

Бу сөенечле хәл. Димәк, якында гына кышлак яки буровой бардыр!

— Ялгышмадыңмы? Чүлдән күтәрелдеме?

— Юк, чәнчелеп китим әгәр. Ком тавы артыннан чыкты!

— Шәп! Син кал! Мин киттем!

— Кая? — Рәүф ашыга-ашыга үрмәләп машина астыннан чыкты.

— Бу 22 нче геоThere разведка! Вертолет шуннан күтәрелгәндер. Әҗәткә бензин бирсәләр, без Фәритләрнең борыннарына чиртәбез!

— Мин дә синең белән...

— Кызудан курыкмасаң... Син бер термосны ал. Мин рюкзакны күтәрәм.

Киттек. Кич җиткәндә, вертолет күтәрелгән барханга килеп җиттек. Тик анда кышлак та, буровой да юк иде. Күрәсең, Рәүф ялгышкандыр!

— Шушыннанмы?

— Әйе... Шуннан чыккан кебек... шушыннан чыкты...

— Кебек тоелды... — дидем мин, ачуымны яшермичә.

Мин артка борылдым. Машинабыз кара-кучкылланып чүл уртасында бер үзе тора. Тагын кузгалдык. Бәлки, вертолет әнә теге тау артыннан чыккандыр!

Төн житте. Аяусыз кояш астында көнозын яткан дала иркен сулый башлады. Батып барган кояш нуры офыкны кызгылт-сары төскә манды. Озак та үтмәде, тирә якка кара-кучкыл чүл төне ятты, күнелдә шом уятып, чүл эченнән сәер тавыш ишетелә иде. Бу безне тәмам куркуга төшерде.

— Нәрсә улый ул?..

— Чүл ыңгыраша.

Көндез кызган, кинәйгән ком өемнәре, һава алмашынгач, урыныннан күчә, утыра, шуыша, күрер күзгә сизелмәслек бу хәрәкәт үзенә бер тавыш чыгара икән.

Алдагы бархан артында да күнелләргә шатлык, аякларга көч өсти торган буровой утлары күренмәде. Кире борылдык. Төн салкыны бет-кәнче, машинага кайтып житәргә дип, кызу-кызу атлыйбыз. Һәркем үз уйлары белән мәшгуль. Мин эчтән генә гамьсезлеге өчен Рәүфне сүгәм, югалган вакыт өчен борчылам. Рәүф тә шаяруын онытты, сөйләшми.

Таң озак көттерми. Көнчыгыштан офык чистара, яктыра бара.

Машина күренми әле. Икебез дә текәлеп-текәлеп карыйбыз. Бераз яктыра төшкәч, күренер дип өметләнәбез. Ләкин машинабыз яктыргач та күренмәде. Инде кояш та чыкты. Тик күпме генә эзләсәк тә, килгән эзләрне дә, машинаны да таба алмадык. Төнлә машинаны күрмичә, үтеп киткәнбез, ахры!

— Бәлки Фәритләр алып киткәннәрдер?

— Фәритләр бүген кичкә генә килеп житәләр... Әгәр Фәрит килсә, безгә фаралар белән сигнал бирер иде...

Без, нишләргә белмичә, чүл уртасында туктап калдык. Бу бәхетсез-лек өметне дә, аякларда булган көчне дә алды. Әмма машинаны табар-га кирәк. Аның күләгәсенә ятып, Фәритләрне көтәргә кирәк иң.

Кояш күтәрелә. Күтәрелгән саен кыздыра бара. Бер генә болыт та юк. Кояш нурлары рәхимсез рәвештә комбинезон аша үтеп тәнгә када-лалар. Итекләр мич калае кебек булып кыздылар. Табаннар ут яна. Тамак чатный. Карын ач. Ипине ашап булмый. Чәйнәргә төкерек юк. Үлеп эчәсе килә. Рәүф артта калган булып термостагы чәйне эчте. Мин сизмәгәнгә салыштым. Ләкин бу хәл янадан кабатлангач, түзмәдем.

— Рәүф! — дип кычкырдым.

— Юк, юк, Вәсим! Мин күп калдымы икән дип кенә карыйм.

Мин аны көтеп алам. Ул өч-дүрт адым атлый да тагын туктый.

— Вәсим... картлач жаным, бераз гына ял итиксәнә...

— Юләр! Бер утырсаң, тора алмассың. Буыннар оеша. Басып ял ит!

— Их, жиле дә юк бит...

Элеккечә шаян, кызу егетне алмаштырып куйдылармыни! Аның элек тә какча бите, сакал баскач, тагын да ябыгып китте. Күзләрен кан баскан. Кипкән иреннәре ярым ачылып калган. Үземнең дә рәт бетте. Ләкин котылуның бердәнбер юлы — алга бару!

— Әйдә, киттек!

Кайнар ком атлаган саен артка шуыша. Такыр жирдә ике адым алга, бер адым артка атлаган кебек, салмак селкенәбез.

Кояш баш өстендә. Ял итәбез. Вакыт-вакыт күз алларым караңгы-ланып китә. Куллар үзләреннән-үзләре термоска үреләләр. Мин, игъти-барны читкә юнәлтү өчен, офыкка карыйм. Офыкның гел бертөрлеле-геннән күңел кайта. Алда ком... ком... ком. Артта да ком... ком... ком. Чүлне урталай бүлеп, ике эз генә ярылып ята.

Төш авышкач, жил чыкты. Рәүф бу үзгәрешкә шатланып куйды. Әмма чүл жиленең шатлык китермәгәнен ул бик тиз аңлады. Жил, хәрәкәтсез һаваны кузгатса да, жиләслек тудырмый. Вак ком бөртек-ләрен себереп алып килә дә биткә сылый. Ком күзгә тула, теш арасына кереп чытырдый. Баруы тагын да кыенлаша төшә.

Рәүф берничә мәртәбә егылды. Баштарак ул үзе торды. Аннары ярдәм итәргә туры килде.

Ниһаять, кич житте. «Фәритләр эзли чыккан булсалар, машинаны тапканнардыр инде, эз буйлап килерләр, бәлки», — дип уйлыйм.

Туктадык. Мин рюкзакны мендәр итеп көйләп яттым. Рәүф ничек егылды, шулай йокыга китте. Термосны алып, рюкзакка тыктым.

Кеше җаваплылык сизсә, үлеп йокласа да, вакытында уяна ала. Мин дә сәгать ярым йоклаганнан соң уяндым. Төнге салкынны ычкындырырга ярамый. Бәлки, машина яки берәр разведка уты күренер! Анда салкын су, җиләс күләгә, кайнар аш...

— Рәүф, тор!

Юлдашым уянмады. Катырак төртәм.

— Егет, тор! Рәүф!

Ул йокы аралаш нидер мыгырдады да кире ятты. Чүлдә минутлар гомерне саклап калалар! Мин Рәүфне күтәреп торгыздым. Дустым уянды.

— Мә, капкалап ал! Аннан соң дүртенче тизлек белән алга!

Аңа бер сынык икмәк белән ярты кружка чәй бирдем һәм термосны урнына кире салып, рюкзакны кидем. Рәүф минем бу эшемне ризасызлык белән күзәтеп торды.

— Димәк, ышанмыйсың? — диде ул.

— Мин чүлне синнән яхшырак беләм...

Ул дәшми-тынмый гына ашады да тәмәке кабызды.

— Яхшы белгәнгә, менә шушылай чүл бүреләренә азык булыр дәрәҗәгә килеп життек инде, — диде ул.

Мин дәшмәдем. Мин күзәтә идем. Рәүф суырган саен, тәмәке уты яктысында аның кырыс йөзе чагыла. Тавышында да, йөзендә дә миңа таныш булмаган салкын чаткылар сизелеп китте. Кузгалдык.

Яктыра башлады.

— Тәмәке хәлне ала, — дидем мин бераз баргач. Ләкин Рәүф җавап бирмәде. Ул, нидер күргәндәй, алга карады һәм йөгерә үк башлады. Бераз баргач, җиргә иелде.

— Кеше эзләре! — дип кычкырды ул. — Картлач, бередән яңа гына үткәннәр.

Мин йөгереп эзләр янына килдем. Ләкин шатлыгыбыз бер мәл эчендә зур кайгыга әйләнде. Бу безнең үз эзләребез иде. Төне буе бер урында таптанганбыз. Шатлык дип көткән нәрсәң кинәт кайгыга әйләнсә, нервлар түзмиләр. Күңелем тулды. Ләкин тамак буйлап менгән эче төерне йотарга туры килде. Рәүфнең өметсезлеккә бирелүе бар иде.

Шәфкатьсез кояш тагын да үз эшенә керешге. Еш-еш туктыйбыз. Чалбар-күлмәк ышкыла-ышкыла тәнне кыра. Итекләр үкчәне суеп бетерделәр. Тозлы тир суелган җирләрне ачыттырып, үзәккә үтә. Сыгылып-сыгылып елыйсы килә.

Бу утыруда, мин аяк яраларым белән маташканда, Рәүф термосны алган. Башым күтәреп карасам, йотлыга-йотлыга чәй эчеп тора. Бер сикерүдә аның янына килеп життем. Мин термоска үрелгәнне сизеп, ул бер кырыйга тайпылды. Ләкин мин тиз генә термосны эләктереп алдым. Рәүф, бер кулы белән термосны тоткан килеш, икенчесе белән мине этеп җибәрде. Мин тагын термоска ябыштым. Без сүзсез генә озак тарткалаштык.

— Үземнеке... үземнеке. Минем термос, бирмим, — дип хырылдый башлады Рәүф, — мин йоклаганда урлап эчәсең. Үземдә торсын. Үзем эчәм...

Рәүфне тезем белән этеп җибәрдем. Ул егылды. Термос минем кулда калды.

— Тиле! Берьюлы эчеп бетереп нишләрсең! Йотымлап кына эчәргә кирәк. Ир-егет бит син, юләр баш! Суны да, көчне дә сакларга кирәк.

Ул бераз тынычлана төште.

Рәүф байтак эчкән, ахры. Термос шактый җиңеләйгән. Үзем дә чак-чак кына тыелып калам. Авыз суга тисә, һич аерылып булмый. Ниндидер сихри көч иреннәрне суга тарта.

Тагы алга киттек. Җил юк. Һава кискәләп-кискәләп алырдай куе. Бугаз ком юшкыны белән капланган. Сулаганда хырылдаган аваз чыгара.

Күктә реактив самолет зәңгәр фонга ап-ак сызык сыза. «Кайдадыр кешеләр бар, — дип уйлыйм мин. — Тормыш бар. Яшиләр, салкын суда коеналар. Татлы салкын чишмә суы эчәләр. Җиләс бакча күләгәсендә ял итәләр».

— Вәсим!

Мин, хыялларга бирелеп, йоклап китә язганмын. Тагын Рәүф тавышы уятты.

— Шәһәр! Картлач җаным, шәһәр! Биш-алты чакрым гына... Урра-а! Котылдык!

Мин тирә-якка карадым. Ләкин бернәрсә дә күземә чалынмады. Электәге тәҗрибәм буенча, мин Рәүф күргән шәһәрнең кайдалыгын сорамадым.

— Әйдә, картлач, киттек! Душта коенырбыз. Мунча керербез. Аннан соң рәхәтләнеп йокларбыз. Әйдә!

Мин ул күрсәткән якны тагын да җентекләбрәк күзәтә башладым.

— Ә-әнә, малай. Бакчалары ямь-яшел. Хәтта күлләре дә бар. Йортлары ак таштан салынган. Кайларга гына килеп чыкканбыз икән?!.

Шәһәр чынлап та бар иде. Күле дә, бакчасы да, урамнары да тоныкына булып офыкта чайкала.

— Әйдә, картлач! Син нәрсә һаман утырасың?

Бу мираж!.. Нишләргә? Барыргамы, бармаскамы? Бармасаң, Рәүфкә аның алдавыч шәһәр икәнен исбатларга кирәк. Чүл уртасында өч көн йөреп кибеккән-арыган кешегә чын күл түгел ул, дисәң, сине ботарлап ташлавы мөмкин. Аңа ияреп барсаң, бөтенләй кире якка китәргә туры килә. Шулай да тырышып карарга кирәк!

— Рәүф, бу мираж гына, дустым...

— Әйдә-әйдә, картлач, шашмый гына тор. Хәзер барып житәбез. Йөзем җимеше, салкын куас, ванна. Җәннәт!

— Без беркайчан да ул бакчага барып житмәячәкбез, Рәүф. Бу юл безне чүл эченә өстери.

— Син шашкансың, картлач... Арыгансың син... Күрмисеңмени? Чып-чын йортлар...

Йончылган егет шәһәр күргәч бөтенләй үзгәрде. Арыганлыгы да сизелми, чыраена да җан кереп киткәндәй булды. О! Мин ул билгеләрне яхшы беләм. Мәкерле чүл кеше белән шулай шаяра.

— Арысаң, капчыкны үзем күтәрәм.

Ул, ризалыгымны көтеп тормыйча, капчыкны күтәреп, мираж ягына атлады. Мин көчемне җыеп, алга йөгердем. Юлдашымны куып життем дә, каршысына басып, юлын бүлдем.

— Малай! Сүземне тыңла, кояшка кара! Кояш бездән алда булырга тиеш. Ә син аны артта калдырып китәсең. Бу — үлем юлы. Бу — мираж!

Рәүф шаркылдап көлеп җибәрде. Аннан кинәт туктап, миңе сөзәрдәй булып, өстәмә килә башлады:

— Җитәр, картлач! Син миңа байтак акыл саттың инде. Хәзер мин сиңа житәкче булып карыйм. Кит юлдан. Мин сау-сәламәт. Бу араны гына үтәрмен. Теләмисең икән — кал! Менә сиңа термос. Кайтып житкәч, синең арттан кешеләр җибәрермен. Хуш!

Ул термосны миңа ыргытты да китеп барды.

— Рәүф! Рәүф, дим! — Ул миңа таба борылмыйча гына туктады.

— Нәрсә?

— Ярый. Ышанмыйсың икән, мин синең белән барам. Әгәр бер сәгатьтән соң ара якынаймаса, кире борылабыз.

— Ха! Чүл белгече, әйдә!

Ул алдан китте. Мин аңа иярдем. Хәзер мин Рәүф алдында авторитет түгел идем инде. Без хәлдән тайганчы бардык. Шәһәр якынаймады. Атлаган саен тоныклана, сыегая, юыла барды. Тора-бара ул бөтенләй юкка чыкты. Без ирексездән туктадык. Бераз хәл алгач, мин торып бастым. Йончылган, картая төшкән юлдашыма: — Я, ышандыңмы инде? — дигән сыман карап алдым да кирегә таба юл тоттым. Рәүф кузгалмады.

— Әйдә, — дидем мин, артка борылып.

— Юк! — диде ул теш арасыннан гына. — Бу юлы алдый алмассың. Син мине кертеп адаштырдың. Син машинадан аерып, җәяү алып киттең. Син термосны урлап, үзең генә эчәргә уйлаган идең. Хәзер инде, килеп җиткәч, шәһәрдән читкә алып китмәкче буласың. Юк, галлюцинация түгел бу. Үз күзләрем белән күрдем. Чып-чын. Әнә теге бархан артына гына капланды ул. Син ялганлыйсың! Синең белән булмасам, мин күптән шәһәрдә идем... Күптән шәһәрдә идем...

Ул миңа шашкан күзләре белән ачулы карап алды да әле генә эреп югалган шәһәр ягына таба китте. Аның адымы тигез түгел иде. Мин дәшмәдем. Рәүф чайкала-чайкала барды да абынып егылды. Бераз селкенмичә ятканнан соң, тагын торып китте. Ком бураздалары атларга комачаулыйлар. Ерак бара алмады, биш-алты атлау белән, йөзтүбән барып төште. Мин килеп җиткәнче, Рәүф кымшанмады.

— Рәүф...

Ул кинәт сискәнеп торып утырды. Аның сакал баскан битенә ком ябышкан, күзләре акылдан язган кешенеке кебек, каядыр бушлыкка төбәлгәннәр иде.

— Су коенасым килә. Шәһәргә кайтасым килә. Син, картлач, кит. Син саран, ипи кисәргә пәкеңне дә бирмәдең... Эчәсем килә...

Ул кабалана-кабалана термос капкачын ачты һәм, эчәргә теләп, авызына китерде. Термос буш иде. Рәүф кипкән иреннәренә тамган берике тамчы чәйне ялап алды да сулкылдап еларга тотынды. Мин, бәләкәй баланы юаткан кебек, аны юатып карадым. Тик юкка.

— Мин барыбер бүген кайтып җитәм, — диде ул, кинәт елавыннан туктап. — Минем әнигә хат җибәрәсем бар, — ул миңа бөтенләй нормаль кебек күренде. — Әйе, әйе, мин акылымда, — диде ул, уйларыма җавап итеп. — Шуңа күрә дә синең белән бармыйм.

Ул, нидер күтәрергә җыенган кебек, тирән сулыш алды да урыныннан торды.

Рәүф үзе теләгән якка китте. Аны үгетләп, аңлатып торырлык хәлем калмаган иде шул. Тәнем кызыша башлады. Күрәсең, борчылган нервлар, талчыккан мускуллар бирешә башладылар. Бизгәк кенә башланмаса ярар иде! Китәргә җыенып, аягүрә бастым. Йөрәгем «жу» итеп китте. Каршымда гына ике чүл бүресе басып тора. Бу куркынычның сөенече дә бар. Димәк, ерак түгел генә кышлаклар утыра. Чүл бүресе куркак ерткыч ул. Тере кеше янына якын килә алмас. Егылганны көтеп йөриләрдер. Мин аларга таба шуыша башладым. Янымда якын дустым, пычагым бар. Ерткычлар мүкәләп килүче җан иясеннән шүрләделәр, ахрысы. Бер-бер артлы Рәүф ягына китеп бардылар. Кинәт йөрәгемне ярып, кайнар дулкын үткәндәй булды: «Рәүф егылгандыр!» Шуышырга!

Чигәгә пар чүкеч белән өзлексез сугып торалар. Дыңк-дыңк-дыңк! Тәнемне төрле яклап кыздыралар. Аяклар яна, арка пешә. Куллар кызуга чыдый алмыйча чатнап ярылалар. Яраларга кемдер тоз сибеп

тора. Баш чатный. Ми кайный. Тик ничек кенә хәлдән таймасын, ми йөрәккә боерык бирә.

Кыймылдарга! Кыймылдарга! Кыймылдарга!

Кайсы юнәлештә булса да кыймылдарга.

Акылны җуймаска, җуймаска, җуймаска!

Гәүдәм алга шуыша.

Ком... ком... ком...

Муен сеңерләре башны күтәрә алмыйлар. Маңгаем кайнар комга терәлә. Тик кайнарлыкны тоймый.

Ком... ком... ком...

Газапның да бер чиге бардыр, ахрысы. Тою хисе юкка чыга. Тән бернәрсә сизми. Хәтта эчәсе килү дә бетте. Гәүдә зурая, зурая, зурая. Барханнар кадәр зурая. Баш кабара. Тубал хәтле була. Тагы да кабара-кабара галәм хәтле киңәя. Эри. Эреп, тирә-якка сеңә, югала. Мин тузан кебек. Юк, дөнья хәтле мин. Мин юк. Мин табигать!

Мин җыелам. Аякларым кыскаралар. Башым ниндидер кыса ярдәмендә кечерәя. Мин галәмнән аерылам. Формам ачыклана. Ниһаять, мин ята торган койкама сыярлык булып кечерәям. Мин мин булам.

Иң элек күземә электр яктысы бәрелә. Ике күбәләк, бер чебен тырышып-тырышып лампа пыяласын таранлыйлар.

Колагым ишетә:

— ...Нормаль... Кертергә мөмкин, — ди тавыш.

Башымны борам. Мин ак халатлы кешеләр арасында.

— Озак йокладыгыз, иптәш! — дип елмая күзлеклесе.

Мин больницада икәнемне аңладым.

— Рәүф! Рәүфне таптыгызмы?

Мин торырга телим. Тик үз-үземә буйсына алмыйм. Күзлекле кеше мине кире яткыра.

— Борчылмагыз!..

Мин күзләремне йомам. Ниһаять, куркыныч төшнең бетәр чагы бар икән!

— Машина?!.

— Күптән биредә... Сез тиздән аякка басарсыз. Тик иптәшегезгә озак тоткарланырга туры килер. Ул акылдан язган...

Хәлсезләнеп урыныма ятам.

Рәхимсез мираж үз эшен эшләгән икән!

● ● ●

*Сибгат Хәким*

## Эмблема

Эмблема... Эмблема...
Беркеткәнме — беркеткән.
Куна кайчак күкрәгенә
Әтәчләр һәм бөркетләр.
Илләр, шәһәрләр... Аларның
Белдем илле йоласын...
Берлинда тактылар миңа
Берлин эмблемасын.
Аңлата: Берлин — аю, ди,
Шунда миңа бер немец.
Аю, ди... Аю түгелен,
Әйтерсең, без белмибез.
Кешегә тими янәсе,
Әйбәт, тыныч холыклы...
Ышандырмакчы... Әйтерсең,
Без узмаган фронтны.
Аю гөнаһсыз, тост тотам
Аю исәнлегенә.
Берлинның ләкин ышанмыйм
Аю иканлегенә,
Аю, ди... юри ул немец
Үзен мескен итә күк.
Тарих та кайчак шаярта,
Үрти, мыскыл итә күк.

## Белгәннәр тик тора

Белгәннәр тик тора, белмәгәннәр
Сөйли күбрәк: Муса баһадир,
Ул Геркулес... Сөйләсеннәр әйдә,
Син үзеңчә җырла, бәһа бир.
Көн үтсенгә язган җырлар белән
Шаккатырып булмый бу илне.
Буе аның Пушкин, Лермонтовлар,
Тукайлардан килгән буй инде.
Йөрәге дә шуларныкы кебек,
Шагыйрьләрнең юлын кан кискән,
Эше беткәч, алып пистолетын
Безнең чорга чөйгән Дантеслар.
Тоткан фашист җиргә төшкәнче ук,
Ташламаган аны ул читкә,
Испаниянең йөрәгенә аткан,
Лоркаларга аткан, Фучикка.
Тормаган ул сөртеп, чистартып та,
Азатлыкка аны төбәгән.
Яңа буын шагыйрьләрен көтә
Җәлилләрдән бушап, төрмәләр.

*1967*

*Касыйм Фәсәхов*

# Үлем аша үлемсезлеккә

1936 елның 19 августына каршы төндә Франко палачлары Испаниянең мәшһүр шагыйре Федерико Гарсиа Лорканы Гранада (шагыйрьнең туган каласы) төрмәсеннән алып чыгып киткәләр һәм таң алдында, шәһәр читендә аталар.

1

Гранада, Гранада,
Күрәсеңме син? —
Төрмә ишеге ачылды...
Беләсеңме син:

Кемнәрне алып чыктылар
Төрткәләп, тукмап?
Берсе яшь ир, икенчесе
Җитен чәчле карт.

Гранада, Гранада,
Яшьрәк дигәне
Таныш түгелме соң сиңа?
Бар бит күргәнең?

Аның җырын урамнарың
Азмы тыңлады?
Белмисеңме, ник богаулы
Шагыйрь куллары.

Гранада, Гранада,
Шикләнмисеңме?
Август төне дөм караңгы,
Күрмәс, дисеңме.

Гранада, Гранада,
Кара син, кара:
Тоткын шагыйрь күзләрендә
Ялкыннар яна.

Туймастай карый ул күкне, —
Сагынгандыр шул:
Саф һавасыз баздай төрмә
Талдыргандыр шул.

Гранада, күрәсеңме? —
Шагыйрь елмая.
Таң җилләре ирек вәгъдә
Итәме аңа?

Күпчә шагыйрь күңеле белән
Испан җирләрен.
Чәчләрен туздырып исә
Август җилләре.

2

Далада туктый машина.
Шагыйрь шикләнми.
«Август таңы ал комачтай
Алсу икән»,— ди...

Нигә фашист алып китә
Картны бер читкә? —
Ал таңны еркетеп, шартлау
Яңгырап китә.

Сискәнә шагыйрь... һәм аңлый
Нәрсә көткәнен:
Фашистларның нигә таңда
Алып киткәнен.

Унтугызы... Шулай ук бу
Соңгы таңыммы?
Агызырмы франкистлар
Хәзер канымны?

Август таңы, җырларымны
Отып кал да син,
Тарат илгә. Алар җирдә
Ирек дауласын.

3

Офык — алсу, күк — зәп-зәңгәр,
Соклан да соклан...
Шагыйрь чалкан ята җирдә,
Күкрәгендә кан.

Карый... карый зәңгәр күккә,
Алсу офыкка...
Бирешмә... тор, Федерико
Гарсиа Лорка.

Елмай, елмай... дошманнарың
Дер калтырансын.
Юк, үлмәссең... шагыйрьне кем
Үтерә алсын!

4

Курыктылар, җырларыңа
Богау салырга
Теләделәр... Ерткычлыкка
Шаһит таң гына.

Тик сүндерә алмадылар,
Балкыдың гына.
Сәрем таралды да, калды
Ялкының гына.

Юк, үлмәдең... Лорка, сиңе
Мәңгелек көтә:
Үлем аша атладың син
Үлемсезлеккә!

*Рафаэль Мостафин*

# КИЧЕР, ИЛЕМ

*Беренче очерк*

## Үлем үзәнлеге

Аяк астында ябышкак саз пычрагы чыпырдый. Корырак урынны сайлап атларга һич тә мөмкинлек юк — озынборыннар ирек бирми. Алар шундый күп монда — бөтен тирә-як безелдәп-чыңлап тора. Һәм бик әрсезләр үзләре: кулларыбызга агач ботаклары тотып, туктаусыз селтәнеп барсак та, барыбер җаен табып, әле битне, әле колакны, әле муенны чеметеп алалар.

Юлдашым Николай, бу хәлгә күнегеп беткән, ахры, ул әллә ни борчылмый. «Безнең озынборыннар шундый усаллар инде», ди. Ә минем инде күз кабакларым шешенеп, иреннәрем кабарып чыкты...

Һич тә түзәр чама калмагач, башыма сөлге урарга туры килде. Аннары Николай да кесәсеннән хатын-кыз яулыгы алып бөркәнде. Читтән караганда безнең кыяфәт шактый көлке тоеладыр, әлбәттә. Әмма монда көләр кеше юк. Сапер солдатларның соңгы постын үткәннән бирле безгә бер тере җан иясе дә очраганы юк әле. Хәер, кем батырчылык итсен соң монда килергә? Картлар әйтмешли, алла каргаган урын бу. Баскан саен дерелдәп-калтырап тора торган сазлык, кыяк үләне, сирәк, кыска усак һәм куаклардан башка берни юк монда. Усаклары да зифа, төз түгел, кайрылары ярылып, кызгылт күгәрек белән капланган. Һавасы да ниндидер күңел болгаткыч авыр исле. Кошлар да сайрамый, чикерткәләр дә юк, шөпшәләр очканы да күренми. Әлегә дә баягы һаман шул озынборыннар безелдәве генә колак төбендә чыңлап тора да әллә нигә бер Мясной Бор ягыннан, тонык кына булып, шартлау тавышлары ишетелгәләп куя — анда саперлар җирне миналардан арындыралар...

Без Волхов сазлыкларының нәкъ уртасында хәзер.

Акрын гына атлый бирәбез һәм, барган уңайга, Николай миңа бу якларда булган хәлләрне сөйли.

— Әнә тегендә, безнең авыл ягында, минага туры килеп, колхоз үгезе үлде... — ди.

— Бервакыт, әле моннан берничә ел элек кенә, без утырып барган трактор минага туры килде. Бик каты шартлады, әмма, аллага шөкер, барыбыз да исән калдык... — ди.

— Әнә теге усаклар тирәсендә Мясной Борның бер карчыгы минага тап булып күккә очты. Шундук үлгән, әлбәттә... Кара ефәк юбкасының кисәкләре әле һаман ботакта эленеп тора, — ди.

Мондый хәлләрне Николай бик күп белә. Ул миңа әлегә юп һич тә куркыныч түгел дигән булса да, куе үлән эчендәге ватык солдат каскасына яисә чәнечкеле тимер чыбык кисәгенә аяк тигән саен, йөрәк жу итеп китә...

Тар гына сукмак безне инде агачлар ускән бер ташландык юлга алып чыкты. Хәзер алга бару шактый җиңеләйде, чөнки юлга бүрәнәләр түшәлгән иде.

— Икенче удар армиянең фронт юлы булган бу, — дип аңлатты Николай.

Шунысы гаҗәп: чирек гасыр үткән булуга да карамастан, юлга җәелгән бүрәнәләр нигәдер черемәгән. Бөтенләй диярлек сазга батып яткан, каралган һәм лай белән капланган ул бүрәнәләр әле бик нык. Бу хәлне Николай миңа сазлыкның үзенчәлегенә бәйле дип аңлатты. Өстә яткан әйберләр чери, әмма сазга батканнары гасырлар буена сакланырга мөмкин икән.

Алга бару һаман кыенлаша. Чөнки ун-унбиш метр үтүгә, бомба, снаряд, мина чокырлары очрап, юлны бүлә. Аларны әйләнеп үтәргә туры килә. Аннары чокырлар тагын да күбәя һәм урыны-урыны белән җир тоташ чокырлыкка әйләнеп китә. Ул чокырларның барысы да су белән тулган, читләре кыяк үләне, мүк һәм агачлар белән капланган. Әмма Николай бер карау белән аларның нинди бомба, нинди снаряд һәм мина актарганнан хасил булуын әйтеп бирә. «Монысы полк минометы минасыныкы», «Ә менә монысы, һичшиксез, ярты тонналы авиабомба базы», ди ул.

Бу тирәләрдәге тупларны, танкларны һәм, гомумән, эре сугыш техникасын металл ватыгы итеп җыеп алганнар инде. Шулай да куак араларында кәкрәеп беткән туп көпшәләре, зур калибрлы снаряд җимереп ташлаган танк башнялары, янган автомашина калдыклары очраштыргалый әле. Ә җирдә, үлән арасында, чәчелеп яткан мылтык көпшәләренең, снаряд һәм пуля гильзаларының, солдат котелокларының, рус, немец, испан (монда «Зәңгәр дивизия» дә сугышкан) каскаларының исәбе-хисабы юк. Сугыштан соң үскән яшь урман арасында сынып, сыдырылып, янып-көеп беткән, ягъни сугыш дәһшәтен кичергән карт агачлар да очраштыргалап куя.

Николай мине шул агачларның берсе янына алып килде. Шактый юан усакны җирдән дүрт метр чамасы җиреннән, әйтерсең, ниндидер ерткыч чәйнәп ташлаган. Шул дүрт метрлы кәүсәдә уч төбен куярлык та исән урын юк — бөтен җире пуля, снаряд, мина кыйпылчыклары белән телгәләнеп беткән. «Менә, шушыннан чыгып, үзең чамала инде монда сугышның нинди булганлыгын», ди Никслай.

Әйе, шаккатырлык хәлләр булган монда. Шуңа күрә дә Үлем үзәнлеге дип атаганнар инде бу урынны!

Николайның әйтүенә караганда, сугыш беткән елны ук бу тирәләрдә урман кисәргә керешкән булганнар. Әмма тиздән ул эшне туктатырга туры килгән, чөнки, агачларда пуля һәм снаряд кыйпылчыклары бик күп булганлыктан, пычкылар һич тә чыдамаган.

1944 елны безнең гаскәрләр һөҗүмгә күчеп, дошманны куып барганда да, миналар бик күп булу сәбәпле, бу тирәләрне әйләнеп үтәргә мәҗбүр булганнар. Саперлар да шәһәрләрне, авылларны, иген кырларын чистартканнан соң гына килгән монда. Бу урманнар әле хәзер дә минадан арындырылып бетмәгән. Шунлыктан җирле халык Үлем үзәнлеген читләтеп үтеп йөри.

Минем юлдашым һәм озатып йөрүчем Николай Орлов кебек, бу үзәнлектә иркенләп йөри алучылар күп түгел монда.

Мина зарарсызландыру юлларын үзлегеннән өйрәнеп, металл ватыклары җыючыларга, урман каравылчыларына һәм колхоз механизаторларына беренче булып юл салучы да шушы Николай булган.

Менә хәзер дә башына очлы тимер чыбык беркетелгән таягын тотып, бик оста хәрәкәтләр белән җирне капшап бара ул. Мин аның эзенә генә басып барырга тырышам. Кайчак Николайның таягы я снаряд кыйпылчыгына, я гильзага яисә мылтык көпшәсенә тиеп, чыңлап куя. Ә кайчак ярылмыйча калган снарядка яки, бик пөхтә итеп төреп, мылтык патроннары тутырылган цинк ящикларга барып төртелә. Менә ул ярым җимерек һәм эчене су тулган бер иске блиндажны актарды да аннан ниндидер шкалаларга бүленгән, күп кенә боргычлары булган тимер ящик тартып чыгарды. Иплэбрәк карасак, рация икән. Җиңе белән әйбатләп сөрткәч:

— Мәктәп музеена менә дигән экспонат булачак! — дип, Николай рацияне корырак урынга илтеп куйды. Көненә пехотага каршы куелган икешәр йөз мина зарарсызландырган чаклары булган аның. Ә егерме ел эчендә барлыгы күпме снаряд һәм мина зарарсызландыруын ул үзе дә әйтә алмый инде — исәбен югалткан. Чөнки бу — аның өчен гадәти эш.



*Волхов сазлыклары. Николай Орлов элекке миномет позициясе урынында.*

Үлән яки сазлык эчендә таягына орынган әйберләрне актарган минутларда мин юлдашымның йөзенә карап торам. Гел кояшта, җилдә йөргәнлектән бите карасу кызгылт төскә кергән. Карашы тәвәккәл. Сары кашлары һәм керфекләре кояшта уңып, бөтенләй аксылланып калган. Йөзендә гади, гадәти рус кыяфәте. Ләкин менә шушы гади рус егете егерме ел эчендә, дежурдан буш вакытларында, күпме мина һәм снарядны зарарсызландырган, ничә тапкыр үлем белән качышлы уйнаган! Чак кына ялгышлык җибәрсәң дә — дөнья белән саубуллаш дигән сүз бит аның бу һөнәре!

— Куркыныч түгелме соң сиңа? — дип сорадым мин Николайдан.

— Башта, билгеле, куркынычрак иде. Әмма соңыннан ияләштем. Кайсы мина белән ничек эш итәргә икәнен өйрәнгәч, бер нәрсәсе дә юк, юлда яткан ташны читкә алып ташлау кебек кенә.

Николайның сүзләренә ышансам да, аның берәр минаны зарарсызландырганын күрергә теләвемне әйттем.

— Була ул! — диде Николай, һич тә исе китмичә. Һәм шундук юлдан читкә чыгып, урманга кереп китте.

— Кирәкми, Николай! — дидем мин, ник әйткәнемә үкенеп.

Николай әллә ишетте, әллә юк — җавап бирмәде. Һәм, үтте микән биш-алты минут, кулына ниндидер зур бер табак сыман әйбер тотып, әйләнеп тә чыкты. Аннары аны тәкәллефсез генә җиргә ташлады. Мин, шартлар дип шикләнеп, күземне йомдым. Әмма бернинди дә шартлау булмады. Күземне ачкач, Николай әлеге табакка тибеп куйды да, көлеп:

— Курыкмагыз! Шартлаткычын алдым инде мин аның! — диде. — Немец минасы бу. Тимер юлны шартлатырга дип алып килгән булганнар, ләкин шартлатырга җитешә алмаганнар. Әнә анда, — ул куаклар артына ымлады, — бик күп өелеп ята мондый миналар.

— Хәзер дә кеше сөякләре очрыймы әле? — дип сорадым мин Николайдан, үземне шушы гаҗәеп зур музейда экскурсант хәлендә тоеп.

Ул, бер сүз дә дәшмичә, мине заманында бик авыр бомба төшүдән барлыкка килгән, ә хәзер инде кечерәк бер күлгә әйләнгән зур чокыр буена алып килде дә:

— Әнә, күл читенә кара әле! — диде.

Башта мин анда нинди дер аксыл-соргылт ташлардан башка берни дә күрмәдем. Ләкин соңыннан, текәлебрәк карый торгач, ул ташлар таш түгел, бәлки кеше башы сөякләре булып чыкты.

— Кемнәр икән соң болар? — дип соравыма җавап итеп, Николай чокыр тирәсендә яткан күгәргән штык һәм черегән шинель кисәкләренә төртеп күрсәтте. Штыкларның өч кырлы булуын һәм шинель төймәләрендә биш почмаклы йолдызларны күргәч, мәсьәлә ачыкланды — ул сөякләрнең совет сугышчыларыныкы икәнлегенә шигем калмады.

Миңа ничектер кыен, куркыныч булып китте. Үлем белән беркайчан да болай күзгә-күз очрашканым юк иде әле минем. Кемнәрнеңдер аталары, абыйлары һәм уллары булган бит инде бу мәетләр! Коточкыч хәл бит бу! Заманында минем кебек үк, безнең кебек үк исән булган, көлгән, шаярган, эшләгән һәм кемгәдер гашыйк булган кешеләр ята бит бу чокырда! Араларында рәтләп яшәргә дә, хәтта сөяргә дә өлгермәгәннәре дә бардыр әле. Һәм инде шуларның сөякләре генә калган! Алары да таркала башлаган инде. Шушында килеп үлү өчен туганмыни алар бу якты дөньяга? Ә бит минем үз әтием дә моннан әллә ни ерак түгел җирдә — Ленинград тирәсендә — үлеп калган һәм аның да кабере билгеле түгел. Ул да шушы мәрхүмнәр язмышына дучар булмагандыр дип кем әйтә ала миңа?.. Уйлый башласаң — акылдан язарлык!

— Узган ел, күмү командасы эшләгән вакытта, бу урыннарда су күбрәк иде. Хәзер су кимегән һәм сөякләр күренә башлаган, — диде Николай, минем сораулы һәм борчулы карашыма җавап итеп. — Хәрби комиссариатка бу турыда йөз тапкыр әйткәнмендер инде. Бигрәк тынгысыз кеше син дип, анда миңа хәтта үпкәләп тә бетteләр. Ленинградка да яздым. Шушы араларда күмүчеләр килеп җитәргә тиеш.

Николай таягы белән күл төбен төрткәләп карады һәм, төрткән саен, таяк кеше сөякләренә бәрелә иде.

— Киттек, — дидем мин, аның җиңеннән тартып, — тимә, кузгатма инде син аларны, борчыма...

Аннары без, бер-беребезгә сүз катмыйча гына, әрсез озынборыннар белән кәрәшә-көрәшә, ян-якларында снаряд гильзалары, ватык машина һәм туп калдыклары чәчелеп яткан күңелсез юлыбызны дәвам иттек.

## Һәлакәт боҗрасында

Чирек гасыр элек бу урыннарда бик авыр канлы сугышлар булган. 1942 елда Волхов тирәсендә камалышта калган Икенче удар армиянең фаҗигале язмышын һәм аның баш командующие генерал Власовның хыянәтен өлкән буын кешеләре әле дә яхшы хәтерлиләр.

Волхов операциясе 1942 елның 7 январенда, армиябез һәм халкыбыз, бөтен көчен туплап, немецларны Мәскәү тирәсеннән куып җибәргәннән соң башланды. Ставканың фикере буенча, Икенче удар армия, Волхов һәм Ленинград фронтларының башка армияләре белән берлектә, дошман оборонасының эченә үтеп керергә һәм Ленинградтан көньяк-көнчыгышта тупланган немец гаскәрләренең зур группасын чорнап алып туздырып ташларга, шулай итеп, Ленинградны блокададан коткарырга тиеш була.

1942 елның январь ае урталарында Икенче удар армия гаскәрләре Мясной Бор районында дошман оборонасын өзүгә ирешәләр. Коточкыч кыен шартларда, билдән кар ерып, совет сугышчылары һөҗүмне һаман үстерә баралар һәм, дошман оборонасына җитмеш километрдан артыграк эчкәре кереп, Любань станциясенә килеп җитәләр. Әмма Любаньны кулга төшерә һәм дошман гаскәрләрен тулысынча чолганышта калдыра алмыйлар. Алай гына да түгел, Икенче удар армия үзе дошман чолганышында кала.

Шулай да, бик күп югалтулар бәрабәренә, 1942 елның мартында безнең гаскәрләр бер урыннан дошман боҗрасын өзеп, киңлеге өч-дүрт, озынлыгы унбиш кило-

метр чамасында коридор ачалар һәм шул коридор буйлап Зур җир белән элемтә урнаштыралар. Ләкин ике ягы да дошман кулында булган бу коридорга зур ышаныч баглау мөмкин булмый, чөнки аның теләсә кайчан ябылып куюы бар. Шунлыктан хәзер я һөҗүмне дәвам иттерергә, яки бу куркыныч урыннан гаскәрләрне тизрәк алып чыгарга кирәк була. Ләкин әлеге ике мөмкинлекнең берсе дә тормышка ашырылмый.

1942 елның язы бу якларга бик иртә килә. Апрельнең беренче көннәрендә үк кар эри башлый. Икенче удар армиянең танклары, туплары, машиналары һәм, гомумән, бөтен хәрби техникасы сазлыкларга батып кала. Бик тиз эреп беткән кар сулары, болай да сазлы, баткаклы җиргә сеңәргә өлгермичә, армия урнашкан үзәнлеккә җәелә һәм, шунлыктан, сугышчыларга окоп казырга да, алгы сызыкка азык-төлек, сугыш кирәк-яраклары китерергә дә мөмкинлек калмый. Узган кышта төзелгән тар колеялы тимер юл да дошман күзәтүе астына эләккәнлектән, армиянең хәле бөтенләй начарлана. Бүтән чара калмагач, ашыгыч рәвештә сазлыкка агач җәеп юл сала башлыйлар. Ләкин, ул чорда немец авиациясенең көче әле зур булганлыктан, бу юллардан да бары төнлә генә хәрәкәт итәргә туры килә.

Май аеның соңгы көннәрендә немецлар безнең авыр хәлдәге гаскәрләрне тагын да ныграк кысрыклый башлыйлар һәм тиздән әлеге тар коридорны бөтенләй ябып ук куялар.

Чолганышта калган гаскәрләрнең хәле хәзер аеруча кыенлаша: сугыш кирәк-яраклары, азык-төлек җитми башлый. Армиянең сугыш кирәк-яраклары тупланган төп склады да дошман самолетлары тарафыннан бомбага тотылганнан соң, тупларны һәм минометларны ач паекка калдырырга туры килә. Солдатлар да ачлыктан интегә башлый. Чолганыштагы гаскәрләргә самолетлардан парашют белән сугыш кирәк-яраклары һәм азык-төлек ташлау да тиешле нәтиҗәгә китерми: Волхов якларында июнь төннәре якты булганлыктан, дошманның зенит артиллериясе самолетларга парашют төшерер өчен түбәнәергә ирек бирми, ә югарыдан төшергән әйберләрнең күбесе немецлар кулына эләгә.

Әнә шундый кыен шартлар булуга да карамастан, Икенче удар армия сугышчылары дошманга айдан артык каршылык күрсәтәләр. Әмма немецлар, боҗраны һаман кечерәйтә барып, безнең гаскәрләрне Новая Кересть һәм Мясной Бор авыллары арасындагы сазлы үзәнлеккә кысрыклап кертәләр. Соңыннан бу районга Үлем үзәнлеге дигән исем бирелә.

Үзәнлектә дә совет сугышчылары дошманга бик каты каршылык күрсәтәләр. Канлы сугышлар көн-төн дәвам итә. Безнекеләр һәр куак, һәр агач өчен батырларча сугышалар. Немецлар бу районга минометлардан һәм туплардан да туктаусыз атып торалар, күктән дә әледән-әле һөҗүм ясап, бомба яудыралар. Шулай барлык төр кораллардан бик озаклап атканнан соң, инде тере җан иясе калмагандыр дип булса кирәк, фашистлар котырынып атакага ташланалар. Әмма сазлыкта яткан исән совет сугышчылары тагын дошманга каршы күтәреләләр һәм аны чигенергә мәҗбүр итәләр.

Югалтулар ике якта да көннән-көн арта бара. Ахыр чиктә немецлар барлык резервларын, хәтта писарьларын, санитарларын, танкистларын һәм очучыларын да атакага җибәрәләр. Ниһаять, июньнең соңгы көннәрендә немецлар чолганыштагы безнең сугышчыларны тәмам кысрыклап, ваграк төркемнәргә таркатуга ирешәләр. Әмма сугышлар һаман дәвам итә. Кайда фронт, кайда тыл икәнлеген дә аерып булмый башлый. Мәсьәлә бары тик июль башында гына хәл ителә.

Армиянең капитуляция ясавын рәсми төстә формалаштырып, Власов үзенең штабы белән дошман ягына күчә. Немецлар аны кочак җәеп каршы алалар. Әмма сугышчыларга андый мөгамәлә күрсәтелми. Тимер юл районындагы госпитальгә тупланган ун меңнәрчә сугышчыны кулга алгач, немецлар аларның йөри алганнарын (андыйлар, хәер, күп булмый) хәрби әсирләрне җыю пунктларына куып алып китәләр, ә йөри алмаганнарын гранаталар белән шартлатып, автоматлардан атып үтереп бетерәләр.

Николай мине элек шул госпиталь урнашкан җиргә алып килде. Ул алан хәзер кеше биеклеге кура һәм үләннәр белән капланган инде. Әмма андагы җирне актарып карасаң, һәркайда сөяк, сөяк, сөяк. Шулай караштырып йөргән чакта ярым җимерек

бер блиндажга юлыктык. Анда рәттән җиде-сигез кеше скелеты ята иде. Барысының да я бер, яки ике аягы да юк. Аяк урынында гипс белән катырылган бинт кисәкләре генә. Һәм барысының да баш сөякләрендә пуля тишекләре. Күрәсең, автоматтан атып үтергәннәрдер. Алардан бераз читтәрәк ятканы хатын-кыз скелеты булырга тиеш. Чөнки аның янында таралып яткан чәчләр дә озын, кирза итекләре дә кечерәк размерлы. Ихтимал, санитарка яисә хәрби врач булгандыр. Блиндаж стенасына сөяләп утырган килеш үлгән ул. Күрәсең, яралы сугышчыларны ташлап китәргә теләмәгәндер.

Волхов тирәсендәге операция уңышсыз тәмамланса да, дошманның Ладога күле ягыннан Ленинградны тәмам камап алырга әзерләнгән зур көчен үзенә җәлеп итеп, аның сайлап алынган иң шәп дивизияләрен шактый хәпсезләндерә ул. Күрәсең шуңардыр, әле күптән түгел генә Волховка килеп киткән бер хәрби начальник, Ленинградны саклап калучыларга һәйкәлне Мясной Борга куярга кирәк, дип әйтте, ди Николай.

Ләкин мин монда Икенче удар армиянең тарихын тикшерү өчен килмәдем. Мине башка нәрсә — шушы җирдә дошманга каршы сугышкан һәм әсир ителгән шагыйрь Муса Җәлилнең язмышы кызыксындыра.

Шагыйрьнең үз хатларындагы һәм шигырьләрендәге мәгълүматлардан тыш, Җәлилнең ул чордагы тормышы хакында озак еллар буена бер нәрсә дә билгеле булмады диярлек. Сугыштан соң хәтта шагыйрь үзе теләп әсир төшкән, имеш, дигән гайбәт сүзләр дә таралды. Соңыннан ачыкланды: ул гайбәтне таратуга гитлерчылар үзләре булышлык иткән булып чыкты.

Тегель төрмәсендә утырган чакта Әхмәт Симаев бер тоткынга Дрезденда уникe җәлилчегә суд ясалуын сөйли. Суд җәлилчеләрнең барысына да «үлемгә хөкем ителделәр» дигән карар чыгара. Аннары закон кагыйдәсенә туры китерү йөзеннән, судья җәлилчеләргә соңгы сүзләрен әйтергә кушкан. Тоткыннар бер тавыштан: «Үтенечебез бер генә — безнең турыда дөреслекне туган илдә дә белсеннәр иде!» — дип җавап биргәннәр. Судья, астыртын елмаеп: «Илегездә сезне бары тик сатлык җаннар һәм хыянәтчеләр буларак кына беләчәкләр», — дигән аларга.

Патриотларның дәрәҗәсен төшерү, аларга карата шик тудыру максаты белән, фашистлар хәтта ялган документлар уйлап чыгаралар. Менә шундый хәлләр аркасында совет патриотлары эшләгән эшләрнең асылын ачыклау шактый кыенлаша һәм озакка сузыла. Җәлил исеме китап һәм дәреслек битләреннән югалып тора. Аның атаклы «Алтынчәч» операсы да театрларда либреттоның авторы күрсәтелмичә генә куела.

Хәтта соңыннан, дөреслек җиңеп, тиңдәшсез батырлыгы өчен шагыйрь хөкүмәтнең югары бүләге — Советлар Союзы Герое дигән исемгә лаек булгач һәм аның «Моабит дәфтәрләре»нә Ленин премиясе бирелгәч тә Муса Җәлилнең кайда, кайчан һәм нинди шартларда әсир ителүен озак вакытлар белә алмадык без. Ю. Корольковның инде берничә тапкыр басылып чыккан популяр китабында Җәлилнең бу чордагы тормышы күп нокталар белән генә билгеләп үтелгән. Җәлил турында художестволы әсәр язган авторлар да шагыйрьнең нинди шартларда һәм кайда әсир ителүен үз хыялларында ничек күргән булсалар — шулай сурәтләү белән генә чикләнеп килделәр. Шәйхи Маннурның «Муса» романында, мәсәлән, шагыйрь, отряд белән берлектә, үтә алмаслык сазлыкны кичеп чыгарга омтылган чакта әсир ителгән итеп сурәтләнә. Шул ук моментлар Н. Җиһановның «Җәлил» операсында бөтенләй башка рәвешле чагылдырыла. Менә шушындый төрлелек, әлбәттә, укучыларда хаклы борчылу тудырып килде.

Бу мәсьәләне бары тик чын, дөрес фактлар нигезендә генә ачыкларга мөмкин иде. Һәм ул фактларны эзләү башланды.

Волхов вакыйгаларыннан соң унбиш ел үткәч, журналист Лев Шилов «Отвага» дигән армия газетасының очраклы рәвештә генә сакланып калган саннарында Муса Җәлилнең шигырьләре белән мәкаләләрен таба. Аннары ул кыр почтасы номеры буенча «Отвага»ның исән калган сотрудникларын эзләргә кереша. Нәтиҗәдә сотрудникларның күбесе Волхов тирәсендәге сугышларда һәлак булганлыгы ачыклана. Исән калган берничә кеше дә табыла. Шуларның берсе, «Отвага»ның редактор урынбасары Лев Моисеев, Мусаның ничек итеп Икенче удар армиягә эләгүен сөйләп бирә.

Моисеев заманында Мәскәү университетында Муса белән бергә укыган һәм электән үк аны яхшы белгән. Ул башыннан ук Волхов операциясендә катнашкан кеше. 1942 елның апрель башларында чолганышта калган безнең гаскәрләр инде укучыга мәгълүм булган тар гына коридорны ачканнан соң, кәгазь һәм азык-төлек алырга дип, фронт штабына чыккан ул һәм фронт штабы урнашкан Малая Вишера урамы буйлап барган вакытында, һич тә көтмәгәндә, Муса Җәлилне очраткан. Шунда алар озаклап сөйләшеп киткәннәр. Моисеев Җәлилгә Икенче удар армиянең авыр хәлдә икәнлеген, әгәр эшләр яхшырмаса, язгы җылы көннәр башлану белән гаскәрләрнең сазлыкта батып калачагы котылгысыз булуын сөйләгән. Ә Муса аңа үзенең резервта эшсез торуын һәм тизрәк фронтка китәргә теләвен әйткән. Моисеев, үз редакцияләрендә штат тулы булмавын, бер сотрудник — хәрби корреспондент кирәк икәнлеген әйтеп, Мусага шул урынны тәкъдим иткән. Җәлил моңа бик теләп риза булачагын әйткәч, алар шундук фронт политбүлегенә барганнар. Политбүлек аларның үтенеченә каршы килми. Ә икенче көнне Муса белән Моисеев Икенче удар армия урнашкан җиргә юнәләләр.

Һәр ике ягыннан да немецлар туктаусыз агып торган тар коридор буйлап көндез хәрәкәт итү куркыныч булганлыктан, Җәлил һәм аның юлдашлары, утлары сүндерелгән машиналарга утырып, юлга төнлә чыгалар. Мясной Бор тирәсенә җиткәч, колонананы сизенеп, фашистлар бик каты ут ача. Алдагы машина ватылып, колонна туктап кала. Кирегә борылу да, читләтеп үтү дә кыен — кар тирән. Шулай да, нинди могҗиза беләндер, редакция машинасы бу җәһәннәм авызыннан исән-сау үтеп китә. Ә иртәгесен колоннадагы машиналар барысы да диярлек дошман тарафыннан кырылып беткәнлеге мәгълүм була.

Лев Моисеев сөйләгән бу вакыйгада игътибарга лаеклы бик мөһим бер деталь бар: аның әйтүенчә, Муса Җәлил Икенче удар армиягә үзе теләп киткән. Ул участоктагы кыенлыкларны күрсәтеп, анда бармаска киңәш итүләренә дә карамастан, Муса үз сүзендә торган!

Бу мәсьәләгә мин шуның өчен аеруча басым ясап әйтәм, чөнки Шәйхи Маннур романында Муса билгеләнгән урынына һич тә теләмичә, бары тик приказга буйсынып кына бара итеп сурәтләнә:

«Андагы хәлләр белән Муса резервтан ук таныш иде, шуңа күрә бу ут капчыгына барып керү аңа бер дә ансат булмады. Бүтән фронтлар инде язгы оборонага күчкән, тик монда гына, үч иткән шикелле, ут бураны котыра. Әмма нишләмәк кирәк, башың солдат булгач, кәҗәләнеп эш чыкмый, приказга буйсынасың». («Казан утлары» журналы. 1965 ел. № 5. 3 бит.)

Әйе, армия штабы резервында торганда Муса Икенче удар армиянең хәле нинди булуын бик яхшы белә. Үзенең эшсез йөрергә мәҗбүр булуы турында Моисеевка сукранганда да буяуларны артыграк кертеп сөйли. Ул чорда язган хатларына карaганда, Җәлил резервта Моисеевка сөйләгәнчә үк тик ятмаган, бәлки еш кына командованиенең аеруча кыен махсус заданиеләрен үтәгән, алгы сызыкка да баргалап йөргән, хәтта бервакыт чолганышта да кала язган. Димәк, бу мәсьәләдә аның намусы чиста булган. Әмма беренче мөмкинлек килеп чыгу белән, ул ут эченә китә.

1942 елның 6 апрелендә «Отвага» газетасының корректоры А. И. Обыдена үзенең көндәлегенә түбәндәге сүзләрне язып куйган:

«Моисеев М. Вишерадан кайтты. Дуңгыз ите һәм М. Җәлил исемле яңа сотрудник алып кайткан».

Обыдененың иң элек ит, аннары гына Җәлил турында язуына гаҗәпләнергә кирәкми — ул чакта армия генә түгел, редакция сотрудниклары да ачлыктан интегә.

Обыдена күңелендә Муса тыйнак, гади, артык күп сөйләшми торган кеше буларак сакланып калган. Аның сөйләве буенча, Муса гадәттә кайры тун һәм итек киеп йөргән; редакциядә утыруны яратмаган, һәрвакыт диярлек Икенче удар армия частьларындагы солдатлар арасында мәкаләләр язу өчен материал җыеп йөргән.

Обыдененың 1942 елның 28 апрелендә язылган көндәлегендә менә мондый юллар бар: «Любаньнан 30 километр чамасындагы Огорелье авылы. Без монда инде байтактан торабыз. Кошлар сайрый, торналар кычкыра. Кичә Муса яз чәчәкләрен җыеп кайтты. Искиткеч матур чәчәкләр, әмма исемнәрен беркем белми. Җәлил каен суы

җыярга өйрәтте һәм без барлык савыт-сабаны каеннарга элеп куйдык. Ул судан чәй кайнатабыз, ботка әзерлибез. Дачадагы кебек бүген: тып-тын. Давыл алды тынлыгы микәнни?»

Ә менә көндәлекнең икенче бите:

«Кичә тыныч иде, ә бүген төн буе һәм төшкә кадәр, бер генә минутка да туктамыйча, куркыныч артиллерия канонадасы яңгырап торды... Кичә төнлә барысы да йоклыйлар иде, тик мин генә йокламыйм, машинадан полосалар килүен көтеп утыра идем. Шул чак палатага Җәлил килеп керде. Ул яңа гына алгы сызыктан кайткан икән. Фронттагы күңелсез хәлләр йокысын качыруын әйткәч, ул миңа шигырьләрен укый башлады. Башта татарча укыды. Аннары мин аңа шигырьләре әйбәт яңгыравын, әмма татарча белмәвем сәбәпле аларның мәгънәсен төшенә алмавымны әйткәч, ул шундук русчага тәрҗемә итеп укырга кереште. Бик нәфис, ягымлы аның шигырьләре. Күбесе — лирика. Аннары бала чагында шактый авыр булган тормышы, беренче мәхәббәте һәм өзелеп яраткан кызы — Чулпан турында сөйләде».

Шуннан соң күп тә үтми, штат кыскартылу нәтиҗәсендә, Обыденаны Малая Вишерага күчерәләр һәм, шулай итеп, ул коридор ябылудан элегрәк чолганыштагы армиядән китеп кала.

Менә Җәлилнең шул чорларда язган үз хаты. Вакытлар үтү нәтиҗәсендә саргаеп беткән ике бит дәфтәр кәгазе. Карандаш белән язган юлларга күз төшерү белән үк авторның бу хатны ашыгыч һәм уңайсыз урында язганын абайларга була. Хатның бер битендә кара тап, күрәсең, землянка түбәсеннән тамган күгәрек саз тамчысы эзедер. Бәлки, якын-тирәдә генә ярылган снаряд яисә мина чәчрәткән пычрак кисәге эзедер. Әмма хатның сүзләрен танып була әле:

«Кашшаф дус!

Бүген синең 22 майда язган хатыңны алдым. Кыска гына итеп булса да сиңа җавап язып салырга ашыгам. (Инде караңгы төшеп килә. Биредә, урманда, төнлә гадәттәге тормыш туктала, башка бер серле хәрби тормыш башлана.)

...Мин хәзер чын мәгънәсендә хәрби шартларда, алгы сызыкта бик еш булам. Дошманның ут нокталары яныннан ук, кулыма автомат тотып, бик хәтәр урманнар, сазлыклар һәм мәгарәләр аркылы узам. Хәрби корреспондент булу — тыныч кына бер эш түгел ул, бер үк вакытта сугышырга да, язарга да туры килә...

...Куркыныч дошман белән бик нык сугышасылар бар әле. Нәтиҗәләре турында язармын.

Хәзергә сине кочып,
Муса».

«Сугышасылар бар әле», — дип язса да, Муса ул сугышларның нәтиҗәсе турында хәбәр итә алмый инде — бу аның фронттан язган соңгы хаты була.

Моннан алданрак язган хатларның берсендә Муса Җәлил Г. Кашшафка тиздән ун-унбишләп җыр һәм шигырьләрен җибәрәчәген хәбәр итә (моңа кадәр дә барлык шигырьләрен язып бетерү белән үк Кашшафка җибәреп тора ул, «чөнки, — дип яза Җәлил, — төрле хәлләр булуы мөмкин: юл йөргәндә дәфтәрне генә түгел, аннан зуррагын да (мәсәлән, башны) югалтып куюың бар». Әмма соңгы хатта вәгъдә ителгән шигырьләр Кашшафка килми. Җәлил аларны җибәргәнме, юкмы — без белмибез.

Чолганышта калган армиянең Зур җир белән элемтәсе башта самолетлар ярдәмендә алып барылган. Әмма элемтә самолетларының барысы фронт сызыгын үтеп чыга алмаган шул... Кем белә, бәлки, шагыйрьнең ул шигырьләре кыр сумкасында, кайдадыр Волхов сазлыкларында ятып калгандыр...

«Отвага» газетасында художник булып эшләгән скульптор Евгений Вучетич Җәлилнең үзе тарафыннан русча язылган уннан артык шигыре шул газетада басылып чыкканлыгын сөйләсә дә, әлегә ул шигырьләрнең берсе генә табылды. Гадәттә, барлык армия һәм фронт газеталарының мәҗбүри экземплярлары Армиянең Баш политидарәсендә сакланырга тиеш. Әмма ул газета армиянең ахыргы көннәренә кадәр системалы рәвештә чыгып килсә дә, барлык саннары да тиешле урынына барып җитә алмаган.

Соңгы штурм алдыннан, башка яшерен документлар белән бергә, «Отвага»ның барлык саннары теркәлгән подшивканы да сейфка салып, кайдадыр урманга күмеп

калдыралар. Сугыштан соң, махсус комиссия килеп, ул сейфны эзләп караса да, таба алмый.

Сейфны эзләүдә Николай Орлов та катнашкан икән. Аның уенча, эзләүнең уңышсыз тәмамлану сәбәбе шунда, чөнки комиссия файдаланган мина эзләгечләр бер метр тирәнлектә яткан әйберләрне генә «таба», ә сейфның метр ярым-ике метр тирәнлеккә күмелгән булуы мөмкин. Үз мина эзләгечен яхшыртып, сейфны яңадан эзләп карарга хыяллана Николай...

Чолганыштагылар 22 июньдә дошман оборонасын штурмлый башлыйлар. Штурм шундый каты һәм кискен була — дошман түзә алмыйча, каушап кала. Шуннан файдаланып, безнекеләр боҗраны бер җиреннән өзүгә ирешәләр. Шул ачыклыктан беренче чиратта авыру һәм яралыларны чыгаралар, аннары, оешкан төстә, частьлар чыга башлый. Шул чакта «Отвага» газетасының исән калган 24 хезмәткәренең өчесе чолганыштан чыгып кала. Ләкин чыгучылар арасында Муса Җәлил булмый. Ә кичкә немецлар өзекне яңадан ябалар. Муса һәм аның иптәшләре боҗра эчендә кала...

## «Чаян чага үзен соңгы чиктә»...

...Менә шул вакыйгалардан соң егерме еллар чамасы вакыт үткәч, Татарстан дәүләт музеена мәһабәт гәүдәле, әйбәт киемле өлкән яшьләрдәге бер кеше килеп керә дә, экспонатларны карый-карый, заллар буйлап йөри башлый. Менә ул Ватан сугышы чорын чагылдырган экспонатлар янына килеп җитә һәм, өлкән политрук формасында эшләнгән Муса Җәлил портретын күреп, тукталып кала.

— Муса! — ди ул, байтак карап торганнан соң, — Җәлилов!

Һәм күзләреннән яшь бәреп чыга. Аннары ул шунда үзе янына җыелып өлгергән кешеләргә Муса белән бергә Волхов фронтында сугышып йөргәнлеген сөйли һәм шагыйрьнең нинди хәлдә әсир ителгәнлеген әйтә. Аңарчы да герой шагыйрь Муса Җәлил турында ишеткән булган ул. Әмма политрук Җәлилов һәм шагыйрь Муса Җәлилнең бер үк кеше икәнлеген белмәгән.

Чит шәһәрдән килгән бу кешенең сүзләрен кызыксынып тыңлап торган экскурсовод кыз аны Җәлилнең иҗатын һәм тормыш юлын тикшерүче Гази Кашшаф янына җибәрә.

Җәлилнең фронттагы соңгы көннәрен белүче шаһитләрнең берсе Иван Павлович Паньков әнә шулай табыла. Хәзер Приморск авыл хуҗалыгы институты доценты, тарих фәннәре кандидаты И. П. Паньков 1942 елның язында Икенче удар армия составындагы 59 нчы аерым укчы бригаданың политбүлегендә өлкән инструктор булып хезмәт иткән. Шул чорда, политработник һәм пропагандист буларак, «Отвага» газетасына да мәкаләләр язгалап торган. Хезмәте буенча Икенче удар армия штабына, Огорелье авылына килгән вакытларында гел редакциягә кергәләп йөргән. Менә шунда, 1942 елның апрель азакларында, аны яңа сотрудник — урта буйлы, җиңел сөякле һәм шат күңелле политрук Муса Җәлил белән таныштырганнар. Паньков үзе дә Идел буенда (Чувашиядә) туып үскән кеше булганлыктан, алар Җәлил белән бик тиз аңлашып киткәннәр. Соңыннан да я редакциядә, я армия штабында, яки алгы сызыкта бик еш очрашып, сөйләшкәләп йөргәннәр. Бервакыт икесе бергәләп (Муса газетага материал җыярга, ә Паньков политәңгәмәләр үткәрергә) 59 нчы укчы бригаданың алгы сызыктагы батальоннарына да барып кайтканнар.

Волхов фронтында хәлләр кыенлаша барган. Азык-төлек китерү мәсьәләсе аеруча читенләшкән. 1942 елның май ахырларында, армия инде чолганышта калганнан соң, Паньков Мусаны Горки авылы тирәсендә очраткан. Элеккечә шат күңелле, житез хәрәкәтле булса да, Мусаның инде шактый ябыгып, суырылып калуын күреп, Паньков аның хәлен сораштырган. Муса аңа каефе болай ярыйсы икәнлеген, әмма, күптәннән икмәк күргәне булмаганлыктан, тешләре карала һәм селкенә башлавын әйткән.

59 нчы укчы бригадага 24 июньгә каршы төндә Теремец-Курляндский авылы тирәсендә сугыш башлап, боҗраны өзеп чыгарга боерык бирелә. Боҗраны башлап бригаданың өченче укчы батальоны өзәргә, калган частьлар аның артыннан хәрәкәт итәргә тиеш була. Алга куелган бурычның аеруча мөһим икәнлеген искә алып, башлап

барачак батальонны көчәйтү нияте белән, армия штабындагы политработникларны һәм офицерларны да шунда җибәрәләр. Алар арасында Муса Җәлил дә була.

Төнге сәгать унберләрдә дошман позициясенә атака башлана. Немецлар моңа бик көчле ут белән җавап бирәләр. Батальон тагын берничә тапкыр күтәрелеп карый. Политработниклар һәм командирлар да, кулларына мылтык тотып, солдатлар белән бергә алгы сафта булалар. Әмма немецлар бик нык каршылык күрсәтә...

Чираттагы атакага ташланган вакытта (иртәнге сәгать өч, яктырыла башлаган чак була бу), шартлагыч пуля тиеп, Паньковның сул аягы яралана.

— Мин яраландым, итегем эчендә кан! — ди Паньков, үзе белән янәшә барган Мусага мөрәҗәгать итеп.

— Түз инде бераз, мине дә тырнап үтте, ахрысы, — ди аңа Муса.

Һәм алар бергәләп батальонның уң флангысына, агачлар куерак, пулялар азрак очкан сыман булып тоелган урынга юнәләләр. Әмма шул вакыт куак арасыннан моңарчы сизелмәгән немец пулеметы тыкылдарга тотына. Паньков җиргә сыена, ә Муса, куакларга ышыкланып, пулеметка таба шуышып китә. Бераздан соң колак тондыргыч туп һәм пулемет тавышлары эчендә Паньков кемнеңдер җан өзгеч ачы итеп кычкырганын ишетә. Муса кычкырган төсле тоела аңа. Ул да булмый, Паньков янында гына нәрсәдер бик каты шартлый һәм ул аңын югалта... Аның сөйләвенә караганда, Муса Җәлил нәкъ менә шул 24 июнь иртәсендә әсир итела.

Паньков соңыннан нишли соң?

Ул аңына килгән чакта, кояш чыгып шактый югары күтәрелгән була инде. Озынборыннар тешләвенә һәм ярасы авыртуга түзә алмыйча, көч-хәл белән генә икенче ягына әйләнеп ятарга азапланган чагында, мәетләр өстеннән атлап килүче ике немецны шәйләп ала. Тегеләр дә моны күрәләр һәм берсе, атып үтермәкче булып, автоматын төзи дә башлый. Ләкин икенчесе, Паньковның киемендәге командир петлицаларын күреп, иптәшенең автоматын читкә этәрә. Офицерларны, бигрәк тә өлкән офицерларны, терелэй алган өчен немецларга бүләк бирелергә тиеш. Шунлыктан әлеге ике немец автоматчысы, кычкыру-ыңгырашуына һич тә игътибар итмичә, Паньковны, яралы аягыннан сөйрәп, җыю пунктына алып китәләр.

Хәрби әсирләр лагерена Паньков менә шулай эләгә. Бәхетенә каршы, немецлар аның батальон комиссары икәнлеген белмиләр, майор дип уйлыйлар, югыйсә, белгән булсалар — шундук атып үтергән булырлар иде. 1942 елның октябрендә Тапс исемле эстон шәһәрчеге тирәсендә оештырылган хәрби әсирләр лагерена бер фашист агенты килеп төшә. Ул генерал Власов командалыгы астында фашистлар тарафыннан оештырыла башлаган «Рус азатлык армиясе»нә әсирләр җыярга килә. Озын, таза гәүдәле, аксыл-сары чәчле, симез битле ул агент әсирләрне Власов армиясенә язылырга өнди башлый. Язылган кешеләргә җәннәт рәхәтлекләре булачагын вәгъдә итә.

— Ышанмагыз шул әшәке сатлык җанга! Ул сезне илгә хыянәт итәргә өнди! — дип кычкыра Паньков, тегенең ялганына түзә алмыйча.

Паньковны шундук сафтан сөйрәп чыгаралар да эт урынына кыйнап ташлыйлар. Бер ай салкын карцерда тотканнан соң, аны Маутхаузенга озаталар. Иван Павлович Гитлер тәмугының барлык төрләрен үз җилкәсендә татый. Фашистларның, брандспойттан су сиптереп, генерал Д. М. Карбышевны боз статуяга әверелдерүләрен дә күрә ул. Лагерьның яшерен интернациональ комитеты члены итеп тә сайлана. Атаклы Маутхаузен восстаниесе планын төзүдә һәм аны әзерләүдә дә катнаша. Ә туган илебезгә кайткач, Иван Павлович үзенең элекке һөнәренә — иҗтимагый фәннәр укыту эшенә керешә.

И. П. Паньковның истәлеген Гази Кашшаф үзенең Җәлил турындагы мәгълүм китабына керткән иде. Әмма ул китап басылып чыгарга өлгермәс борын ук, Гази Кашшафка ТАССР Верховный Советы Президиумыннан бер хат тапшыралар. Элек Икенче удар армиядә хезмәт иткән, ә хәзер Нижний Тагил шәһәрендә яшәүче Аркадий Русских язган хат була ул.

Хатта әйтелгәнчә, 1942 елның язында А. Русских Икенче удар армия штабында сакта хезмәт иткән һәм редакция эшләре белән штабка еш кына килгәләп йөрүче Муса Җәлиловны да белгән. Җәлилов күбесенчә итәкләренә пычрак чәчрәп беткән

шинель киеп, автомат асып килә иде, күрәсең, алгы позицияләргә еш барып йөргәндер, дип яза Русских.

Июньнең егермеләрендә немецлар армия штабы урнашкан Новая Keресть авылын һәм шул авыл тирәсендәге аэродром хезмәтен үтәгән басуны басып алалар. А. Русскихның әйтүенә караганда, авыл немецлар кулына эләгүдән берничә сәгать элек кенә, солдатлар сафы каршына бастырып, аэродромда унлап дезертир һәм мародерларны аталар. Аларны атканда Муса Җәлил дә аэродромда була.

21 июнь кичендә чолганыштан берәм-берәм яки вак төркемнәргә бүленеп чыгарга боерык бирелә. Чөнки күмәкләп чыгарга һич тә мөмкин булмый.

«Барыбыз да эндәшми генә таралыштык, — дип яза Русских. — Мин ялгызым киттем, әмма омтылышым барып чыкмады. Артиллерия утын читләтеп үтмәкче булып барганда немецларга юлыктым. Бәхеткә каршы, алар миңа атмадылар, кулларын изәп, үзләре янына килергә чакырдылар. Әсир төшү була бит бу! Шул уй күңелемә килде дә тиз генә читкә йөгердем. Шөкер, исән калдым. Нишлисең бит, сугыш булгач — төрле хәлләр була. Бүтән карарга килеп, урман эчләтеп тар тимер юлга таба киттем. Шунда барышлый Мусаны очраттым. Бераз сөйләшкәч, икәү бергә китәргә булдык. 1942 елның 22 июнь иртәсе иде бу. Артиллерия утына эләкмәс өчен, сулгарак каерылып, ике километр чамасы төньякка таба китәргә өлгерсәк тә, немецлар белән очрашудан котылып булмады. Иртәнге тынлыкны бозып, башта пулеметлар тыкылдый башлады, аннары вак миналар яварга тотынды. Без тиз генә бер чокырга яттык. Безгә пуля тию ихтималы зур түгел, әмма, миналар шартлавы тынып торган арада, немецларның: «Рус, бирел!» дигән тавышлары ишетелә башлагач, бу чокырда озак ятарга мөмкин булмады. Я әсир буласың, яисә маңгаеңа пуля аласың дигән сүз иде монда яту. Немецлар башларын калкыта алмаудан файдаланып, безгә, тәвәккәлләп, йөгерә-ята бу тирәдән сызарга туры килде һәм, үттеме икән биш минут, без яткан чокырга төрле яклап снарядлар ява башлады. Безнекеләр дә, немецлар да аталар иде. Шулай итеп, Муса белән мин ике ут уртасында калдык. Ләкин әсирлек үлемнән куркынычрак, һәм без, шуышып, юлыбызны дәвам итә башладык, чөнки басарга түгел, баш калкытырга да мөмкинлек юк. Бөтен дөнья шаулап-селкенеп тора. Берничә «юнкерс» килеп чыгып, сиреналарын акыртып, түбәннән генә очып үттеләр. Без төньякка, үзебезнекеләргә таба байтак җир киткән идек инде. Ләкин тагын алдыбызда немецлар калыкты һәм автоматларыннан ут сиптерергә тотындылар. Мин аударып ташланган бер кечкенә паровозны күрдем һәм, Мусаны әйдәп, ышыкланмакчы булып, шуңа таба йөгерә башладым. Ләкин Мусаның артымнан килүе сизелмәде. Борылып карасам, ул егылып ята, күрәсең, пуля тигәндер. Немецлар күзе алдында аның янына барырга һич тә мөмкин түгел иде, әлбәттә. Ул арада тагын миналар коела башлады. Шул чак якындарак кына торган бер ватык немец танкысын күреп алдым. Берничә сикерүдә аның янына барып та җиттем һәм, артиллериядән ату тукталганчы шунда утырып торырга ниятләп, эченә кердем. Күрәсең, сизенми калганнардыр — немецлар танкка атмадылар. Ләкин юлдашыма нәрсә булганын белә алмадым мин: танктан бер нәрсә күреп булмый, ә чыгарга һич тә мөмкин түгел — бик каты атыш бара иде.

Кичен, атышлар тына төшкәч, танктан чыгып, Муса егылып калган җиргә барып карадым. Әмма Муса анда юк иде инде. Димәк, ул үлмәгән, үлсә — гәүдәсе булыр иде. Димәк, ул яраланган һәм немецларга эләккән. Ләкин мин нишли ала идем соң?..[1]»

Аркадий Русских, ничек итсә итә, әмма чолганыштан чыгып котыла. Аннары, ахырына кадәр диярлек сугышта йөри, кече лейтенант дәрәҗәсенә күтәрелә, берничә тапкыр яраланып, госпитальләрдә ятып чыга.

А. Русскихның бу хәбәре белән бер үк вакытта диярлек, Мусаның ничек әсир ителүе турында өченче версия дә мәгълүм була.

Әсирлектә булган Салих Ганиевнең әйтүенә караганда, ул 1942 елның көзендә хәрби әсирләр лагеренда Муса Җәлил белән очрашкан һәм шунда Муса аңа үзенең ничек әсир ителүен сөйләгән.

---

[1] Бу хакта Г. Кашшаф заманында радио һәм телевидение аша чыгышлар ясаган иде инде.

26 июньдә булган бу хәл. Башкача берничек тә максатларына ирешә алмагач, чолганыштан агач түшәлгән юл буйлап, автомашиналар колоннасы белән, Мясной Бор юнәлешендә чыкмакчы булалар. Муса штаб машинасынамы, редакция машинасынамы утырып бара. Ләкин немецлар колоннаны сизеп алалар һәм котырынып ут ачалар. Машиналар тирәсендә миналар ярыла башлый. Җәлил юлдашларының күбесе я үлеп, яки яраланып бетә. Мина кыйпылчыгы тиеп, Җәлилнең дә сул иңбашы яралана һәм шартлау дулкыны аны читкә алып ыргыта.

Аңына килгәндә аны немецлар урап алган була инде.

«Кичер, илем!» исемле шигырендә Муса үзен-үзе үтерергә теләвен әйтә. Әмма Ганиевкә бу хакта берни дә сөйләми. Әгәр шагыйрь сазлыкка егылган булса, аның «сугыш дусты — пистолеты» нигә хыянәт итүен аңлау кыен түгел, әлбәттә.

Дошманга терелэй бирелмәү хакында Муса элек тә уйлаган булса кирәк. Гази Кашшафка язган хатларының берсендә «Соңгы патрон турында баллада» язуын искәртеп үткән ул. Шагыйрьнең ул шигыре безгә килеп җитә алмаган, әмма анда сүз, күрәсең, үзенә билгеләнгән соңгы пуля хакында баргандыр.

Шагыйрьнең ярасын бәйләгән Салих Ганиевнең сөйләве буенча, Мусаның сул як иңбаш сөяге яньчелгән һәм сул кулы хәрәкәтсез калган булган. Моннан тыш, Җәлилнең шул ук сул як күкрәгендә әле төзәлеп үк җитмәгән пуля ярасы эзе дә күренеп торган. Пуля аның йөрәге тирәсеннән, әмма артык тирәнгә кермичә, тәнен сыдырып үткән булган. Җәлилнең үтенүе буенча, Салих Ганиев аның яралы күкрәгенә массаж да ясаган. Бәлки, шагыйрьнең бу ярасы И. Паньков сөйләгән яра булгандыр?

С. Ганиевнең әйтүенә караганда, башта Муса үзен бик начар хис итә. Бик авырлык белән генә йөри, эшли алмый. Әсирләрне эшкә алып чыккан вакытларда иптәшләре аны баракта дневальный итеп калдыралар. Аны әледән-әле политрукларны һәм еврейләрне эзләп торучы немецлардан яшерәләр, лагерьдан лагерьга күчкән вакытларда аңа ярдәм итәләр.

«Эзләү дәвам итә» исемле китапны бастырып чыгарырга әзерләгәндә әлеге өч версиянең кайсына тукталу хакында Гази Кашшаф белән бик күп уйландык без. Ниһаять, соңгысына тукталырга булдык, чөнки анысы шагыйрьнең үз авызыннан сөйләнгән.

Ә калган икесе ничек? Алары дөреслеккә туры килмимени? Алай дип әйтергә бернинди дә нигезебез юк иде.

Без китапны әзерләп яткан чорда «Литературная газета»да тимер юл караучы Николай Орлов дигән бер кешенең Волхов урманнарында үлеп калган солдатларны эзләү белән шөгыльләнүе турында мәкалә басылды. Адресын табып, Орловка хат яздык һәм аның безгә дә ярдәм итүен үтендек. Орлов озак көттермәде. Безгә хат язып, Волхов тирәсендәге сугышларда катнашкан кешеләрнең истәлекләрен, адресларын соратып алды. Ә берничә айдан соң кыска гына итеп: «Килегез. Мин кайбер нәрсәләр таптым, ахрысы», дип хәбәр итте.

Һәм менә без хәзер аның белән әлеге сугыш булган урыннарда йөрибез. Николай теге өч версиянең берсен дә кире какмый.

— Менә монысы Аркадий Русских хатында язган урын, — ди ул, мине элек Икенче удар армиянеке булган тар тимер юл буенча алып килеп, — әнә тегендә, Новая Kересть авылында, армия штабы, ә менә бу юнәлештә аэродром кыры булган.

А. Русских хатында язылган барлык детальләр дә дөреслеккә туры килә. Без хәтта ул искә алган кечкенә паровоз ватыкларына кадәр таптык. Бары тик Русских яшеренеп ятарга мәҗбүр булган танкны гына табып булмады. Күрәсең, ул бик нык ватылмаган булгандыр һәм немецлар аны төзәтеп, үзләре белән алып киткәннәрдер.

— Русских хатында язылган вакыйга кайчан булган? — ди Николай, кулларын селки-селки. — 22 июньдә. Ә Муса Җәлилне әсир иткәннәрен үз күзе белән күргәнме соң ул? Юк, күрмәгән. Димәк, ул шагыйрь тормышының бер сугышчан эпизодын гына язган.

Әйе, Аркадий Русских дөресен сөйләгән. Әмма бу әсир ителү түгел бит әле.

Иван Павлович Паньковның хаклыгы да шул рәвешле нигезләнде. Дөрес, Николай аның сүзләрендә кайбер төгәлсезлекләр тапты табуын. Ләкин соңыннан, Паньков белән языштканнан соң, мәсьәләне бик ансат ачыкладык без.

Николайның әйтүе буенча, нәкъ менә Паньков истәлегендә язган урыннарда узган ел күму командасы эшләгән. Нибары ике-буе икешәр йөз метрлы участоктан гына да команда биш йөздән артык мәет сөякләрен җыеп күмгән. Чолганышны өзү өчен менә шунда бик каты сугышлар булган. Бу урында күп мәртәбәләр йөргән Николайның фикеренчә, монда һәлак булган кешеләр арасында өлкән офицерлар да күп. Чөнки, ди ул, мәет сөякләре янында офицер каешы калдыклары бик еш очрый иде. Ә кайбер мәетләрнең күкрәк кесәләре турында төсле карандашлар күренүен дә әйтте ул. Ихтимал, Паньков искә алган штаб офицерлары булгандыр алар.

Шулай итеп, Паньков истәлеге безгә Җәлилнең 23 июньнән 24 июньгә каршы төндәге фронт тормышының тагын бер моментын ачыклап бирә. Бәлки, Җәлил нәкъ менә шул төнне беренче мәртәбә пуля ярасы алгандыр. Ләкин бу да әсирлеккә төшү түгел бит әле. Мин Салих Ганиев сөйләгән сүзләр турында хат язгач, Паньков: ихтимал, шулай да булгандыр, чөнки Мусаны тотып алуларын үз күзем белән күрмәдем, дип җавап бирде. Хәер, кычкырган тавыш — Җәлил тавышы иде дип раслый ул. Ләкин төнлә туп, мина, мылтык тавышлары арасында кем кычкырганын төгәл генә аерып карагыз...

Хәзер өченче шаһит турында берничә сүз. Волхов тирәсендәге сугышларда катнашкан кешеләрнең истәлекләренә карaганда, чыннан да, 25 июньдә эшкә яраклы барлык автомашиналарга бoҗрадан чыгарга боерык бирелгән булган. Боҗрадан чыгу өчен сугыш 26 июньдә дә дәвам иткән. Ләкин аннан гаскәрнең бик аз өлеше генә чыга алган. Машиналарның күбесе дошман утына очраган һәм Глушица белән Полисть елгалары арасындагы чиктә тукталып калырга мәҗбүр булган.



*Мясной Бор янындагы урман. Муса Җәлил пленга төшкән урын шушы булырга тиеш.*

Язучы Риза Ишморатка әле 1944 елда ук Черных дигән бер капитан белән очрашырга туры килгән (кызганычка каршы, ул капитанны һаман таба алганыбыз юк әле). Сөйләве буенча, Черных Җәлил белән бер машинада утырып барган. Ихтимал, 25—26 июньнәрдә чолганыштан чыгарга омтылып барган колонна булгандыр ул. Менә шунда, кыска гына тукталыш вакытында, Җәлилне каядыр эш белән җибәргәннәр. Ул китүгә, колоннага кузгалырга боерык бирелгән. Черных машинага утырган, ә Муса килеп җитәргә өлгерми калган. Күрәсең, башка машинага утыргандыр ул. Черных шул көнне боҗрадан чыгу бәхетенә ирешкән. Шуннан соң ул Җәлилне күрә алмаган...

Николай Орлов Волхов вакыйгалары чорында очраклы рәвештә Икенче удар армия хәрәкәт иткән җиргә килеп эләккән бер хатынны табып сөйләшкән. Әйтүе буенча, ул хатын да немецлар машиналар колоннасын утка тоткан урында 25—26 июньнәрдә әсирлеккә эләккән. Хәрби кеше булмаса да, башка әсирләр белән бергә, аны да Чудово тирәсендәге Сябреницы авылында оештырылган әсирләр лагерена куып алып килгәннәр. Ул хатын Николайга җимерек машиналар янында фашистларның бик күп яралы сугышчыларны әсир итүен һәм аларны да Сябреницыга куып китерүләрен сөйләгән.

Аннары, шул хатын ярдәме белән, ватык машиналарның үзләрен дә тапкан Николай. Мясной Бордан җиде-сигез километрда агач түшәлгән юлда туздырылып ташланган булган алар. Шул ватык машиналарның берсе тирәсендә ике язу машинасы һәм үлән арасында чәчелеп яткан типография шрифтларын да тапкан Орлов.

— Бәлки, Муса Җәлил утырып барган редакция машинасы булгандыр ул, — ди Николай.

Без машинага якынрак киләбез. Юлдан утыз метрлар чамасы читтә ята ул. Юлга туктаусыз мина һәм бомбалар төшеп торганга, монда кергән булгандыр, күрәсең. Машинаның моторы тетелеп беткән, кабинасының да урыны гына калган. Әрҗәсе һәм көпчәкләре дә янып беткән. Әмма янында чокыр-фәлән күренми. Күрәсең, аңа тигән мина бик зур булмагандыр, югыйсә аударып ук ташлаган булыр иде. Әнә машина янында Николай әйткән ике язу машинасы да ята. Ә типография шрифтлары күренми, чөнки җир өстен куе үлән каплаган. Аларны табам дисәң, яз көне, әле үлән калыкмаган чакта килергә кирәк.

Ватык машинаны фотога төшердем дә уйга калдым. Кем белә, бәлки, шагыйрь нәкъ менә шушы урында яраланып, кан эчендә яткандыр. Үзем шулай уйланып басып торам, ә колакта Җәлилнең ялкынлы шигъри юллары яңгырый:

Язмыш көлде, үлем кагылмыйча
Үтте яннан минем тирәләп.
Нишлим, нишлим, соңгы минутымда
Пистолетым итте хыянәт!

Чаян чага үзен соңгы чиктә,
Бөркет ярдан түбән ташлана.
Мин соң бөркет түгел идеммени,
Баш ияргә шуннан башкага!

Ышан, илем, шундый бөркет идем,
Мин дә, соңгы минут килгәндә,
Әзер идем мәгърур канат җәеп
Ташланырга ярдан түбәнгә.

Нишлим, сугыш дустым — пистолетым
Соңгы сүздән кинәт баш тартты.
Богау салды дошман кулларыма
Һәм хурлыклы юлдан атлатты.

● ● ●

Ибраһим Салахов

# Давыллар, утлар аша

*Укучыларга тәкъдим ителә торган түбәндәге ике очерк редакциягә төрле юллар белән килеп керде. Аның берсен — Усман ага Әбдрәшитов турындагысын — язучы Ибраһим Салахов тапшырды. Язучы туксан яшен тутырып килгән Усман ага белән якыннан таныш булган, күп мәртәбәләр аны күреп сөйләшкән һәм нәтиҗәдә «Давыллар, утлар аша» очеркы дөньяга килгән.*

*Журналист Әсгать Хәмидуллин белән «Индустриальная Караганда» газетасы редакторы В. Скоробогатов тәкъдим иткән икенче бер очерк та Усман агага турыдан-туры бәйле булып чыкты.*

*Журналыбызның бу санын планлаштырганда бу ике очерк ничектер янәшә туры килде. Игътибар беләнрәк күз салсак, очеркларда сурәтләнгән геройларның яшәгән урыннары да, фамилияләре дә бер икән: аталы-уллы түгелме соң болар?*

*Әйе, шулай булып чыкты, ата һәм ул журнал битләрендә очраштылар.*

*Ләкин очраклы түгел бу очрашу!*

*Усман ага Әбдрәшитов үзенең ярты гасырдан артык гомерен революция эше өчен, кешелек дөньясының якты киләчәге өчен багышлаган. Ул шатлыкларны да, кайгыларны да ил белән бергә кичергән, ул халыкның үз улы.*

*Ә аның улы Нияз — әтисе көрәштә яулап алган бәхетле тормыш хакына, халыкның бәйсезлеге өчен кулына корал тотып дошманга каршы көрәш сафына баскан һәм шул көрәштә газиз башын салган батыр.*

*Димәк, алар икесе дә әсәрләрнең герое булырга да, халык күңелендә үзләренә урын алырга да лаеклы.*

*Усман ага да, аның улы Нияз да инде безнең арабызда юк. Ләкин аларның исемен халык тирән мәхәббәт белән үзенең йөрәгендә саклый, илебез аларны зурлый. Халыкның аларга булган менә шушы тирән ихтирамы, мәхәббәте аталы-уллы бу ике патриотны журнал битләренә китерде, аларны очраштырды.*

Менә тагын бер документ... — диде Усман ага акрын гына һәм ябынып яткан юрганы өстендәге укучылар сумкасыннан бер бит кәгазь тартып чыгарды. Аның ике ягы да язылган. Үзе саргаеп, таушалып беткән. Усман ага бу кәгазьне әйләндереп-әйләндереп бик җентекләп карады, бөкләнгән почмакларын төзәтте, җыерчыкларын сыйпап тигезләде. Аннан соң ул, шул кәгазьне ике куллап күз алдында тоткан киләш, хәрәкәтсез калды. Әүвәле мин аны укый икән дип уйласам да, җентекләбрәк карагач, аптырап киттем: күзләр йомылган. Әллә инде йокымсырап? Әллә...



Усман ага Әбдрәшитов. 1920 елдан КПСС члены. Беренче рус революциясенә, Кукчәтау өязендә Совет власте урнаштыруда актив катнашкан кеше. Актив селькор. Нияз Әбдрәшитовның әтисе.

— Фәридә! — кинәт ул башын күтәреп кычкырып җибәрде. — Минем папиросларны алып кил әле. Ә син, улым, менә бу кәгазьне укый тор.

Озын, ябык куллар миңа теге саргайган кәгазьне суздылар. Фәридә — озын буйлы, бик җыйнак гәүдәле, урта яшьләрдәге ханым — Усман аганың кызы — бер пачка «Беломор» һәм шырпы китерде.

— Әти, сиңа тартырга ярамый бит...

— Уйларымны бүлдермә әле, — диде ул, ачулы тавыш белән. Папиросын кабызды. Озак итеп суырды. Аннан авызыннан күп итеп төтен чыгара-чыгара, әле һаман китәргә базмыйча басып торган кызына карап елмайды. — Ачуланма инде, кызыкай. Менә туксанны тәгәллим дә ташлыйм. Син нәрсә басып торасың, бар, самоварыңны куеп җибәр.

Фәридә атасына карап башын чайкады да көлемсерәп аш өенә чыгып китте. Минем кулымда борынгы контора кенәгәсеннән ертып алынган бер бит кәгазь. Заманында шәмәхә кара белән язылган юллар төсен югалткан. Кайбер хәрефләр, хәтта сүзләр танымаслык дәрәҗәгә килгәннәр. Бу документка инде 59 яшь. Ә аның хуҗасына биш айдан түп-түгәрәк 90 яшь тулачак.

Менә ул яткан урыныннан торып, кровать янындагы өстәлгә ике кулы белән таянган да уйга талган. Озын. Ябык. Әле күптән түгел генә кырынган булуына карамастан, аның битендә ап-ак төкләр тырпаеп тора. Кашлары да ике ак канат булып салынып төшкәннәр. Анда-санда ул аларны күтәреп куя һәм зур, соргылт күзләр ялтырып китәләр.

— Я, укы әле, улым.

Мин теге кәгазьне күземә якынрак китереп укый башлыйм.

*«Дмитрий Андреевич!*

*Без, Атбасар станицасында яшәүчеләр, шәһәр обывательләре хокукында сезне түбәндәгеләрне таләп итәргә вәкаләтле саныйбыз:*

*1. Безнең туганнарыбызга һәм иптәшләребезгә тулы амнистия бирсеннәр... Бөтен халык эше өчен көрәшүчеләр азатлык алсыннар.*

*2. Алла законына каршы килә дип, үлем җәзасын бөтенләйгә һәм тулысынча юкка чыгарырга.*

*3. Законга каршы килә торган һәм күп газаплар күргән рус халкының дәрәҗәсен төшерә торган хәрби кыр судларын, хәрби хәлне, көчәйтелгән һәм гадәттән тыш сакларны хәзер үк юкка чыгарырга.*

*4. 1905 нче елның 7 октябрь Манифестында вәгъдә ителгән ирекләрне тормышка ашырырга, чөнки аларны безнең туганнарыбыз үзләренең газиз каннары белән яулап алганнар һәм бөтен рус халкының яхшы тормышы һәм гаделлеге өчен үзләренең тормышларын корбан иткәннәр.*

*5. . . . . . . . . . . . . суд каршында тигез булсыннар, суд халыкныкы һәм хөкүмәткә бәйсез булырга тиеш.*

*6. Без сайлаган халык вәкилләре алдында да, бөтен халык алдында да хөкүмәт җаваплы булсын.*

*7. Халык мәгарифе барлык гражданнарга түләүсез булсын, түбәнге катлауларга да, урта катлауларга да кысынкылык булмасын, уку дәүләт исәбенә булсын. Мәктәп чиркәүдән тулысынча аерылсын.*

*8. Хосуси биләүлек, кабинет . . . . . . . . . һәм монастырь җирләре тулысынча тартып алынсын. Җир бөтен халыкныкы булсын. Җир мәсьәләсен бөтен халык хәл итсен.*

*9. Туры налоглар да, читләтеп салына торган налоглар да тулысынча бетерелсен һәм прогрессив налог белән алмаштырылсын.*

*10. Крайның культурасын һәм тормыш хәлен күтәрү өчен безнең край аркылы, казна исәбенә, тимер юл салынсын.*

*11. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .*

*12. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .*

*13. Киләчәктә сайлаулар . . . . . . . . . яшерен һәм барлык кешеләр өчен тигез булсын.*

*14. Атбасар уезлында дәүләт ярдәме белән проектлаштырылган яңа шәһәр хәзер үк салынсын.*

*15. Без үзебезнең барлык ихтыяҗларыбызны дәүләт башлыгына һәм үзебезнең халык вәкилләренә ышанып тапшырабыз.*

*Атбасар станицасы, 28 январь,*
*1907 ел».*

Имзалар — гарәпчә, русча, төрле шәкелдәге тамгалар һәм баш бармак эзләре. Мин укуымны дәвам итәм: «Нурмөхәммәт Әбдрәшитов, Георгий Яков, Мәхмүт Булатов, Сәетов, Петр Казакин, Кәрим Фпяров, Иван Бородин, Ефим Клочкинның сорвы буенча кул куйдым (танылмый), Феофан Шипенко, Усман Әбдрәшитов...»

Барысы иллегә якын имза. Татарлар, казакълар, руслар. Кәгазьне кулымда тоткан килеш, уйга калдым. Уйланмаслык та түгел бит. 1907 елда, бишенче ел революциясе дулкыннарының инде басылган чагында, Столыпин реакциясенең котырган чорында, Акмулла губернасы хәрби хәлдә исәпләнеп кулга алулар барганда, дәреслэп имзаларын да куя белмәгән бер төркем кешеләр бөтен Россия монархы алдында менә нинди кыю политик таләпләр куялар.

— 1907 елда, — диде Усман ага, минем уйларымны бүлеп, — икенче дәүләт Думасына сайлаулар башланды. Бу сайлаулар бик катлаулы иде. Шуның өчен без турыдан-туры аңа катыша алмадык. Омскида булачак Думага сайлау җыелышына без бары үзебезнең вәкилне генә җибәрә ала идек. Менә без Атбасар округыннан үзебезнең сайлаучы — выборщик итеп Дмитрий Андреевич Ушаковны сайладык. Аңа менә шушы наказны бирдек һәм аны Думага җиткерергә куштык.

Ул тагын тәмәке кабызды, аннан ашыкмыйча гына үткән көннәрне искә төшерә башлады.

* * *

— ...Таң алдыннан безнең шхуна тәрек ярларына килеп җитте. Төштек. Балыкчылар мине ниндидер җимерелгән курганнар арасыннан алып бардылар да куыш янында учак ягып, балык пешереп утырган бер карт янында калдырып югалдылар. Күрешеп, сәламләшкәннән соң, карт сораштыра башлады.

— Бу караңгы төндә улым кайда юл тота икән?

— Бәйрут шәһәренә, ата.

— Ул ерак, шәриф шәһәрдә сине хөрмәтле ата-аналарың көтеп зарыгалармы?

— Юк, хөрмәтле ата. Мин әле ул шәһәрнең кайда икәнен дә белмим. Бәлкем, сез чит җирдән килгән егеткә шул Бәйрут исемле шәһәргә бара торган юлны күрсәтеп шатландырырсыз.

— Юлчыга юл күрсәтү фарыз эш. Әмма мин бу яшь егетнең ул шәһәрдә кемне эзләвен белер идем. Бәлкем, ул үзенең гүзәл ярын эзлидер?

— Юк, ата. Минем эзләгәнем гыйлем. Мин Бәйрут шәһәренә барып укырга телим.

— Афәрин, — карт балыкчы шатланып минем аркамнан кагып куйды, — белем эзләү изге эш. Әмма... — кинәт ул сүзен бүлеп урыныннан торды да учак янына

куелган чүлмәктәге суны ут өстенә түкте. Тирә-якка алтын очкыннар чәчелде. Учактан пышылдап пар күтәрелде. Тирә-як кап-караңгы булып китте. Бары еракта, кара бәрхеттәй күк өстендә йолдызлар җемелди. Аларның нурлары күгелҗем һәм салкын. Менә кинәт, күзгә ком сибеп, җил исеп китте. Курган артыннан ниндидер тонык, басынкы тавыш ишетелде. Әйтерсең лә, арыслан ыңгыраша. Юк, бу дулкын тавышы. Мәрмәр диңгезенең дулкыннары шулай тавышланып ярга сугылалар.

— Әйдә, улым, куышка керик, — дип карт мине җитәкләде дә, як-ягына каранып, өстәп куйды, — монда янычарлар була...

— Юк, улым, Бәйрутка барып җитә алмассың шул, — диде карт, камыш җәйгән идәнгә йокларга яткач. — Тотсалар үтерерләр. Солтанның фәрманы шундый. Бигрәк тә ул Русиядән килгән кешеләргә үчле.

Икенче көнне карт мине, үзенең балыкчы дуслары янына көймәгә утыртып, кирегә Севастопольгә озатты.

— Үтмәс товар, кире кайттыңмы,— дип, өйдә әти ачуланып каршы алды. Үги әни кабакларын да күтәрмәде, эндәшмәде дә. Алар минем өйдә булуымны, өйләнеп хуҗалыкта эшләвемне телиләр иде. Ә мин әллә кайдагы Бәйрутка кузгалдым. Безнең хәлфәләр: «Дөньяның иң атаклы мәдрәсәләре Бәйрут шәһәрендә», — диләр иде. Мин шунда омтылган булдым. Шулай да бу уңышсыз юлның файдасы да булды. Гүя күземне каплап торган пәрдәне кисеп алдылар. Мин дөньяны тирәнрәк, ачыграк итеп күрә башладым. Нужа безнең Иман-Тауда гына түгел, Кара диңгез, Мәрмәр диңгезе ярларында да бер үк шәфкатьсезлек белән халык өстенә баса һәм эшче-крестьяннарга тын алырга да бирми икән. Севастополь, Баку, Батум портларындагы сыгылып торган траплар буенча тау-тау йөкләрне ташучы эшчеләр нужага каршы бергәләп көрәшәләр икән. Менә шулар инде минем күземне ачтылар да...

1902 елны Усман Әбдрәшитов тагын ата йортын ташлап китә. Ул бу юлы Атбасар станицасына барып, Россия транспорт һәм страховка җәмгыятенең агентлыгына яллана. Чит җирләрдә күп йөрү аркасында Усман инде русча сөйләшергә, аз-маз язарга да өйрәнгән була. Өстәвенә ул бик тырышып эшли. Шуңа күрә икенче елны җәмгыять идарәсе аны агентлыкның начальнигы итеп билгели. Бу вакытта Атбасарда сөргенгә җибәрелгән күп кенә политик гаепләләр яши. Усман уезд начальнигы писаре Лонгов, врач Кулагин, пар тегермәненең механигы Ушаков белән аралаша. Атбасарның прогрессив карашлы кешеләре: Сабир Шәрипов, Адельбик Майкутов һәм бертуган Сутюшевлар: Кәрим, Хәмит, Мәҗит, Газиз белән таныша.

Менә шуларның тырышлыгы белән 1903 елда Атбасарда уку йорты ачыла. Монда татарча спектакльләр куела, әдәби кичәләр уздырыла. Анда-санда түләүле спектакльләр, концертлар да була. Шуннан җыелган акчага Казаннан китаплар һәм газета-журналлар алдыра башлыйлар.

Атнасына бер тапкыр, җомга көнне, бу уку йортының актив членнары чираттагы репетициягә җыелалар. Тәрәзә пәрдәләре төшерелә, ишекләр ябыла, капка төбенә бер дежурный да куела. Шуннан соң, Дмитрий Андреевич Ушаков һәм Кәрим Сутюшевлар төрле политик китаплар укыйлар. Тыңлаучылар арасында Усман Әбдрәшитов та була.

— ...1905 елгы җәмгыятьнең идарәсе мине Петропавел шәһәре агентлыгы башлыгы итеп күчерде. Тынгысыз һәм шау-шулы еллар иде ул. Бер көнне Кәрим Сутюшев (ул монда тимер юл идарәсендә эшләргә күчкән иде) мине урамда очратып, кичкә безнең якка килеп чык әле дип, адрес бирде.

Ул әйткән йорт Петропавел шәһәрендә социал-демократлар җыела торган конспиратив урын икән. Монда мин дә йөри башладым. Оешманың бик күп актив членнары белән таныштым. Минем күңелемдә аеруча тирән эз калдырган иптәшләр: әз сүзле, тәвәккәл Михаил Иванович Казаков һәм матур, батыр кыз Калюжная булды. Бу йортка «Васыль» кушаматлы бер украинлы егет тә килә иде. Питердагы, Мәскәүдәге революцион хәрәкәтләр турында кызыклы чыгышлар ясый иде.

Беркөнне шулай, чираттагы җыелыш бетеп тарала башлаганда, минем яныма Кәрим килде:

— Усман, кара әле, — диде ул шыпырт кына, — синең белән безнең Касаткин дигән бер якын иптәшебез кызыксына. Иртәгә эштән соң безгә кереп чык әле.

— Ярый, — дидем.

Кем ул Касаткин? Сорарга кыймадым. Шулай да икенче кичне Кәримнәргә килдем. Ул капка төбендә көтеп тора икән. Каршылап өенә алып керде.

— Менә, иптәш Касаткин, таныш булыгыз, — диде.

Озын буйлы, ябык кына ак чырайлы егет урыныннан торып, миңа кул бирде. Таныштык. Бу егетнең миңа бигрәк тә чәчләре ошады — озын, кара, бөдрәләнеп, күперәп торалар иде алар.

Озак кына сөйләшеп утырдык. Ул Омскидагы һәм Кукчәтаудагы социал-демократлар оешмасының эшләре белән таныштырды һәм милли халык арасында, бигрәк тә татар эшчеләре арасында, революцион эшне көчәйтеп җибәрү һәм аны җитәкләү турында сөйләде. Яшь кенә булса да үзен бик җитди тота, фикерләрен кыска итеп, дәлилләр белән беркетеп әйтә. Сүз ахырында ул миңа транспорт конторасы аркылы революцион әдәбият һәм листовкалар тарату кирәклеген белдерде. Мин бу эшне башкарырга сүз бирдем.

Безнең контора аркылы Россиянең барлык почмакларына товарлар китә. Менә шуларны озатканда ящикларга, тюкларга пакетлар сала торган булдык. Аларның тышына «Кызыклы яңалыклар» дип язып та куя идек.

Кәрим Сутюшев миңа соңыннан гына әйтте: бу яшь егет Валериан Владимирович Куйбышев булган икән.

...Гүзәл һәм данлыклы ул Имән-Тау станицасы. Әле аңа барып җиткәнче үк, берничә ун чакрымнан, ерак офыкта күгелҗем тау тезмәләре күләгәләнә. Анда бара торган юл киң, такыр. Әйләнә-тирәдә күз күременнән еракка сузылган чиксез, тигез дала — дулкынланып торган кылганлы дала. Тик ара-тирә, уйсулыкларда гына, үенга төшкән кызлар кебек, яшел куләмәкле яшь каеннар төркеме күренеп кала.

Менә соңгы үр. Сез күтәреләсез дә гаҗәпләнеп туктап каласыз. Нәкъ каршыгызда озын буйлы төз наратлар басып тора, әйтерсең лә, кубанкаларын кырын салган яшь казаклар. Алар рәт-рәт булып тезелгәннәр дә туктаусыз каядыр баралар һәм баралар төсле. Менә аннан күтәрелә башлыйлар. Зур крепостьны алырга омтылган солдатлар кебек ярларны, биек кыяларны урап Казан-Тауга, нәкъ аның түбәсенә кадәр күтәреләләр. Казан-Тауның итәгендә күл. Ул бик озын һәм киң. Диңгез кебек җәелеп ята. Күлнең уртасында зур утрау. Аның ярлары — биек кыя ташлар. Әнә шул кыяларга, канатларын җәеп баласын саклап торган бөркет кебек, мәһабәт, сирәк наратлар баскан. Утрауның нәкъ уртасында дулкынланып торган яшел үлән, хәтфә булып түшәлеп яткан артыш агачлары. Күзләрне камаштыра торган, төрле төстәге чәчәкләр һәм сулап туя алмаслык шифалы хуш ис.

Казан-Тау итәгендәге наратлар күләгәсендә йортлар. Бик күп йортлар. Урамнар. Менә шул үзе инде Имән-Тау станицасы. Станицаның уртасыннан, аны нәкъ икегә ярып, кечкенә генә инеш ага. Инешнең бер ягында — урман буенда — татарлар яши. Икенче ягында, басуга таба — руслар. Бүленеп утырганнар. Берсе берсенә дошманнармы? Юк. Монда андый милли дошманлык һичкайчан да булмаган. Бу станицада торучылар барысы да казаклар — Себер атаманы гаскәрендә хезмәт итүчеләр. Алар өйрәнүләрдә дә бергә булганнар һәм дошманга каршы һөҗүмгә дә бергә барганнар...

* * *

Усман ага бу якларның гүзәллеген сөйләгән арада, Фәридә безгә кечкенә касәләрдә кофе алып керде. Тәмләп карыйм әле дип, бер генә йотым капкан идем, туктый алмыйча, төбенә кадәр эчеп бетердем. Усман ага ашыкмады. Бер-ике генә йотты да касәне читкәрәк этеп куйды. Без байтак кына вакыт сүзсез утырдык.

— Тукта әле, — кинәт ул миңа сорау белән карады, — без кай җирдә туктадык әле?

— Сез Валериан Владимирович белән очрашуыгыз һәм аның...

— Әйе, әйе. Куйбышев заданиесе турында. Менә, шайтан алгыры, хәтер чуала башлаган бит. Яңа гына сөйләдем, шуны онытканмын да. Эх, картлык баса, ахрысы. Соңгы вакытта үземдә кызык бер үзгәреш сизә башладым. Элек мин сөйләргә яратмый идем. Гел эш артыннан йөгерә идем. Хәзер берәр кеше күрдемме — әңгәмә. Үткәннәрне искә төшерә башлыйм. Бәлки, кайбер кешеләр Усман үзенең данын күпертергә маташа, ди торганнардыр. Юк, мин андыйлардан түгел. Мин үткәнне сөйләгәндә, үземнең иптәшләремне искә төшерәм. Алар белән тагын очрашкандай булам. Юк, бик күп иптәшләр юк инде... һәлак булдылар. Кайсылары төрмәдә, каторгада, ә кайсыларын аттылар...

Кайберәүләр, бигрәк тә яшьләр: «Казак — ул патшаның камчысы, аның иң ышанычлы терәге», — дип уйлыйлар. Юк. Алай түгел шул. Дөрес, казакларның бер төркеме, бигрәк тә офицерлар, бай казаклар, патшага җаны-тәне белән бирелеп хезмәт иттеләр. Әмма шул ук вакытта казаклар арасында патша хөкүмәтенә нәфрәт белән караучы, туктаусыз аңа каршы көрәш алып баручы казаклар да аз түгел иде. Менә мисал өчен беренче Себер казак полкының хәрби врачы Виноградовны алыйк. Ул большевиклар группасы оештырды, казаклар арасында революцион эш алып барды. Революциянең беренче көннәрендә үк бу полк Советлар ягына чыга. Ә гражданнар сугышы елларында Виноградов атаман Анненковка каршы сугышты. Шул ук полкта безнең Иман-Тау казагы Александр Семенович Егоров хезмәт итә иде. Аның мендәре астыннан «Иртыш»ны тапканнар. Хәтерлисезме, 1906 елларда шундый газета бар иде. Аны Омск РСДРП оешмасы чыгарды. Ә «Иртыш»ны безгә Кәрим Сутюшев җибәрә иде. Мин аны үзебезнең таныш интендантлар аша полкка... Менә шушы газета өчен хәрби кыр суды Александр Семеновичны 12 елга каторгага хөкем итте. Ул бичара ун ел каторгада өстерәлгәннән соң гына, Февраль революциясе булгач, Иман-Тауга кайтты. Күрше Чалкар станицасы казагы Лихоман да «Правда» газетасын укыган өчен Себергә китте. Ә менә Күкчәтау тирәсенә тупланган дүртенче, җиденче казак полкларының восстаниесе исегездәме? Ул 1914 елның 31 июлендә кузгалды. Сигез казакны аттылар. Бик күпләрне богаулап Себергә кудылар. Мин бу турыда әле иркенләбрәк сөйләрмен. Чөнки бу хәл Күкчәтау далаларындагы революция хәрәкәтенең иң әһәмиятлесе. Атылганнар арасында минем дуслар да бар иде. Нәкъ революция алдыннан һәлак булдылар... Җәл, бик җәл...

Кинәт әңгәмә киселде. Усман ага күзләрен йомып, башын түбән иде. Ул шулай бик озак йокымсыраган хәлдә калды. Миңа ничектер уңайсыз, күңелсез булып китте. Папирос кабыздым.

— Миңа да бирегез әле, — диде ул һәм башын күтәрмичә генә кулын сузды, — бер-ике суырыйм.

Без шулай озак, сүзсез генә тәмәке тарттык. (Әле менә хәзер дә үземне шелтәлим. Бик зур хата эшләдем мин ул вакытта. Утыз беренче июль восстаниесе турында Усман аганы күбрәк сөйләтергә иде. Восстание әзерләүдә Усман ага үзе катнашкан бит. Шулай булгач, анда никадәр бай материал! Ә мин уңайсызландым. Авыр көннәрне хәтерләтеп борчыйсым килмәде минем. Соңыннан бер вакытны сорашырмын, дип уйлаган идем. Ә соңыннан инде артык соң булды...)

— Юк. Иман-Тауда да тыныч булмады, — дип сүзен ялгап китте Усман ага, тәмәкесен сүндергәч. — Дөрес, бая әйткәнчә, руслар белән татарлар арасында милли, дини дошманлык булмады. Яз башында, чәчү беткәч, безнең якта Сабан туе башлана. Руслар киләләр, керәшәләр. Атларын бәйгегә кушалар. Бүләкләр алалар. Кыш ахырында, масленкада, без — татарлар — аларга барабыз. Пар атлар җигеп бәйрәм итәбез. Ә менә офицерлар белән ярлы казаклар арасында ызгыш туктамады. Кайвакытта ул корал күтәрүгә кадәр барып җитә иде.

Севастополь портында япь-яшь килеш авыр йөкләр ташыганга, миндә бөсер авыруы булды. Шуның өчен мине башта хәрби хезмәттән азат иткәннәр иде. Герман сугышы башлану белән, Петропавелдан Иман-Тауга чакыртып, резерв казак полкына алдылар. Көне-төне солдат хезмәте. Сугышка җибәрүне көтәбез. Мин полкка күчкәч тә Кәрим белән бәйләнешне өзмәдем. Ул полкка җибәрелә торган чәй-шикәрләр арасына «Окопная правда»ны тыгып җибәрә, ә без аны сотняларга тарата идек.

* * *

Октябрь революциясеннән соң Имән-тау станицасы бер-берсенә капма-каршы торган ике лагерьга бүленде. Монда ике төрле хөкүмәт органы оештырылды. Берсе — офицерлар, кулаклардан торган Земский башкарма комитеты. Аның башында офицер Филипп Ильиченко торды, соңыннан, восстание вакытында, ул акгвардеецлар отрядының атаманы булып, Совет хөкүмәтенә каршы сугышты. Земский башкарма ничек кенә булса да станицада элекке атаман тәртипләрен саклап калырга тырыша иде. Аңа каршы Совдеп торды. Аңа член булып: Усман Әбдрәшитов, Галимҗан Зәетов, Роман Войтенко, Ширәй Шабаев, Мирхәйдәр Әширов һәм башка ярлы казак вәкилләре сайланган иде.

Менә фронттан казаклар кайта башлады. Башта — ярлылар. Соңга таба — үзләре коралларын ташлап кайтучылар. Шатланып, җырлап кайттылар алар өйгә. Ә өйдә — ачлык-ялангачлык. Сугыш вакытында бар ашлык, бар төрлек ашалып беткән. Ә бай казакларның ындырларында тау-тау эскертләр утыра.

— Байларның артык ашлыкларын конфисковать итеп, ярлыларга өләшергә!

Станицаның сходкасы менә шундый карар чыгарды. Совдеп шушы карарны — күпчелекнең теләген тормышка ашыра башлады. Ул арада борчулы хәбәрләр таралды.

Революциянең алдынгы фронтында торучы Питер, Мәскәү эшчеләре ачыгалар, ярдәм итегез!

Совдеп членнары Усман Әбдрәшитов җитәкчелегендә продотрядлар оештырып, Имән-Тауга гына түгел, аның тирәсендәге башка станицаларда бай казакларның ашлыкларын конфисковать итеп Имән-Тауга җыйдылар. Бу ашлыкның беркадәресе ярлыларга, ятимнәргә, тол хатыннарга өләшенде. Ә күбесе Петропавелга — тимер юл буена озатылды.

Башында Ильиченко торган Земский башкарма комитеты ашлык җибәрүне туктатырга таләп итте һәм ул, бу таләп үтәлмәсә, Совдепны тар-мар итү белән куркытты. Нәкъ менә шул вакытта Күкчәтаудан килгән өяз Совдеп члены Сабир Шәрипов Кызыл гвардия отряды оештырырга кереште. Бу отрядка беренче булып Гани Шәфиев, Василий Егоров, Хәсән Биктимеров, Гани Бәхтиев, Шәгали Гобәйдуллин һәм башкалар язылдылар. Бу отряд икмәк обозларын Имән-Таудан Петропавелга хәтле саклап алып бара иде.

— ...1917 елның декабрь ахыры иде. Шакырдап торган суык. Земский башкарма комитетыннан посыльный килде. Ул:

— Ильиченко Совдеп членнарын исполкомга килергә куша, — дип белдерде.

Киттек. Барып керүебез булды, офицерлар уртасында утырган Ильиченко урыныннан сикереп торып, приказ биргән тавыш белән безгә кычкырды:

— Исполком икмәк озатуны хәзер үк туктатырга боера. Югыйсә, барыгызны да кулга алабыз!

— Моны әле карап карарбыз. Кем кемне, — диде Роман Войтенко, алгарак чыгып. Аннан безгә карап өстәп куйды, — без Россиядәге эшче туганнарыбызны ач калдыра алмыйбыз.

Без чыгып киттек. Кайту белән Кызыл гвардия отрядының нарядларын көчәйттек, Күкчәтауга корал алырга кеше җибәрдек. Ә икмәк җыю һәм озатуны бер көнгә дә туктатмадык. Шулай итеп 1918 елның беренче апреленә без Имән-Таудан Петропавелга йөз мең пот икмәк озаттык. Бу безнең иң зур шатлыгыбыз иде. Сутюшев, Петропавел Совдепы членнары исеменнән безне котлап, хат җибәрде һәм мине үз янына килергә чакырды. Ни өчен? Әйтелмәгән. Шул вакытта ук китә алмадым. Чәчү башланыр чак иде. Әйтергә дә онытканмын икән: без бит әле Имән-Тауда сельпо оештырдык. Байларның кибетләрен ябып, үзебезнекен ачтык. Менә чәчү тәгәлләнгәч, май ахырында, мин Петропавелга киттем. Сельпога товар алырга дип чыксам да, төп теләгем Кәрим дус белән күрешү булды. Сагынган идем мин аны. Кызганычка каршы, безгә инде күрешергә язмаган икән...

— Сез Усман Әбдрәшитовмы?

— Әйе.

— Коралыгызны бирегез! Киенегез!

— Сез кем?

— Хөкүмәт, — дип кычкырып җибәрде офицер. Киеме миңа таныш түгел — френч-галифе. Ул, мин яткан кровать янына килеп, мендәрне күтәрде. Анда карабиным иде...

Мин әле шул көнне кич белән генә Петропавелга килеп, бер танышыбызның өенә төшкән идем. Шәһәр бик тыныч күренә иде. Ә хәзер? Миңа артык уйланып торырга бирмәделәр, машинага утырттылар да — төрмәгә! Ә анда шыгрым тулы халык — большевиклар, красногвардеецлар, Совдеп члennары....

Моннан берничә көн элек Петропавел тимер юл станциясенә берничә эшелон белән ак чехословак солдатлары килеп төшкән булган. Шунда ук Совдепка хөкүмәттән яшерен депеша килгән: чехословак солдатларын коралсызландырырга. Әгәр баш тартсалар, эшелонга паровоз бирмәскә.

Чехословаклар коралларын бирүдән баш тарткач, Петропавел Совдепының комиссары Кәрим Сутюшев аларга паровоз бирмәскә куша. Менә шуннан соң инде, 28 майда, чехословаклар баш күтәрәләр. Аңа җирле контрреволюция кушыла.

Икенче көнне төрмәгә коточкыч хәбәр килә: Кәрим Сутюшев белән Калюжнаяны үтергәннәр.

Сораша торгач, мин шуларны белдем:

Чехословак корпусы баш күтәрү белән, Сутюшев, консерв заводына барып, эшчеләрдән, тимер юлчылардан отряд оештырып, станциягә һөҗүм итә. Ләкин бу аз санлы һәм начар коралланган отряд озак сугыша алмый, чигенергә мәҗбүр була. Кәримнең янындагы иптәшләре аңа, казак киеме киенеп, Омскига таба китәргә киңәш итәләр. Ләкин ул бу тәкъдимне кире кага һәм тагын отряд оештырып, төрмәне басып алырга әзерләнә. Нәкъ менә шул вакытта шәһәрдәге ахунның хәйләсе белән Кәрим кулга алына. Аны кыл аркан белән ат койрыгына бәйләп, урам буенча йөрттәләр, кыйныйлар. Ахырында, хәлсезләнеп егылгач, ахунның наемщигы Маслаков Кәримне башына казык белән сугып үтерә.

Кәрим Сутюшевның гәүдәсе Петропавел урамында өч көн ята. Аның янына килергә һичкемгә рөхсәт ителми. Бары дүртенче тәүлектә генә туганнары Кәримнең гәүдәсен күмәләр.

* * *

— ...1919 елның сентябрь аенда Колчак армиясенә мобилизация башланды. Мине дә шунда алдылар. Бу вакытта Кызыл Армия частьлары, Тухачевский командасында, Петропавелга якынлашканнар иде инде. Безнең дивизия Колчакның чигенүче гаскәрләрен флангтан саклаучы булып бара иде. Менә шуның өчен без кызылармеецлар белән дә ара-тирә очрашып ала идек. Без, бер группа солдатлар, кызыллар ягына чыгарга җыена башладык. Шул вакытта күршебездәге Нижний Бурлук станицасы казагы Коровин миңа Омск большевиклар оешмасының заданиесен китерде: «Дивизиядә калып, Кызыл Армия ягына чыгу турында солдатлар арасында агитация алып барырга».

Без үз эшебезне яхшы башкардык. Дивизия тулы составы белән кызыллар ягына чыкты. Өстәвенә дивизия командиры полковник Копейкинның үзен дә Кызыл Армия кулына тапшырдык...

* * *

1920 елның июнь аенда Иман-Тауда коммунистларның беренче ячейкасы оештырыла. Бу ячейкага член булып: Усман Әбдрәшитов, Шәгали Гобәйдуллин, Мирхәйдәр Әширов, Гали Әширов, Галимҗан һәм Таһир Зәетовлар сайлана.

Тагын икмәк өчен көрәш башлана. Партячейкага ярдәмгә продотряд килә. Кулакларның 1914 елдан ук куйган эскертләрен сугу, ашлыкны озату бер генә көнгә дә тукталмый. Менә шулай эшнең нәкъ кызган вакытында — 1921 елның февралендә — восстание күтәрелә.

— Уналтынчы февраль төнне баш күтәрүчеләрнең Иман-Тауга якынлашып килүләре турында хәбәр алдык. Монда калырга ярамый иде. Чөнки Иман-Тауның үзендә үк баш күтәрүчеләрне дүрт күз белән көтүче казаклар аз түгел. Без шунда ук, подводалар әзерләп, коммунистлардан ундүрт продотрядчы Арып-Балык станицасына юнәлдек. Андагы продотрядка кушылырга уйласак та, бу уебыз барып чыкмады. Станицага бер-ике чакрым житәр-житмәс, безне көчле пулемет уты белән каршы алдылар. Чигенергә туры килде. Володаровка ягына борылдык. Ике арада атыш барганда баш күтәрүчеләр бер подводабызны алып калдылар. Коткарырга көчебез житмәде. Ике продотрядчы һәм коммунист Мирхәйдәр Әширов пленга төштеләр.

Продотрядчыларны шунда ук үтергәннәр. Мирхәйдәрне бик каты кыйнап Иман-Тауга китергәннәр. Монда салкын сарайда минем йөкле хатыным, сеңелем Зөһрә һәм 80 яшьлек агам ябылган булган. Мирхәйдәрне дә шунда ташлаганнар.

Иртә белән сарайны ачып, барысын да ишек алдына чыгаралар. Җәзалау башлана. Мирхәйдәрне чатнап торган суыкта чишендереп, ялан аяк кар өстендә йөртәләр, кыйныйлар. Тешләрен сугып сындыралар. Ул хәлсезләнеп егыла. (Мирхәйдәр Әширов әле исән. Иман-Тауда яши). Чират безнекеләргә дә житә, аларны да чишендерәләр, атарга әзерләнә башлыйлар. Шулвакыт:

— Алладан куркыгыз! — дигән көчле тавыш яңгырап китә. Баш күтәрүчеләрнең башлыклары тупланган җиргә Иман-Тау чиркәвенең дьяконы Григорий Яковлевич Беляев чыга һәм ялангач арестантларны куллары белән киртәләп мылтыклар каршына килеп баса.

Ул көнне минем гаиләм исән кала, әмма озак та үтми, Беляевның үзен ишек алдында үле килеш табалар...

* * *

— Мин арыдым, ахрысы...

Усман ага өстәл янынннан торып, урынына ятты. Мин уңайсызланып киттем. Нигә дип аны шулкадәр озак сөйләтеп борчыдым соң? Нишләргә? Китәргә кирәктер. Ичмаса, рәхмәт тә әйтә алмадым үзенә. Ул инде йокымсырый. Урынымнан торып кузгалуга, Усман ага күзләрен ачты. Миңа карап елмайды. Аның йөзе яктырып, яшәреп киткәндәй булды:

— 28 гыйнварда килергә онытмагыз. Миңа туксан яшь тула. Сезгә тагын да бик күп нәрсәләр сөйләрмен әле.

— Килэм, Усман ага, һичшиксез, килэм.

Кызганычка каршы, без инде икенче тапкыр очраша алмадык. Ул сөйләгән булыр иде, бик күп вакыйгаларның серен ачар иде. Югыйсә, Усман ага давыллар, утлар аша үтеп, үзенең ярты гасырдан артык гомерен революция эше өчен бирген кеше. Ләкин ул туксан яшь туларына дүрт ай калганда арабыздан китте...

*ИМӘН-ТАУ — КУКЧӘТАУ*
*1967 ел.*



Политрук Нияз Әбдрәшитов.
1941 елның ахырлары.

*Ә. Хәмидуллин,*
*В. Скоробогатов*

# КОММУНА УЛЫ

Кырык беренче елның 22 июнь иртәсен Нияз типографиядә каршы алды. Газета бик соң басыла башлады, сәгать бишләрдән соң гына. «Ленинское знамя» исемле өлкә газетасының партия тормышы бүлеге мөдире Нияз Әбдрәшитов ул көнне «саф баш» иде.

Газетаның бу саны бер яктан аңа ошады, икенче яктан ошап та бетмәде: якшәмбе көн өчен аны күңеллерәк тә итәргә мөмкин иде... Беренче биттән И. В. Сталинның ярым профиль рәвешендә төшкән зур рәсеме карап тора. Астарак баш мәкалә — «Промышленностьның яңа уңышлары өчен». Ә уңда дүрт баганага партия өлкә комитетының язгы чәчү йомгаклары һәм урып-җыюга әзерлек бурычлары турында Карары урнаштырылган. Икенче, өченче битләр дә хуҗалык мәсьәләләренә багышланган. Нияз газетаны бик җентекләп укып чыкты, белдерүләрне дә игътибарсыз калдырмады: кинотеатрларда «Фронтташ дус кызлар» һәм «Маннергейм линиясе» фильмнары бара.

— Кичен «Линия»не карап кайтырга кирәк булыр, — дип уйлады Нияз, урамга чыккач. Типографиянең кургаш тузаннары катыш бәркү һавасыннан соң, акация чәчәкләренең саф сулышы Ниязның күкрәген киңәйтеп җибәрде. Иртәнге сафлыкка сокланып, ул типография капкасы төбендә озак басып торды. Аның яныннан шау-гөр килеп кичәге укучылар узып китте: мөгаен, чыгарылыш кичәсе иртәнгә кадәр дәвам иткәндер. Нияз акрынлап кына атлап өенә юнәлде. Үз урамнарына борылгач, борынгы су башнясы янында тукталып торды. Аның кирпечләре әлегә кадәр гражданнар сугышы эзләрен саклый: икенче катындагы стенаны снарядлар шартлап умырган. Колчак бандалары, мөгаен, туплардан атып, Петропавел шәһәрен сусыз калдырырга уйлаганнардыр. Әйе, биредә сугышлар каты булган, аны хәтерләүче кешеләр хәзер дә исән әле...

Әбдрәшитов, журналист һәм коммунист буларак, тагын да көчлерәк, тагын да күбрәк кан койгыч сугышның әле алда булачагын күңеле белән тоя иде, ләкин ул көнне

бу турыдагы хәбәрне бүген үк ишетәсен башына да китермәде. Өенә кайтты да йокларга ятты. Исәбе: ял итеп алырга да балалар белән Ишим елгасында коенып кайтырга. Ә дүшәмбе көн — районнарга китәргә...

— Нияз, тор! Тор, Нияз, сугыш...

Аны хатыны уятты, күзләре стенадагы репродукторга текәлгән иде...

Редакциядә ул иң элек редактор урынбасары Андрей Петровичны очратты. Күптәнге дуслар бер-берсен ярты сүздән үк аңлыйлар иде. Андрей Петрович Кияница комсомол газетасы редакторы булып эшләгәндә, Нияз ВЛКСМ өлкә комитетында бүлек мөдире иде. Менә инде бишенче ел алар өлкә партия газетасында бергә эшлиләр. Хәсән күле вакыйгалары вакытында бергәләп, Ерак Көнчыгышка җибәрүләрен сорап, хәрби комиссариатка бардылар. «Хәзергә анда кирәкмисез әле», — дип борып кайтардылар аларны.

Андрей Ниязга соргылт-зәңгәр күзләрен тутырып карады. Әбдрашитов бу карашны аңлады.

— Әйе, Андрей, безгә нәрсәдер уйларга кирәк, — диде Нияз.

— Безнең кулларда хәзергә пулемет та, винтовка да түгел, каләм генә, — диде Кияница. — Шуның белән эш итәргә кирәк. Әлбәттә, хәрби комиссариат ишеген дә шакырбыз. Ләкин бит синең арка сөяге...

— Әй, мин ул турыда күптән оныттым инде, — дип кул селтәде Нияз.

Чынлыкта исә бу авыру Ниязны күптәннән борчый иде. Бала чагында Имән-Тау станицасында, иптәшләренә егетлеген күрсәтергә теләп, ул биек амбар түбәсеннән кар өстенә сикерде. Барлык уеннарда башлап йөрүче, шук Нияз бу «очыш»ны элек тә берничә тапкыр ясаганы бар иде. Ләкин бу юлы уңайсыз төшеп арка сөяген имгәтте һәм озак вакыт больницада ятып чыкты. Кырымнан да дәваланып кайтты. «Сакланмасаң, умыртка сөяге туберкулезына әйләнер», — дип кисәттеләр врачлар. Шуңа күрә Ниязны Кызыл Армиягә действительный хезмәткә дә алмадылар...

— Күптән таза инде мин, — дип кабатлады Нияз. — Син беләсең бит инде, беркайчан да, бернидән дә зарланганым юк. Командировкаларда кайда туры килсә, шунда ятып йоклыйм, берничә тәүлек йокламаган чаклар да була, пычагым да юк. Хәрби хезмәттән дә бөтенләй үк азат түгел. Димәк, мин сафта!

Нияз хаклы иде: чыннан да ул редакция кабинетында утырырга яратмый. Районнардан рухланып, дулкынланып кайта. Материалларын секретариатка тапшыра да тагын берничә көнгә чыгып китә. Яңа тормыш өчен көраш белән бәйле, иң мөһим мәсьәләләрне яктырткан материалларны гына алып кайта ул газетага. Аның язганнары кыскалыклары белән, дәртле омтылыш, тормышны, хезмәт ияләренең уйларын, хисләрен тулы яктыртуы белән аерылып тора...

Нияз хәзер дә хәтерли: ул бала гына иде әле. Мәскәүдә чыга торган газеталарның берсендә Имән-Тау коммунасы турында мәкалә басылып чыкты. Бу мәкаләне аның әтисе Усман ага язган иде. Газетада әтисенең өстенә кожан киеп төшкән рәсемен дә басып чыгарганнар. Коммуна турындагы мәкалә газетаның бөтен битен алып тора. Бу мәкалә чыкканнан соң, авылдашлары — комсомолец Сергей Щелкунов станицага беренче «Фордзон» тракторы алып кайтты.

Шуннан соң Ниязда матбугатка карата мәхәббәт уянды, ул үзе дә газета редакцияләренә кечкенә хәбәрләр җибәрә башлады. Ә Идрис Зәетов — аның туганнан туган абыйсы — хәтта шигырьләр дә яза иде. Бер шигыре Мәскәүдә — редакторы Муса Җәлил булган «Кечкенә иптәшләр» журналында да басылып чыкты.

Редакциядән килгән җавап хатларын түземсезлек белән көтеп ала торган иде Нияз. Дөрес, аларда уңай җавап булмый, кимчелекләрне күрсәтеп яза торганнар иде. Шулай да Нияз бу хатларга бик сөенә, үзен гаять җитди эш белән шөгыльләнүче кеше итеп сизә иде. Һәм ул авыл кешеләренең тормышы, коммуна хәлләре хәбәрләрен бер-бер артлы газетага җибәрә торды.

Ә коммуна тормышы җанлы, кызыклы иде. Ул 1921 елда оешты, аңа «Прогресс» дип исем куштылар.

Ниязның әтисе — беренче рус революциясенә һәм гражданнар сугышына катнашкан, 1920 елдан партия члены Усман Әбдрашитов — гомеренең соңгы көннәренә кадәр Төньяк Казагыстанда оешкан бу беренче коммунаның документларын үзендә саклады. Бу документлардан күренгәнчә, башта коммунада өч ат, ун үгез, унбиш са-

вым сыер, ике дуңгыз, ике тәрәнле ике сабан, бер тәрәнле өч сабан, бер чәчкеч, җиде көрәк, җиде балта, дүрт сәнәк булган.

Имән-Тау станицасы ярлыларының байлыгы зур булмаган ул вакытта, әмма аларда Ленин идеяләренә какшамас ышаныч һәм яңа тормышка дәртле омтылыш булган. Бергәләп җир сөргәннәр, бергәләп уңышны җыеп алганнар. Коммунистлар — коммунада алар алты кеше булган — мәктәп ачуны кайгыртканнар. Тиздән Усман абзыйның сеңелесе укытучы Зөһрә Әбдрәшитова инициативасы белән коммунистик балалар оешмасы барлыкка килгән. Анда член булып торган балаларга укучыларның үзләре тарафыннан әзерләнгән таныклыклар бирелгән.

Соңрак кулактан тартып алынган зур кибет бинасын клубка әверелдергәннәр. Революцион бәйрәмнәр вакытында яшьләр анда спектакльләр куйганнар, концертлар күрсәткәннәр. Укырга омтылган сәләтле яшьләрне коммуна, юлларына акча юнәтеп, ашарларына биреп Күкчәтауга, Петропавелга, хәтта Казанга һәм Мәскәүгә җибәргән. Имән-Тау кешеләре үзләренең авылдашлары: техникэ фәннәре докторы Галим Әбдрәшитов, Совет Армиясе полковнигы Җамали Гобәйдуллин, Казан университетының кафедра мөдире, күренекле юрист Рахман Яхин, партия хезмәткәре Идрис Зәетов белән хәзер дә горурланалар.

Гади һәм гадәттән тыш шаян Нияз Әбдрәшитовның да укып кеше булуына алар бик сөенделәр...

Нияз, Петропавелда совет-партия мәктәбен тәмамлаганнан соң, комсомол ячейкасы секретаре булып туган станицасына кайтты. Бер елдан аны комсомолның Арык-Балык район комитетына секретарь итеп сайладылар.

Авыр чор. Коллективлашу заманы. Ул елларда колхоз төзелешендә һәм кулакларның Совет властена каршы оештырган планнарын фаш итүдә комсомолның роле гаять зур булды. Район бик зур иде, шулай да Нияз һәр авылда, һәр станицада булырга тырышты. Аның өлгерлегенә, оештыру сәләтенә якын дуслары да гаҗәпләнәләр иде.

1931 ел — Нияз тормышында зур борылыш елы булды: аны коммунистлар партиясе члены итеп кабул иттеләр һәм ВЛКСМның IX съездына делегат итеп сайладылар.

* * *

«...Безнең кулларда каләм генә». Нидән эшне башларга соң? Гитлерчылар белән сугыш күп булса бер елга сузылыр, — ул вакытта Нияз шулай уйлады, — Ватанга, халыкка мондый көннәрдә мөмкин кадәр файдалырак булырга кирәк...

Киңәшмәгә җыелып, өлкә газетасы журналистлары Хасан күле, Халхин-Гол һәм фин сугышы геройларын киң итеп сурәтләү карарына килделәр. Әбдрәшитов орден һәм медальләр белән бүләкләнгән командирларны, кызылармеецларны эзләп тапты. 24 июньдә инде алар газета битләреннән укучыларны немец басып алучыларына каршы көрәшкә бөтен көчне бирергә чакыралар иде.

Фронттан алынган хәбәрләр күңелле түгел. Безнең гаскәрләр шәһәр артыннан шәһәр калдырып чигенәләр. Газета һәр көнне халыкка дөресен әйтергә, хезмәт иләрен оешканлыкка, түземлелеккә, батырлыкка чакырырга тиеш. Фронт хәбәрләре белән рәттән газета битләрендә фабрика һәм заводлардан, колхоз һәм совхоз кырларыннан да мәкаләләр чыга тора, сабанны, станокны винтовкага алыштырып, дошманга каршы сугышка киткәннәрнең дә, алар урынына баскан һәм ике, өч кеше өчен эшләгән хатын-кыз, яшүсмерләрнең дә омтылышлары, фикерләре анда чагылыш таба.

Соңгы биш көн эчендә Нияз өлкә үзәгеннән йөз чакрымнар ераклыктагы Ильинское авылында да, партиянең өлкә комитеты заданиесе буенча МТСларда да булырга өлгерде. Авыллардан колхозчыларның урып-җыюны елдагыга караганда иртәрәк бетерергә вәгъдә бирүләре, Кызыл Армиягә күбрәк икмәк, ит, май һәм башка продукция тапшырачаклары турында материаллар туплап алып кайтты...

Кайтып озак та тормады, көннәрнең берендә ул редакциядән хатынына шалтыратты:

— Иртән армиягә китәм, — диде ул. — Барлык кирәк-яракларны әзерләп куй. Үзем соңарып кайтам, язып бетерәсе әйберем бар...

Хатыны шаярта дип уйлады: иренең тавышы тыныч, гадәти иде — әйтерсең, ул командировкага гына китәргә җыена. Әмма бу чын булып чыкты:

— Повестка кесәдә инде, — дип естәп куйды Нияз

Жыену озакка сузылмады, балалардан аерылу кыен булды. Алар өчәү иде: олысына, Розага, биш яшь, Вивага — өч, ә улына, Вилгә, ике яшь тә тулмаган иде әле.

22 июльдә эшелон Ерак Көнчыгыш ягына таба кузгалып китте. «Үзем теләгәндә җибәрмәделәр, — дигән иде Нияз, юлдан язган хатларының берсендә. — Ә хәзер мөнә фронтка китәсе урынга шунда җибәрделәр. Хәер, анда да фронт булуы мөмкин: юкка гына җибәрмәсләр иде. Һәр нәрсәгә әзер булып тору кирәк...»

Әбдрәшитов әллә кайчан юлда, ә ул язган материаллар Н. Имәнтавский псевдонимы белән газетада һәр көн чыга торды. Редакциядә буш урыннар күбәйде. Александр Доброзраков, Михаил Костырев, Федор Богатырев, Борис Монастырский, Федор Супрунюк, Иван Горбуновлар да фронтта инде. Көзгә таба Ниязның дусты Андрей Петрович Кияницаны да батальон комиссары итеп җибәрделәр.

Армиядә хезмәт итүнең беренче айлары киеренке хәрби күнегү белән узды. Куе куак белән капланган сопкаларны «штурмлаганнан» соң, рядовой кызылармеец Ниязның авыру биле түзеп булмаслык рәвештә сызлый, аяклары кургаштай авырая иде. Ләкин шулай булса да ул ротаның стена газетасын чыгарырга да, Ерак Көнчыгыш фронты газетасы «Тревога»га материаллар язып җибәрергә дә вакыт таба иде.

Әбдрәшитов хезмәт иткән часть японнарның миллионлы Квантун армиясе бәреп керсә, отпор бирергә әзер тора иде. Шулай да Нияз үзен тыл кешесе итеп тойды: хатынына җибәргән хатларында ул фашист башкисәрләре Мәскәү янына килеп җиткән вакытта ерак тылда булуына уңайсызлануын белдерә иде.

1941 елның ахырында Ниязга политрук званиесе бирелде. Шулай Ерак Көнчыгышта бер ел узып та китте. Ниһаять, 1942 елның июлендә Ниязлар төялгән эшелон Көнбатышка таба юл алды. Юлда хатлар язарга да, телеграмма сугарга да рөхсәт ителмәде. Нияз туган шәһәре аша узды, әмма семьясын да, дусларын да күрә алмады, тик таныш тимер юлчы аша хатынына бер кечкенә хат кисәге җибәрергә генә өлгерде: «Сине һәм балаларны күрергә бик теләгән идем. Сталинградны сакларга барабыз. Борчылма, фашистларны җиңәрбез дә әйләнеп кайтырмын. Балаларны сакла. Нияз».

Фронттан да хатлар сирәк килде. «Һәр урам, һәр йорт өчен генә түгел, хәтта һәр баскыч өчен сугышабыз, — дип язды Нияз. Белсәң иде, безнең сугышчыларның нинди батырлыклар күрсәткәнен! Алар турында үзебезнең «Ленинское знамя» газетасына язарга җыенам әле. Бу турыда Ф. И. Самаринга (җаваплы редактор) әйт. Миндә яңалык: Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләделәр. Тәбрикли аласың».




Ниязның фронттан язган бер хаты. «Кургәнсеңчә, бу открытка канга һәм пычракка буялып беткән, — дип яза Нияз үзенең кызы Розага. — Бу немец бандитлары яралаган иптәшемнең каны. Сволочьлар безнең окоплардан берничә метрда торалар. Вакыт килер, аларның эзе дә булмас.»



Н. У. Әбдрәшитовның улы Вил, Совет Армиясе сафында хезмәт иткән вакыты.

Соңыннан сугышка аның белән бергә киткән Петропавел кешеләреннән бу орденның нәрсә өчен бирелгәнлеге дә билгеле булды.

Нияз Әбдрәшитов 33 нче гвардия укчы дивизиясендә хезмәт иткән. Орден аңа Котельниково шәһәрендәге урам сугышларында күрсәткән батырлыгы өчен бирелгән.

Нияз Әбдрәшитов ротасы өч көн эчендә сигез тапкыр атакага күтәрелә. Ниязлар батальоны немецларның полктан артык гаскәрләренә каршы сугыша. Нияз, ике сугышчы белән бергә, урам чатындагы таш йортны сугышып ала һәм безнең рота немецларның контратакасы басымы астында позицияне калдырырга мәҗбүр булуына карамастан, караңгы төшкәнче дошманнарны тоткарлап тора. Бәлки, олы кызы Розага җибәргән открыткасын ул нәкъ менә шушы Котельниково станциясеннән язгандыр. «Сөекле кызым! — диелгән анда. — Без немецлардан зур торак пунктын азат иттек. Оэакламый фашист ерткычларын юк итәрбез, һәм мин өйгә кайтармын. Син мәктәпкә йөрерсең. Әниеңне, Виваны, Вилне үп һәм мине көт».

1943 елның язы шатлык алып килде, җиңүгә ышанычны арттырды. Ләкин Нияз Әбдрәшитов бу язны күрә алмады...

Нияз хезмәт иткән батальонның штаб начальнигы, Ростов шәһәрендә яшәүче, запастагы майор В. Г. Маноцков бу көннәрне хәтерләп, түбәндәгеләрне сөйләде:

«Мин Нияз Әбдрәшитовны Маныч тагы сугышлар вакытында күрдем. Хәлиткеч сугышлар алдыннан безнең частьны тулыландырдылар. Яңа килгән сугышчылар безгә төрле сораулар яудырырга керештеләр. Аларны частьның кайда оешуы да, аның сугышчан юлы да — барысы да кызыксындыра иде. Җанлы әңгәмә башланып китте.

— Безнең сугышчылар кыю, — дип сөйләп китте Нияз. — Фашист өстенә суворовча кинәт ябырылырга яраталар. Ә бу бик әһәмиятле. Шуңа күрә командование дә моңа зур бәя бирә. Әйтик, шулай кинәт һөҗүм итеп, фашист офицерын пленга аласың икән — сиңа орден. Унтерны алып кайтсаң — «Батырлык өчен» медале...

Бу сугышчылар белән Әбдрәшитов соңгы сугышка керде...

Мин аның яшь сугышчылар белән әңгәмә үткәрүен тыңлап тордым да сорадым:

— Сез журналист бит, — дидем, — редакциягә кайтырга уйламыйсызмы соң?

— Әлбәттә, уйлыйм, — дип җавап бирде ул, — сугыш беткәч.

* * *

...Ләкин Нияз Әбдрәшитов редакциягә кайта алмады. Хатынына килгән хәбәрдә өлкән лейтенант Н. У. Әбдрәшитовның 1943 елның 2—3 февралендә Ростов өлкәсе Самодуровка станциясе янындагы сугыш вакытында хәбәрсез югалуы турында әйтелгән иде.

Бер айдан соң тагын бер хат килде. Ниязның сугышчан дусты офицер Мошков язган иде аны:

«Сезнең ирегез кыю һәм батыр кеше иде. Без аны һәрвакыт сугышның иң кызган

урыннарында күрә идек. Самодуровка янындагы сугышларда да ул шундый кыю булды. Әбдрәшитов дошман пулялары астында барлык сугышчылар алдыннан беренче булып һөҗүмгә ташланды. Аннан инде без аны күздән югалттык. Мөгаен, ул минага туры килеп шартлагандыр. Дивизия сугышчылары һәлак булганнарны, шулар исәбеннән тануы мөмкин булмаган гәүдәләрне дә, зур хөрмәт белән күмделәр»...

* * *

Сугыш беткәннән соң биш ел узгач, «Ленинское знамя» газетасының утыз еллык юбилеен билгеләп үттеләр. Юбилейга газетаның махсус саны багышланды. Редакциягә сугыш кырларыннан әйләнеп кайта алмаучылар турында да анда бер мәкалә бар иде. «Әбдрәшитовны бер вакытта да безнең эшсез күргәнебез булмады, — дип язылган иде анда. — Ул һәрвакыт каядыр ашыга, һәрвакыт хәрәкәттә иде. Таракка буйсынмас соргылт чәчле, очкынланып торган акыллы күзле, тез гәүдәле, өлгер, җитез хәрәкәтле каләмдәшебез, тере кебек, һәрчак минем күз алдымда тора.

*А. Кияница.»*

...Вилне әтисенә охшаган, диләр. Өч ел элек ул лейтенант званиесендә Совет Армиясендә действительный хезмәтен бетереп кайтты. Вил армиядә дивизия политбүлегенең инструкторы булган, полк комсомол комитеты секретаре булып сайланган. Хәзер Вил Петропавел шәһәрендәге зур заводларның берсендә цех начальнигы булып эшли. Ниязның олы кызы Роза Алма-Атада инглиз теле укыта, ә Вивасы — врач, Петропавел медицина училищесында анатомия буенча дәрес бирә. Революционер, коммунар Усман ага улының — журналист, сугышчы, коммунист Ниязның хәзер инде үз оныклары бар.

Әбдрәшитовларның туган станицасында — хәзер зур совхоз. Ул «Правда» исемен йөртә.

● ● ●

# КАРАИМНАР ЯНЫНДА

Балтик буе республикаларыннан берсе булган Литва җирләренә барып чыгыгыз. Аның төньяк табигатенә хас, үзенчәлекле матурлыгы бар.

Андагы йөзләрчә эреле-ваклы зәңгәр күлләр, саф сулы елга-инешләр, мәңгелек яшел наратлар, күкрәп үскән күгелҗем куаклыклар һәркемне үзенә тартып тора.

Без республиканың иң борынгы шәһәрләреннән берсе Тракайга юл тотабыз. Тракай — Литва князьләренең борынгы башкаласы. Караимнар Литваның шул гүзәл почмагында күп гасырлардан бирле яшәп киләләр.

Бүгенге караимнарның ерак бабалары борынгы күчмә төрки кабиләләрдән берсе — хазарлар булган. Алар VIII—X гасырларда Кара диңгез буйларында, Кырым җирләрендә яшәгәннәр. Төп кәсепләре терлекчелек булган. Шул заманнарда хазарларның югары катлавы яһүди диненең бер мәзһәбе булган караим динен кабул иткән.

X гасыр ахырларында Кырым җиренә башка төрки кабиләләр басып керә. Хазарлар исә, бу кардәш кабиләләр белән аралашып, тора-бара алар тәэсиренә бирелләр. Соңыннан инде аларны хазар дип үз исемнәре белән атамыйча, кабул иткән диннәренең исеме белән «караим» дип йөртә башлыйлар.

XIV гасыр ахырында Литва князе Витаутас Кырымга хәрби поход ясый һәм шунда ул караимнардан 5000 ләп кешене барымта (наложник) итеп Литвага күчереп алып китә. Аларны ул Тракай тирәсенә урнаштыра. Бу күчерү хәрби максат белән, Литва князьләренә сугышчан көчләр туплауны күздә тотып эшләнә.

Караимнар Литва тарихында аның көнбатыш чикләрен, шулай ук Тракай ныгытмасын крестоносецлар һөҗүменнән 200 еллар буена саклап килгән сугышчылар сыйфатында искә алыналар. Соңыннан, хәрби вазифадан азат ителгәч, алар игенчелек, яшелчә үстерү, бакчачылык белән шөгыльләнә башлыйлар. Бакчачылыкны Литвага башлап караимнар алып килә.

Караимнарның бер өлеше Кырымда утырып кала. Алар үзләрен урап алган рус халкы белән аралашып, тормыш-көнкүреш ягыннан рус культурасын үзләштерәләр, рус теле аларның икенче ана теленә әйләнә.

Ләкин Литвадагы караимнарның хәле башкача: алар берничә йөз ел үзләренә аерым община булып яшиләр, башка халыклар белән артык аралашмыйлар, бигрәк тә семья мәсьәләсендә үз даирәләрендә генә чикләнәләр. Шуңа күрә аларның теле хәзергәчә сакланып кала.

Хәзер Литвада да караим телендә сөйләшүчеләрнең саны көннән-көн азая бара. Яшьләр күбесенчә рус яки литва телендә сөйләшәләр. Ләкин Тракайда яшәүче караимнар семьясында ана телендә сөйләшү әле дә дәвам итә.

Караимнарның күп гасырлардан бирле иҗат итеп киленгән бай фольклоры бар. Алар Польшада чыккан аерым китапларда тупланган. Шушы урында караим фольклорыннан кайбер мисаллар китереп үтү кызыклы булыр дип уйлыйбыз.

**БАБАЙЛАР СҮЗЕ:**

**Болмас акча, әгәр бошка бакча (Бакчаң буш булса, акчаң булмас). Иласай чәчкәндә — куваныс какканда (Чәчкәндә еласаң — сукканда куанырсың). Ындырда мактан битиш бә (Уңышың белән ындырда мактан). Куяш кайнар — артад кыяр (Кояш кызу булса — кыяр арта, яхшы үсә). Битсә ашлык — качар таслык (Уңса ашлык — качар ярлылык). Түксәң бакчаны — хәзерлә янчыкны (Бакчаны сугарсаң — хәзерлә янчыкны). Аз ашим — тинч башим (Аз малым — тыныч башым).**

Караимнарның төп кәсепләре игенчелек, бакчачылык. Бу хәл аларның фольклорларында да чагылыш тапкан.

**ЕЛ ФАСЫЛЛАРЫ:**

Яз башы [яз], яз [җәй], кюзь, кыш.

**ДӨНЬЯ ЯКЛАРЫ:**

Кюн тувуш, кюн батыш, тюшлюк [кюньяк], сырт [тюньяк].

**КӨН ИСЕМНӘРЕ:**

Ек кюн — якшәмбе, ек баш кюн — дүшәмбе, орта кюн — сишәмбе, хан [кан] кюнчәршәмбе, кичи бараски — пәнҗешәмбе, бараски — җомга, шамбат — шимбә.

**АЙ ИСЕМНӘРЕ:**

Кыш ай — январь, каракышай — февраль, сювюнч ай — март, артых ай — апрель, курал ай — май, башкусхан ай — июнь, яз ай — июль, улагъ ай — август, сырых ай — сентябрь, айхырсы ай — октябрь, кюзь ай — ноябрь, согум ай — декабрь.



Фиркович Семен Адольфович

Күргәнебезчә, караим телендәге көн һәм ай исемнәре дә аларның борынгы тормышларының кайбер күренешләрен гәүдәләндерә.

Караимнарның аерым вәкилләре үз телләрендә әдәби әсәрләр иҗат иткәннәр. Шулардан берсе шагыйрь С. А. Фиркович Тракай шәһәрендә яши. Аңа бу ел 70 яшь. Ул үз гомерендә күп кенә шигырь, поэмалар иҗат иткән. Халык көйләренә язган лирик җырлары яшьләр арасында бик таралган.

С. А. Фиркович рус классик поэзиясенең аерым үрнәкләрен, бигрәк тә А. С. Пушкин шигырьләрен һәм аның «Бакча-Сарай фонтаны» поэмасын караим теленә тәрҗемә иткән.

Ул Советлар Союзы гимнын үз телләренә күчерә.

Түбәндә без С. А. Фиркович шигырьләреннән берничәсенең татарча тәрҗемәсен урнаштырабыз:

## Трох шәһәрдә бер кыз сөйдем

Трох шәһәрдә бер кыз сөйдем, атасы бирмәде.
Озак йөрдем яу кырында, үлем килмәде.
Кил, кил, кил, сөйгән дустым, көчыйм мин сине.
Әгәр миңа насыйп булсаң, алырмын сине.

Кайтсам өйгә ни күрим мин — ярым киявдә!
Түккән ачы яшьләремнән киңәйгән Гальвә [1].

[1] Гальвә — күл исеме.

Кил, кил, кил, яшьлек дустым, юат күңелемне:
Эх, син язмыш, бу соң мине алдау түгелме!

Бер сандугач моңлы итеп сайрый әңгердә,
Син дә ялгыз, мин дә ялгыз, елыйк, ди бергә.
Кил, кил, кил, иске дустым, мин котлыйм сине,
Язмыш бармы, юкмы! Ләкин — онытмыйм сине.

## Ник елыйсың, сызланасың

Ник елыйсың, сызланасың,
Кадерлем, чибәр генәм,
Үзеңне дә, күңелемне дә
Юат сабырлык белән.

Вакыт җиткәч, кайтып килер
Ярың синең яныңа,
Кочар сине, иреннәрен
Тидерер маңгаеңа.

Оялма шунда, тартынма
Каршыла дустыңны син,
Чын теләктән, саф йөрәктән
Суз аңа кулыңны син.

Ул юар күз яшьләреңне,
Коткарыр хәсрәтеңнән,
Ярәшү булыр арада
Бер яки ике көннән.

Айларың синең, елларың
Шат үтәр, гүзәл яркай,
Улларың белән кызларың
Ишәер балыклардай...

## Бер йолдызчык балкып яна

Бер кечкенә йолдыз яна
Күк гөмбәзе түрендә,
Бер ут яна, сүнми һаман
Йөрәгемдә минем дә.

Шул йолдызга карыйм да мин
Кинәт очынып китәм,
Мин дә аңарга охшашлы —
Әгәр дә янам икән!

Кайчакта йолдыз, атылып,
Үзгәртә торган төшен,
Киткәли кайчак йөрәктән
Элек яраткан кешең.

Атылган йолдыз яктыртмый,
Мәңгегә сүнеп кала.
Ә сөю көчлерәк аннан
Яңадан кабына ала.

## Караим килгән Литвага

Караим килгән Литвага,
Таныш түгел якларга,
Бик сагынган диңгез ярын,
Кырымның кояш нурларын.
Ачык йөзе, кара күзе,
Үзгә гадәт, теле-сүзе...
Ат уйнаткан юлларында,
Кылыч йөрткән кулларында
Күл эчендә биек сарай,
Аны карап батыр карай[1]
Саклап килгән элек көн-төн,
Тугры ирләр бозмый антын.
Бәрә дулкын яр читенә,
Күбек чәчә дә чигенә,
Тыңлашмакче гүя бу күл
Кырым Кара диңгезенә.

## Карай келип Летувага[2]

Карай келип Летувага,
Таныш тювюль орунларга,
Кеп сагына Эски Крымны
Изляред барча куйашны.
Ачых йюзю, кара кезю,
Озьгя адет, озь тюрк сезю.
Йенгиль учад атланганда,
Кылыч сезлейдир кынында.
Орта сувда Трохта сарай,
Аны коруйд батыр карай.
Кюн, кеч саклэйдыр барьяртын,
Керти адам бузмаст антын.
Чувлэйд толгун, йалэйд йерни,
Кайта ташлэйд кебюклярни.
Клейд теняшмя бу гелгюня
Крымның Кара тенгизиня.



Польша Фәннәр академиясе члены академик А. Заенчковский, Варшава университеты адъюнкты Александр Дубинскийга докторлык дипломы тапшыра. Алар икесе дә Литва караимнары.

А. С. Фиркович әсәрләре аерым журналларда басылып килә. Шулай ук аның әсәрләре Польша профессоры Г. Ковальскийның (чыгышы белән караим) «Караимские тексты на тракайском диалекте» дигән хезмәтендә дә басылып чыкканнар.

Литва караимнары теле борынгы терки телнең күп элементларын үзендә саклап килгән. Шуңа күрә төрки телләр тарихын өйрәнү өчен бу тел кыйммәтле фактик материал булып хезмәт итә.

Лингвист К. Мусаевның караим теле грамматикасын өйрәнүгә багышланган махсус монографиясе бар. СССР Фәннәр академиясенең тел өйрәнү институты караимча-русча-полякча сүзлек чыгарырга әзерлек алып бара. Бу эштә Польша Фәннәр академиясе члены академик А. Заенчковский, Варшава университеты адъюнкты яшь доктор Александр Дубинскийлар (һәр икесе дә Литва караимы) зур хезмәт күрсәтәләр. А. С. Фиркович та сүзлеккә материал туплауда якыннан катнаша.

**МОСТАФА НОГМАН**

---

[1] Карай — караим.

[2] «Караим килгән Литвага» шигыренең караимча варианты, чагыштырып уку өчен, янәшә бирелә.

А. С. Фирковичның бу шигырьләрен Мостафа Ногман тәрҗемә итте.



## *Җәлил Камалетдин*

*Прогрессив ирак шагыйре Җәлил Камалетдин узган елның апрелендә уздырылган Поэзия көнендә Казанда булды һәм Тукай һәйкәле янында үзенең Тукайга багышланган гарәпчә шигырен укыды...*

*... Түбәндә без аның шул шигырен укучыларыбызга тәкъдим итәбез.*

# Багдадтан сәлам!

Күкнең зәңгәр нурларының фонтанына,
Сиңа, Тукай, шигърияттнең ал таңына
Ерак Ефрат буйларыннан, Багдадымнан
Йөрәгемне алып килдем мин янына!

Озак юлның газапларын йөкләп иңгә,
Алып килдем, бөек Тукай, синең илгә,
Бүләк итеп мәхәббәт һәм җырларымны,
Хуш исле бер букет итеп бәйләп бергә.

Күптән, күптән мин бу хакта хыялландым,
Шул хыялдан җырларыма илһам алдым.
Әшкә ашты бу хыялым, Тукай, бүген,
Күрәм азат Казаныңның якты көген.

Көрәшләрдә җиңгән батыр токымнарың
Төзегәннәр Казаныңны өр-яңадан.
Кочагына алып мине, чын дусларча,
Җырларыма илһам бирә гүзәл калаң.

Салкын гүрдән чык та, Тукай, кил яныма,
Әйдә, барыйк көрәшүче Багдадыма.
Без — дусларың. Алып килдем җырда сәлам
Сиңа, Тукай, шигърияттнең ал таңына!

Мин — гади бер җырчы. Сөймим сугышларны,
Сөймим сарай, тәхет, алтын-көмешләрне.
Минем корал — тыныч калам, ялкынлы җыр,
Багышлыйм мин тынычлыкка бар хисләрне.

Бүген менә дус татарлар арасында
Басып торам нур һәм шигырь каласында.
Онытылды йөрәктәге сагышларым —
Туган итеп карый миңа һәркем монда.

Карый миңа Муса әнә киң мәйданнан.
Җырлый заман горурланып аңарга дан.
Менә Муса Моабитта язган юллар...
Көрәшләрдә илһам алдым мин алардан.

Кабул ит син, Тукай, безнең сәламнәрне,
Ялкынландыр көрәштәге әләмнәрне.
Яңа дөнья җиңә җирдә. Анда кеше
Елгаларны бора, яулый галәмнәрне...

Күкнең зәңгәр нурларының фонтанына,
Сиңа, Тукай, шигърияттнең ал таңына
Ерак Ефрат буйларыннан, Багдадымнан
Йөрәгемне алып килдем мин янына!

Иреклe тәрҗемә итте
**ӘХМӘТ ИСХАК.**

*Нил Юзиев*

# МУЗАЛАР ТУГАНЛЫГЫ

## III. Кино һәм татар әдәбияты

Беренче карашка, татар әдәбиятын кино сәнгате белән янәшә кую, алар арасында ниндидер бәйләнешләр эзләү сәер һәм ясалма шикелле тоела. Мин кайберәүләрдә, мәкаләнең исемен уку белән, ышанмаучан бер караш, хәтта скептик елмаю тууын сизеп торам.

— Милли кино сәнгатьләре үскән илләрнең әдәбиятлары өчен бу табигый һәм актуаль мәсьәлә. Әмма татар әдәбиятының кинога нинди мөнәсәбәте булсын! — диячәкләр алар.

Караны ак дип булмый. Ихтимал, минем оппонентларым күпмедер дәрәҗәдә хаклыдыр. Ләкин татар кино сәнгатенең, аякка баса алмыйча, сабый чакта ук егылып калуы әдәбиятыбызны кинога нисбәтән тикшерү мөмкинлеген юкка чыгара алмый әле. Сәнгать төрләренең үзара тәэсир итешү законы кино һәм татар әдәбияты мөнәсәбәтенә күчкәч кенә хәрәкәт итүдән туктап калмый. Тик шунысы бар, татар әдәбиятында бу мөнәсәбәтләр, кино сәнгатьләре үсешкә ирешкән башка милли әдәбиятларга караганда, үзгәрәк төстә чагыла. Башка әдәбиятларда бәхәс күбесенчә сценарийларның үзенчәлеге һәм аларның әдәби кыйммәтләре яки әдәби әсәрләрне экранда ни рәвешле җанландыру тирәсендәрәк куерса, бездә сүзнең милли кино тудыру кирәклегеннән уза алганы юк әле.

Шулай да кино сәнгате татар әдәбиятына төрле юллар белән, төрле юнәлештә тәэсир итә тора. Шундый катлаулы юлларның берсе — тамашачы аша килгән йогынты. Кино сәнгате үскән саен, аның тамашачыга һәм әдәбиятка йогынтысы да үзгәрә, төрләнә бара.

Кино — сәнгать төрләре арасында иң яшьләреннән берсе. Әдәбият һәм музыка кебек сәнгать төрләренең тарихы гасырлар белән исәпләнсә, кинематографиянекен исә дистә еллар белән генә санарга туры килә. XIX йөз ахырларында гына дөньяга килгән кино, үзенә кадәрге сәнгать үсешен һәм техника казанышларын да оста файдаланып, чагыштырмача тиз арада халыкчан сәнгать төрләренең берсенә әверелә.

Патша Россиясендә баштарак чит илләрдән, аеруча Франциядән, сатып алынган фильмнар күрсәтелә. XX йөзнең башларында инде, төгәлрәк әйтсәк, 1907 елдан башлап, Россиянең үзендә Дранков һәм Ханжонков кинофирмалары тарафыннан нәфис һәм документаль фильмнар эшләнә башлый. Яңа сәнгатьтән Идел һәм Кама буе халыклары да читтә калмый. Мәсәлән, Казан губернасында Октябрь революциясенә кадәр 9 киноустановка эшләве мәгълүм. Шундый ук киноустановкалар татарлар яши торган башка губерналарда да булган. Мәсәлән, бертуган Кәримовлар Уфаның иң күркәм урыннарының берсендә — шәһәр бакчасында кинематограф ачалар, аңа «Йолдыз» дип шигъри исем кушалар. Уфадагы татар халкын беренче буларак яңа тамаша белән таныштыралар.

Нинди генә субъектив максатлардан чыгып эшләнмәсен, Кәримовларның бу яңа төр сәнгатьне татар халкына җиткерергә омтылулары тарих өчен ифрат та уңай, прогрессив күренеш иде. Шушы дәверләрдән башлап татар халкын рус һәм бөтен дөнья сәнгате белән таныштыручы тагы бер юл ачыла, ике арада тагы бер әһәмиятле күпер салына.

Әлбәттә, кинематограф халыкка җиңел генә, каршылыксыз гына кермәде. Татар халкы өчен аның өстәмә авырлыклары да булды. Хәрәкәтләнүче җанлы сурәтләрне күрсәтүче кино үзенең асылы белән үк ислам кануннары белән сыеша алмый иде. Шуңа күрә дә ислам тарафдарлары аңа каршы аеруча кискен көрәштеләр. Бу көрәшнең бер чаткысы Г. Тукайның «Мәкаләи махсуса» исемле әсәрендә дә теркәлеп калган. Шагыйрь Уфа халкының кинематографны ничек кабул итүенә тукталып, болай сөйли:

«...Көннәрдә беркөн Кәримовлар, әлбәттә, үзләре сизмичә булырга кирәк, кинематографларында «Мөхәммәт оҗмахы» дигән нәрсәне күрсәтмәкче булып игълан таратканнар. Бу хәлне сизгәч, Уфага яңарак килгән бер «зыялы» мәчеттәге картларга Кәримовларның шундый начар эш эшләячәген сөйләгән. Картлардан хәбәр халыкка да таралган. Халык кызып, витринадагы афишаларны ертып, Кәримов ке-

шеләрен кыйнарга да уйлаганнар. Ләкин Кәримовлар ни дип җавап биргәннәр?

Наданлык сәбәпле көферга төшү җиңел инде:

Алар, без белмәдек дип, зари кылды,
Гәһәрләр күзләреннән җари кылды...

Әлкыйсса, мәзкүр нәрсәне күрсәтмәгәннәр». (Г. Тукай. Әсәрләр. 4 томда. IV том. 1956 ел. 150—151 битләр.)

**Мәчет картлары, дин әһелләре «Мөхәммәт оҗмахы»н күрсәтүне тыюга ирешсәләр дә, гомумән киноның шөһрәтле адымын туктатырга аларның көчләреннән килми.**

**Әлбәттә, кино — катлаулы сәнгать. Аны бөтен тирәнлеге белән аңлау өчен билгеле бер хәзерлек тә, кинематографик культурага ия булу да кирәк. Ләкин бу сәер тамашаны татар халкы башта ук яратып һәм аңлап кабул итте. Моны ничек аңлатырга соң! Бу күренеш, безнеңчә, татар халкының сурәтле фикерләве кинематографик фикерләүгә бик якын булуы турында сөйли. Чыннан да, халык җырларына гына мөрәҗәгать итеп карыйк. Аларда табигать күренешләре белән лирик геройның рухи халәтен янәшә кую, символлар, метафоралар белән эш итү, яки сөйгәненең портретын «эре планда» сурәтләү аз очрыймыни!**

Бакча артларында салкын чишмә,
Тирә-ягын тал алган ла,
Яфраклары саргайган.
Син җанкисәгем хәсрәтендин
Ике күземне кан алган ла,
Йөз генәем саргайган.
Су янына баралмадым,
Басма өстенә басалмадым;
Теләсәм дә, соралсам да,
Сөйгәнемә баралмадым.
*(Сөйгәнемә баралмадым.)*

**Шушындый поэтик принципка корылган җырлар татар кешесе өчен һич тә чыгарма яки гадәттән тыш күренеш түгел.**

**С. Вельтман «Көнчыгыш киносының бурычлары» [М. 1927] исемле китабында Н. Наримановның түбәндәге сүзләрен китерә: «Логик фикерләүләргә караганда образларга күнеккән көнчыгыш халыкларында кино тамашачыны алдан дәвамлы төстә хәзерләүне сорамый торган пропаганда чарасы булып тора. Көнчыгыш крестьяны экранда сурәтләнгән күренешләрне реаль чынлык итеп кабул итә». [5 бит.]**

**Хәзерге заманда кино, җыр-экият, шигырь-роман шикелле үк, татар халкының көнкүрешенә якын үтеп кергән сәнгать төре булып әверелде. Социологлар шундый кызыклы саннар китерәләр: Татарстанда җан башына кино карау хәзер алдынгы капиталистик илләргә караганда да югары тора икән. Мәсәлән, Америкада җан башына кинофильм карау елына 11,8, Англиядә 7, Франциядә 6,4 чамасы туры килсә, Татарстанда бу сан 1966 елда авылда 14 кә, шәһәрдә 23 кә җиткән [1].**

[1] Ә. Таҗетдинов. Татарстанда культура революциясе. «Казан утлары» журналы. 1967 ел. 9 сан.

**Кинoны башка сәнгать төрләре белән чагыштырып караганда да кызыклы гына күренешләр ачыла. 1966 елда, мәсәлән, республикабызның һәр кешесе 19 китап укыган. Ә кино карау елга якынча 20 туры килә. Бу — халыкны эстетик тәрбияләүдә киноның искиткеч зур көчкә әверелүе турында сөйли.**

**Иҗат процессында язучыга хәзер бу хәлне искә алмыйча ярамый. Халыкның әдәби зәвыклары кино тарафыннан да тәрбияләнүе, оптик күрү культурасының үсүе язучылар алдына да искергән традицияләрдән тизрәк котылуны, укучыга тәэсир итәрдәй поэтик алымнарны кыюрак эзләүне сорый. Кино сәнгатенең үсеше, шул рәвешчә, татар әдәбияты һәм язучылары алдына яңа бурычлар, яңа эстетик таләпләр куя.**

**Кино сәнгате халыкны гына түгел, язучыны да эстетик тәрбияләүдә актив катнаша. Хәлбуки, мәсьәләнең бу ягын без онытып җибәрәбез. Теге яки бу язучының әдәби остазлары турында язабыз икән, иң әүвәл аның халык авыз иҗатыннан — экият, җырлардан өйрәнүен билгеләп үтәбез, аннары иҗатыннан үзенә кадәр яшәгән шагыйрьләрнең, прозаикларның тәэсирен эзлибез. Әлбәттә, болар барысы да дөрес. Әдәби укытучыларны табарга, өйрәнергә кирәк. Ләкин чынбарлыкта мәсьәлә күп катлаулырак бит. Язучының матурлык тойгыларын тәрбияләүдә, халык авыз иҗаты һәм әдәбият әсәрләреннән тыш, кино кебек сәнгать төрләре дә якыннан катнаша. Муса Җәлил, мәсәлән, 20 елларда кинога аеруча бер үҗәтлек белән йөри торган була. «Муса киноны бигрәк тә ярата иде. Ул «кино минем иҗатыма зур ярдәм итә» дия иде», — дип яза истәлекләрендә шагыйрьнең дусты Фатих Исхаков («Татарстан яшьләре». 1966. 8 январь). Хәзерге язучылардан кемнән генә сорама, яшь вакытта аларның киноны бер дә экияттән ким яратмаганын, хәзер дә әйбәт фильмнарга яратып йөрүләрен ишетерсез. Димәк, хәзерге заман язучыларының матурлык тойгыларының тәрбияләнүе турында сөйләгәндә, без киноны һәм атаклы кино эшлекләләрен һич тә читтә калдыра алмыйбыз.**

**Тамашачыны яки язучыны эстетик тәрбияләү аша килә торган тәэсиреннән тыш, кино сәнгатенең әдәбиятның үзенә турыдан-туры булган йогынтысы турында да сөйләргә мөмкин. Бу юлы без сүзне киносценарийлар турында алып барабыз.**

**Кино әдәби чыганакка — сценарийга нигезләнеп туа. Кинематографиянең үсүе аның базар аттракционыннан сәнгатьнең бер төренә әверелүе, баштарак тавышсыз һәм сүзсез булып, 30 елларның башында «телгә» килүе әдәбият белән киноны тагын да ныграк туганлаштыра. Әдәбият һәм киноның арадашлыгы нәтиҗәсендә яңа жанрлар — киносценарийлар, сценарийларның либреттолары туа. Без, әлбәттә, татар киносценарийлары тарихы турында авыз тутырып сөйли алмыйбыз. Әмма татар әдәбиятында да сценарийлар иҗат итү буенча аерым омтылышлар булган, һәм бу өлкәдә**

20—30 елларда ук беренче буразналар салынган.

Республикабыз җәмәгатьчелеге Октябрь революциясенең ун еллыгын, әдәбият, театр, музыка өлкәсендәге уңышлар белән рәттән, татар тормышыннан алып иҗат ителгән беренче кинофильм белән дә каршыларга омтыла. Мәскәүдәге Совкино оешмасы 1927 елда «Булат батыр» исемле фильмны төшерү буенча кызу эш башлый. [Фильмның режиссеры — Ю. Тарич, операторы — Г. Гибир.] Кинога төшерү өчен тарихи тема — татарларның Пугачев хәрәкәтендә катнашулары алына. СССРда кино тарихы буенча эшләнгән фильмографик белешмәдә картинаның сценарием Н. Зархи язган дип күрсәтелә. Бу — дөрес факт, әмма тулы ук түгел. «Яңалиф» журналының 1927 елгы 7 санында режиссер Ю. Таричның «Булат батыр» фильмын кую турында сөйләгән докладының кыскача эчтәлеге бирелгән. Ю. Тарич фильмның «мәүзугы казанлы Шакиров иптәш тарафыннан бирелүе, ул мәүзугны атаклы сценарист Н. Зархиның сюжетлаштыруы» турында әйтеп уза. Димәк, Н. Зархи «Булат батыр» сценарием Шакиров әсәреннән файдаланып язган икән [1]. Шакировның Пугачев хәрәкәте турындагы язмалары Н. Зархины, күрәсең, темасының җитдилеге белән дә, кино өчен материалның киң мөмкинлекләр ачуы белән дә үзенә тарткан. Шушы материалга таянып, тарихны да өйрәнеп, үзенең кино эшендәге тәҗрибәсен дә кушып, ул үзенчәлекле генә сценарий иҗат итә.

Режиссер Ю. Тарич Татарстан партия һәм совет оешмаларының фильмны төшерүдә зур булышлык күрсәтүләре турында сөйли. Массовый күренешләрдә төшерү өчен Казан гарнизонының кызылармеецлары җәлеп ителә. Пугачевның Казанга килү юллары — Мамадыш юлы, Арча кырындагы кирпеч сарайлары; шәһәрнең тарихи урыннары — Казан Кремле һ. б., Яңа бистә һәм башка күренешләр — бары да Казанда төшереп алыналар. Губернатор сараендагы, постоялый двордагы, Беренче гимназиядәге күренешләр генә Мәскәү павильоннарында төшерелә.

«Булат батыр»ның экранга чыгуын газеталар даими яктыртып бара, фильмны җәмәгатьчелек хуплап каршы ала [мәсәлән, «Кызыл Татарстан»да 1928 елны Сәгыйт Фәйзуллинның «Булат кайтты» исемле рецензиясе басыла].

«Булат батыр» фильмы кино тарихына караган хезмәтләрдә хәзер дә телгә алына. Мәсәлән, профессор Н. А. Лебедевның «Очерк истории кино СССР» китабында [М. 1965 ел.] 20 елларда куелган һәм уңышлы дип табылган совет фильмнары арасында «Булат батыр» картинасы да бар: «Татар крестьяннарының Пугачев хәрәкәтендә катнашулары турындагы бу фильм,— дип яза автор, — тамашачылар тарафыннан начар кабул ителмәде» [455 бит].

Татар халкы тормышыннан куелган икенче фильм — «Койрыклы йолдыз» [«Комета»]. Аны «Кончыгыш киносы»ның режиссер В. Инкижинов җитәкчелегендәге төркеме 1929 елда Казанда төшерә. Фильм шул ук елның көзендә җәмәгатьчелеккә күрсәтелә һәм бераз төзәтүләр белән 1930 елның җәй айларында экранга чыга.

«Койрыклы йолдыз»ны тәнкыйть салкынрак каршы ала. «Кызыл Татарстан» газетасы, мәсәлән, картинаны «идеология ягыннан да, шулай ук художество ягыннан да яраксыз» әсәр дип бәяли, «Зәки Баязитский хәлфә ролен ифрат начар уйный, татар байларының эксплуататор икәнлекләре бөтенләй күрсәтелми», дип яза. [«Кызыл Татарстан». 1929 ел, 3 ноябрь һәм 1930 ел, 22 июнь.]

Бүгенге кино сәнгате югарылыгыннан карагандэ, «Койрыклы йолдыз», әлбәттә, шактый йомшак эшләнгән. Әмма фильмга газета биргән бәя белән [мәкалә имзасыз басылган] һич тә килешәсе килми. Мондый фикерләрне шул еллар тәнкыйтендәге вульгар-социологик тайпылышның бер ачык чагылышы итеп кенә карарга кирәк. «Койрыклы йолдыз» үзенең идея-сәнгатьчә эшләнешe белән шул заман таләпләренә җавап биргән әсәрләрнең берсе булды. Шуңа да «Яңалиф», «Безнең юл» кебек журналлар бу фильмга киң урын биргәннәр, аны татарның иске тормыш гадәтләреннән көлгән уңышлы әсәрләрнең берсе дип санаганнар. Фильмның уңышлы чыгуына аның танылган киноартист һәм режиссер В. Инкижинов тарафыннан куелуы да [Инкижинов «Чыңгыз хан токымы» фильмында баш рольне уйнаган артист], аның ярдәмчесе татар кинорежиссеры Каюм Поздняков булуы да, рольләрне Галина Кравченко, Зәки Баязитский кебек танылган артистларның башкаруы да ярдәм иткән.

«Булат батыр» тарихи-социаль драма булса, «Койрыклы йолдыз» көнкүреш комедиясе планында куелган фильм. Фильмда татар драматургиясенең Г. Камал, К. Тинчуриннардан килә торган традицияләре ярылып ята. Сценарийның драматик яктан шактый ук оста оештырылуы, көлкеле һәм гыйбрәтле коллизияләргә бай булуы, сюжетның мавыктыргыч корылуы күзгә ташлана.

...Вакыйга 1900 елларда Казанда бара. Баштагы күренешләрдә шәһәрнең көндәлек гадәти тормышы күз алдына баса. Мәшһүр Печән базары... Кабан күле буендагы, Яңа бистәдәге, Болак аръягындагы мәдрәсәләрдә сакаллары билләренә җиткән пишкадәмнәр шәкертләр укытып ята. Тормыш шулай үзгәрешсез, бер көе генә ага бирә.

Көннәрдән бер көнне шәһәр өстеннән ялтырап үткән койрыклы йолдыз — комета бөтен шәһәр халкын тәшвишкә төшерә. Иртән мәчетләргә җыйналган мәхәллә халкы алдында дамелла киләчәк афәтләр турында, тиздән ахырзаман буласы турында сөйли... Куркынган кешеләр дамелла алдындагы зур ак ялыкка акчалар яудыралар. Мәдрәсә шәкертләре дә йолдыз

[1] Хәзергә Шакировның кем икәнлеген ачыкларга мөмкин булмады.

атылу вакыйгасыннан файдаланып кала. Ачлы-туклы яшәгән шәкертләрнең, ниһаять, сәдака белән тамаклары туя.

Базарларда, кибетләрдә, чәйханәләрдә дә сүз — әлеге дә баягы шул койрыклы йолдыз һәм ахырзаман җитүе турында гына.

Либреттист безне шәһәрнең «могтәбәр» картлары белән дә таныштыра. Шундыйларның берсе — Галләмдар хаҗи. Койрыклы йолдыз Галләмдар хаҗины да тәшвишкә сала. «Беткән баш беткән» дип, хаҗи рус сәүдәгәрләре белән сырахәнә, фәхешханәләрдә типтерә, исерек баштан яшь, матур хатынын аерып җибәрә. Аталары тарафыннан хаҗига сатылган бу кыз бик шатланып хаҗи өен ташлап китә. Галләмдар хаҗи һәм Хәят арасында яңадан-яңа кызык маҗаралар туа... Ахыры шул: Хәят һәм байның управляющие, байның үзен алдап, үз өеннән куып чыгаралар, үзләре байлыкка хуҗа булып калалар.

«Койрыклы йолдыз»ның сценарием кем язган соң? Фильмографик белешмәләрдә сценарийның авторы В. Туркин дип күрсәтелгән. Фильмның эчтәлегеннән исә сценаристның татар халкының элекке тормышын шактый ук нечкәләп белүе, татар драматургиясе традицияләре белән якыннан таныш булуы күренә. Ирексездән күңелдә шик туа: «В. Туркин татар тормышын шундый нечкәлекләре белән ничек белер икән!» дип уйлый башлыйсың.

Бу сорауга җавапны профессор Н. А. Лебедевның югарыда искә алынган китабыннан табарга була. Ул, «Көнчыгыш киносы» чыгарган фильмнар турында сөйләгәндә, В. Инкижиновның «Койрыклы йолдыз»ын да тикшереп үтә һәм ачыктаначык: «Сценарий нигезенә татар язучысы Рахманкуловның «Упкын» пьесасы салынган», — дип яза (Н. А. Лебедев. Очерк истории кино СССР. 530 бит).

Кем соң ул Рахманкулов? Рус дөньясына мәгълүм булган бу татар язучысының исеме ни өчен татар әдәбияты тарихына караган хезмәтләрдә, мәкаләләрдә телгә алынмый? Яшь буынга бу исем язучы буларак хәзер берни дә сөйләми бит. Хәлбуки, олы буын язучылар һәм тамашачылар Рахманкуловны һәм аның «Упкын» пьесасын яхшы беләләр. Нәкый ага Исәнбәт, Әмирхан ага Еникиләр 20 елларда Рахманколыйның пьесалары Академия театрында зур триумф белән баруы турында сөйлиләр.

— Әхмәт Таҗетдин Рахманколыйның «Боз астында дулкын», «Упкын», «Үлмәс ханым» исемендәге өч серияле пьесалары куелганда, театрны саклар өчен, атлы милиционерлар чакыра торган иделәр. Аның пьесалары театр өчен гаҗәеп бер вакыйгага әверелә иде, — дип искә алалар алар.

Сәрвәр ханым Әдһәмова Әхмәт Таҗетдин Рахманколыйны шактый ук яхшы белүче булып чыкты. Ул Әхмәт Таҗетдинның Троицкида яшәве, Истамбулда укып кайтуы, әдәби иҗатының һәм журналистлык эшчәнлегенең Октябрь революциясенә кадәр үк башлануы, аның катлаулы, каршылыклы, бормалы юл үтүе турында сөйләде. Сәрвәр ханым Рахманколыйның кино өчен сценарийлар язуын да раслады. Рахманколыйның кино белән бәйләнеше «Койрыклы йолдыз» белән генә чикләнмәгән икән.

— Мин Әхмәт Таҗетдинның берничә сценарий язуын әйтә алам, тик нинди исемдә иде алар, — хәтеремдә калмаган. Соңрак елларда ул Үзбәкстанга барып, «Көнчыгыш киносы» заказы буенча Бохара әмиренең соңгы көннәре турында киносценарий өстендә эшләгән иде. Бохара әмирен белгән кешеләрне эзләп табып, алардан әсәре өчен материаллар җыйнаганын ишетеп беләм, — дип сөйли Сәрвәр ханым.

Әхмәт Таҗетдин Рахманколыйның шәхси тормышы да, әдәби язмышы да күңелсез очлана. Пьесалары сәхнәдә уңыш белән барса да, вакытында алар, ни сәбәптәндер, басылмыйча калалар. Ә 37 елларда алар язучының архивы белән бергә юкка чыкканнар. Пьесалары шикелле үк, киносценарийларының да «Койрыклы йолдыз»дан башкалары эзсез югалган. Ә бәлки югалып ук та бетмәгәннәрдер әле! (Әхмәт Таҗетдин Рахманколый абынулар-сөртенүләр аша хакыйкатькә юл алган. Әмма аның иҗат юлындагы каршылыклары бу үзенчәлекле әдипнең мирасын әдәбият тарихыннан бөтенләй сызып ташларга нигез бирми әле. Әдәбиятчыларга аның иҗатын өйрәнеп, әдәбият тарихындагы урынын билгеләргә вакыттыр инде.)

Татарстан Мәгариф Халык Комиссариаты янында оештырылган Гыйльми үзәк кино сәнгатен пропагандалауны һәм милли кино сәнгатен булдыруны әһәмиятле эшләрнең берсе дип санаган. 1922 елда ук Гыйльми үзәкнең сәнгать секциясендә, әдәбият, музыка, театр, рәсем сәнгате бүлекләре белән бергә, кино бүлеге дә кирәк дип табыла һәм Гыйльми үзәк янында шундый бүлек оештырыла да. Әмма ул бүлек күзгә күренерлек эшләр башкара алмый. Шуңа да Гыйльми үзәк тарафыннан үткәрелгән киңәшмәләрдә (мәсәлән, 1928 елдагы киңәшмәдә) татар тормышын һәм көнкүрешен чагылдырган кинокартиналарның юклыгын татар совет культурасының җитди бер кимчелеге буларак билгеләп үтәләр.

Гыйльми үзәк милли кино сәнгатен аякка бастыруны күздә тотып, төрле чаралар үткәреп карый. Татар фильмнары иҗат итү буенча ярыш игълан итүне шундый чараларның берсе итеп санарга кирәк. Әмма бу ярыш та көтелгән нәтиҗәләрне бирми. Шулай да бу өлкәгә беркадәр игътибар көчәя. Мәсәлән, кинорежиссер А. Л. Генри Гыйльми үзәккә җибәргән хатында (1929. 4 январь) «Фатыйма» исемле киносценарий язуын хәбәр итә:

«Мөселман (татар) халкының аз санлы булмавын, бу халыкларның гадәти тормышында да көчле психологик, тирән драмалы процесслар баруын, самодержавие белән революцион көрәштә аларның аз катнашмауларын исәпкә алып, «Фатыйма»

кинокартинасы өчен сценарий яздым. Мин бу картинада татарларның көнкүрешен, аларның артталыгын һәм культура өчен көрәшләрен күрсәтергә омтылдым». (ТАССР УДА. 3682 фонд. 178 эш. 121—122 битләр.)

Генриңең «Фатыйма» сценарие Гыйльми үзәк коллегиясенә тикшерүгә куела. «Сценарийда бирелгән мөндәриҗә белән тулы рәвештә танышмый торып, фабулага карап кына бу авторның хезмәтенә кыйммәт кую хата булыр иде, — ди Ф. Бурнаш. — Ә инде сценарий либреттосына таянып хөкем йөрткәндә, авторның татар халкы тормышын, көнкүрешен тирән белмәве ачык күренә». Шуннан чыгып, Ф. Бурнаш әсәрнең әдәби кыйммәте аз булуын билгеләп үтә. Фикер алышуда катнашучылар Фатих Бурнаш фикеренә кушылалар.

Кино сәнгате белән һ. Такташ та нык кызыксына. Мәсәлән, ул үзенең «Камил» драмасын нигезгә алып, рус кино эшлеклесе Е. М. Дубровский белән бергә 1930 елда «Камил» киносценариен яза [бу сценарий шагыйрьнең архивында саклана].

Беренче карашка, шагыйрьнең поэзиядән читтә ук торган сәнгать төренә мөрәҗәгать итүе сәеррәк тә тоела. Әмма Такташның кинону үз итүе бик тә табигый күренеш иде. Такташ тормыштагы яңа хисләргә шигырь аша «исем бирү» белән генә чикләнмәде. Ул сәнгатьнең үзендә туган яңалыкларга да гаять сизгер булды, сәнгатьтәге яңалыкларны, шул исәптән киноны да, татар культурасына алып керү өчен тырышты. Киноның халыкны коммунистик рухта тәрбияләүдә искиткеч көчле корал һәм гадәттән тыш популяр сәнгать төре икәнлеген ул яхшы аңлап эш итте.

Аннары мәсьәләнең парадоксрак күренгән икенче ягы да бар. Белгечләрнең язуына караганда, поэзия, башка жанрларга караганда, кино сәнгатенә якынрак тора икән. В. Маяковскийның үзенең бер чыгышында болай ди: «Мин үземнең шигъри сәләтемне кинематографта файдаланырга телим. Чөнки сценарист һөнәре белән шагыйрь һөнәре асыллары белән нигездә бер ук нәрсә.» Бу — кинематографта тәҗрибә алган шагыйрь сүзләре. Шундый ук фикерне кино эшлеклеләреннән дә ишетергә мөмкин. В. Шкловский тавышсыз кино чорында ук үзенең бер мәкаләсендә: «Миңа кино эшлеклеләреннән прозага караганда шигырь фильмга якынрак тора дигән сәер фикерне еш ишетергә туры килә иде», дип язган.

һ. Такташның, соңрак Ә. Фәйзи кебек шагыйрьләрнең үз сәләтләрен кино өлкәсендә сынап карауларын шигъри фикерләү белән кинематографик фикерләүнең якынлыгына нигезләнгән иҗат дуслыгы итеп тә карарга мөмкин.

һ. Такташның «Камил» әсәре белән «Көнчыгыш киносы» да [Востоккино] кызыксына. «Көнчыгыш киносы» сценарий цехларының методбюросы чыгарган бюллетеньдә[1] [Мәскәү, 1932 ел. Апрель. 2 сан] Такташ сценаркесенең язмышын ачыклый торган кайбер фактлар китерелә. Кино эшенә төрле милләт язучыларын тарту максаты белән, 1930—31 елларда «Көнчыгыш киносы» Мәскәүдә һәм милли республикаларда сценарий цехлары оештыра. Шул цехларга сценарий язарга заказ бирелә. Бюллетеньнән шунысы мәгълүм: җыелган 23 сценарийдан сигезе кабул ителгән, дүртесе яңадан эшләргә кайтарылган, калганнары, бөтенләй яраксыз буларак, кире кагылган. Яхшы дип кабул ителгән сигез сценарий арасында һ. Такташның «Камил»е дә бар. Бу факт Такташ әсәренең шул чордагы кино таләпләре югарылыгында торуын раслый. Әмма «Камил» экранда җанлана алмый, кино архивлары киштәсендә генә урын ала. Мактаулы сценарийның уңышсыз финалына нәрсә сәбәп була — авторның вакытсыз үлемеме, әллә башка бер сәбәпме — хәзергә әйтүе кыен. Такташның үлеме комачаулады дип фараз кылсак — әсәр тәмамланган һәм кабул ителгән, төзәтергә кирәк урыннары бар икән — соавторы исән. Күрәсең, сәбәпләре бүтәндер...

Кабул ителгән сценарийлар исемлегендә тагын бер әсәр игътибарны җәлеп итә: ул «Ачкыч табылды» дип атала. И. Усманов һәм А. Файер тарафыннан язылган әлеге сценарий либреттосы «Көнчыгыш киносы» сценарий цехларының методбюросы чыгарган бюллетеньдә басылып та чыккан. Әсәрдә 30 еллардагы вакыйгалар — күмәк хуҗалык төзү өчен булган көрәш җанлана. Методбюро исеменнән язылган мәкаләдә «Ачкыч табылды» тормышчан һәм схематизмнан котылган әсәрләрнең берсе буларак билгеләп үтелә. Әмма бүгенге күзлектән караганда, сценарийда схематизмның шактый көчле булуы үзен нык кына сиздерә. Әсәрнең әдәби эшләнеше шактый зәгыйфь. Бәлки, шуңадыр да, ул экранга күчә алмый кала.

И. Усманов исә «Социалистик Татарстан» газетасында эшләгән журналист Исмәгыйль Усманов булып чыкты. Ул 1930 елларда Казанда оештырылган сценар цехлар турында әле дә яхшы хәтерли, анда язучыларның да кызыксынып йөрүләрен [Г. Минский, М. Әмир] искә ала.

Мин Габдрахман ага Минский белән дә очрашып сөйләштем.

— Кино белән мавыккан бер төркем яшьләр Казанда ачылган киномастерскойда укып йөрдек. Безне күренекле совет режиссеры Николай Васильевич Грачев укытты. Мин үзем шунда "Яңавыл кызы" исемле кинолибретто яздым. Либреттоны охшатканнар иде, хәтта минем белән договор да төзеделәр, — дип сөйләде Габдрахман ага.

Кино сәнгате белән шушы мастерскойда башланган дуслыкны Г. Минский соңыннан да дәвам итә. Ул 1934—38 елларда киноинститутта сценарийлар язу буенча махсус белем ала. Астрахань татарларының «Кара Айдар һәм кызыл гөл» исемле дастанына нигезләп, «Кара Айдар» исемле киносценарий яза, аны диплом эше итеп тәкъдим итә һәм уңышлы яклый.

---

[1] Бюллетень журналист Исмәгыйль ага Усмановта саклана.

(«Кара Айдар» хәзер дә авторның архивында саклана.) Баку киностудиясендә Г. Минскийның сценарийлары буенча нефтьчеләр турында берничә документаль киноочерк, ә 1941 елның көзендә Ватан сугышының беренче көннәре турында «Ватан улы» исемле нәфис фильм куела.

Азын аз инде. Шулай да бөтенләй юк та түгел икән әле үзе. Беренче буразналар кайчандыр сызыла башлаган икән. Әмма татар киносценарийлары тарихы югарыдагы исемнәр һәм әсәрләр белән генә чикләнми.

Мәрхүм Әхмәт Фәйзинең архивында саклана торган материаллар белән танышып утырганда, мин атаклы әдәбиятчы һәм күренекле кино эшлеклесе Виктор Шкловскийның бер хатын очраттым. Ул 1941 елның 11 июнь көне белән билгеләнгән. Хат турыдан-туры кино мәсьәләсенә кагыла. Озын да түгел. Шуңа да тулысы белән күчереп үтүне кирәк санадым:

*«Хөрмәтле Михаил Ильич!*

*Иптәш Фәйзинең «Тукай» либреттосы яхшы сценарийның нигезе була ала. Бездә «Булат батыр»дан соң татар ленталары очраганы юк. Бу әйбердә рус һәм татар культураларының бәйләнешен ныграк күрсәтергә кирәк. Казанда Ленин укыган, Горький, Киров, Лобачевский һ. б. булган.*

*Сценарий өстендә хәзер үк эшли башлаячакбызмы — шуны хәбәр итүегезне сорыйм.*

*Виктор Шкловский».*

Михаил Ильич кем булгандыр, ул нәрсә дип җавап биргәндер, анысы әлегә ачык түгел. Әмма бу кечкенә генә язмадан шактый кызыклы һәм гыйбрәтле фактлар ачыла. Бөек Ватан сугышыннан алдагы елларда ук Габдулла Тукай турында нәфис фильм куелырга уйланылган икән. Бу фикерне шагыйрь архивындагы икенче бер документ та раслый. СССР Халык Комиссарлары Советы янындагы кинематография комитетына Татарстан хөкүмәте исеменнән җибәрелгән эш кәгазендә (1940. 15 август. 4129 сан) «Тукай» кинофильмын чыгару мәсьәләләре буенча Әхмәт Фәйзинең консультант итеп билгеләнүе язылган. Документлардан аңлашылганча, 1940—41 елларда «Тукай»ны чыгару буенча конкрет эш тә башланган. Тик В. Шкловскийның әлеге хатыннан соң унбер көн үтү белән башланып киткән Ватан сугышы гына бөек шагыйрьнең образын кинода гәүдәләндерергә комачаулый.

Бу хатлардан икенче әһәмиятле факт та — шагыйрь Әхмәт Фәйзинең без белеп бетермәгән яңа яклары — кино сәнгате, кино эшлеклеләре белән дә якыннан танышлыгы, аның хәтта «Тукай» фильмы өчен сценарий либреттосы язуы, бөтенләй яңа өлкәдә каләм тибрәтүе дә ачыла.

Шагыйрьнең сеңелесе Зәйнәп ападан мин Ә. Фәйзинең «Тукай» либреттосын архив материаллары арасыннан эзләп каравын үтендем. Берничә көннән соң «Тукай» минем кулда иде инде.

Либретто кечкенә Апушның яңа чыпталар түшәлгән арба өстенә утырып Казанга килүен, атлы абзыйның базар мәйданында «Асрамага бала бирәм, кем ала!» дигән сүзләрне кычкырып торуын сурәтләгән күренешләр белән башланып китә. Тукайның сабый чагы — әсәрнең прологы гына. Язучы Г. Тукайның биографиясен хронологик рәвештә ачу белән мавыкмый, бөтенләй башка юл сайлый. Төп вакыйгалар Габдулла Тукайның 1907 елның көзендә Казанга килүе белән генә башлана һәм шагыйрьнең үлеме белән тәмамлана. Сценарийга нигез итеп Ә. Фәйзи үзенең «Тукай» драмасын — шундагы коллизияләрне, образларны алган. Дөресрәге, Ә. Фәйзи «Тукай» драмасын һәм «Тукай» кинолибреттосын бер үк вакыттарак иҗат иткән.

«Тукай» драмасының куелу тарихына күз салыйк.

«Тукай» драмасын Ә. Фәйзи беренче мәртәбә 1938 елның 15 августында Түбән Осланда дачага җыелган дусларына — язучыларга, артистларга укый. Шунда ук пьеса турында фикер алышу да үткәрелә. Татар дәүләт академия театры пьесаны шушы ук елны үзенең репертуарына кертә һәм репетицияләр башлый. 1939 елны театр сезоны «Тукай» постановкасы белән ачыла.

Ә. Фәйзи, тәнкыйть фикерен искә алып, драма өстендә эшләвен дәвам итә һәм пьесаның драматик яктан җыйнаграк яңа вариантын эшләп театрга тәкъдим итә. Казанлылар 1942 елның апрелендә «Тукай» спектакленең яңа вариантын карыйлар. Шушы ук елларда ул «Тукай» киносценарием дә яза.

«Тукай» пьесасы һәм кинолибреттосы өстендә бер үк вакытта эшләве пьесага да, киносценарийга да тирән эз салган. Бер яктан, ул пьесаның кинематографик фикерләүгә бик якын итеп «корылуына этәргән. Күренеш-эпизодларның күп булуы, аларның тиз алышынып торулары — композициядәге һәм сюжет корудагы бу үзенчәлек, шиксез, Ә. Фәйзинең кино сәнгате белән мавыгуыннан, кино үзенчәлекләрен өйрәнүеннән, кино тәэсиреннән килә. Ә. Фәйзи бу елларда җитди рәвештә кино сәнгатен, аның теориясен өйрәнә, яңа чыккан фильмнарны карап бара. Моны Ә. Фәйзинең шул еллардагы хатларыннан да күрергә була. «Тукай» пьесасын сәхнәләштерүче режиссер Ш. Сарымсаковка язган хатларының берсендә, мәсәлән, шундый юллар бар:

*«...Ә пьесаны сәхнәләштерү ничек бара, Сарымсак? Кайбер күренешләрне әдәби яктан эшкәртүгә, үзгәртүгә мохтаҗ түгелсеңме? Бүген «Ленин 1918 елда»ны карадым (мең әле яңа гына шуны карап кайтуым). Картина мин көткәнгә караганда да әйбәтрәк булып чыкты. Мин еладым да, көлдем дә. Чын сәнгать. Картина гаҗәеп тормышчан. Бу — Ленин турындагы иң яхшы фильм.*

*Безнең спектакль дә дөреслекне шундый тирән ачсын иде, түйганчы еларлык һәм көләрлек булсын иде!»*

Кинематографик фикерләү белән мавыгу пьесада драматик хәрәкәтнең үзенчәлекле корылуына этәрсә, шул ук вакытта ул пьесаның үз вакытында тәнкыйть ителгән композицион таркаулыгын да китереп чыгарган сәбәпләрнең берсе булган. Димәк, Ә. Фәйзинең кино белән мавыгуы аның иҗат эшчәнлегенә ике юнәлештә (уңай һәм кире) тәэсир иткән.

Икенче яктан, «Тукай» либреттосын язганда ул «Тукай» драмасын язу тәҗрибәсеннән дә нык файдалана. Мосфильмның сценарий бүлегенә җибәргән хатларының берсендә Ә. Фәйзи «Тукай» драмасының Казан һәм Уфа тамашачылары тарафыннан җылы кабул ителүе, хәзерге вакытта пьесаның өр-яңа варианты өстендә эшләве турында язуы һич тә очраклы түгел. Драманың уңышлы һәм көчле яклары кинолибреттоның да көчле яклары булып әверелгән. Драматик конфликтның кискенләге, Тукайны коеп куйган шагыйрь итеп кенә түгел, ә ихтыяр көченә ия булган көрәшче, җәмәгать эшлеклесе итеп сурәтләү, шагыйрьнең үзен икеләнүләре, эчке каршылыклары аша ачу, социаль фонның әйбәт сурәтләнүе — кинолибреттоның да көчле яклары. Әмма автор, драмадагы көчле яклар белән бергә, андагы йомшаклыкларны да файдалана. Бу нәрсә аеруча С. Рәмиев образын гәүдәләндерүдә күренә. С. Рәмиев драмада да, либреттода да шундый ук ихтыярсыз, көчсез, ахырда охранкага сатылган шәхес итеп бирелгән. Ә драманың җитешсезлеге булып күренгән күп эпизодлылык, вакыйганың төрле урыннарда баруы һәм тиз алышынып торуы либреттоның табигый хасияте һәм отышлы яклары булып киткән.

Әмма «Тукай» кинолибреттосы драманың кино өчен прозага күчереп чыккан үзгәрешсез варианты гына түгел. Ул «Тукай» драмасыннан нык кына аерыла да. Кайбер образларда аерымлыклар бар. Кайбер образлар өстәлгән. Драмада без Тукайның дуслары арасында Фатих Әмирханны күрми идек. Ә либреттода ул, Г. Камал, Х. Ямашев, эшче-революционер Михайлов, Гафурлар белән бергә, шагыйрьнең якын дусларыннан берсе һәм революцион рухлысы итеп сурәтләнгән. Мәсәлән, либреттода реакциянең һөҗүменә каршы татар интеллигенциясе исеменнән өндәмә язган кеше — Фатих Әмирхан.

Ни өчен соң Ә. Фәйзи Әмирханны пьесада күрсәтми! Тәнкыйть драманың беренче варианты куелу белән — 1939 елны ук — Әмирханның пьесага кертелмәвен әсәрнең бер кимчелеге итеп күтәреп чыга бит.

Әгәр «Тукай» драмасының кульязма вариантларына игътибар итсәк, анда без Ф. Әмирханны очрата алабыз. IX күренеш түбәндәгечә башланып китә:

«Тукай бүлмәсе. Тукай, Камал, Солтан, коляскада Фатих һәм тагын ике кеше. Колахметов тәрәзәдән карап тора. Ямашевның үлүенә бер ел тулу уңае белән, дуслары аны искә алу көненә җыелганнар. Тукай Ямашны сагынып, аңа багышланган шигырен укый. Скрипкада «Ямашны сагыну» дигән көй уйнала». Пьесаның кульязма караламасында Фатих тагын беркичә урында телгә алына, ул Тукайның иң яхшы дусларыннан берсе буларак гәүдәләнә. Пьесаның сәхнәгә куелышында һәм басмасында болар төшерелгән.

Ә сценарийда, әйткәнебезчә, Әмирхан әһәмиятле образларның берсе булып урын алган. Моны нәрсә белән аңлатырга! Шушы рухтагы сорауларга Ә. Фәйзи пьесаны тикшерүгә багышланган киңәшмәдә (пьесаны тикшерү 1942 елның 16 апрелендә үткәрелә) болай дип җавап биргән:

«Бирегә чыгыш ясаучылар ни өчен Карнеев юк, ни өчен Әмирхан юк диләр. Аларның пьесага кертелмәвен шуның белән аңлатырга кирәк: әгәр аларны да өстәсәк, Камал образы төссезләнер һәм аны кабатлау булып чыгар иде. Мин натуралистик юнәлештән китәргә теләмәдем».

Һәм, икенчедән, Ф. Әмирхан 1907 елда авырый башлый: «Ничек итеп аны коляскада, авыру килеш сәхнәгә кертәсең. Сәхнәдә үен шартлы куела, аның үз законнары бар», — дип сөйли Ә. Фәйзи артистларга Әмирхан турында сүз чыккач. (Тукай образын башкарган артист И. Гафуров сөйләгән истәлекләрдән.)

«Тукай» драмасының вариантларын һәм «Тукай» либреттосын тикшергәч, шул нәрсә ачыла: Ә. Фәйзи һич тә Фатих Әмирханның татар иҗтимагый фикер үсешендәге ролен кечерәйтергә теләмәгән. Шунысына игътибар итик: автор Ф. Әмирханны пьесага кертү-кертмәүне сәхнә законнарына бәйләп, пьесаның характеры белән аңлаткан.

Тукайны һәм аның көрәштәшләрен кинода гәүдәләндергәндә инде Ә. Фәйзи кинематографик фикерләүгә таяна. Кинематографның театрга, сәхнәгә караганда мөмкинлекләре күбрәк тә, үзгәрәк тә. Шуңа да драмага сыя алмаган образ кинолибреттода үзенең коляскалары белән дә бик табигый рәвештә урын алган.

Пьесада драматик хәрәкәт диалог аша гына тормышка аша. Киноэкранда сүздән башка да драматик хәрәкәт бирелергә мөмкин (киноның башлангыч дәверен — тавышсыз вакытын хәтерләгез). Диалогны киномонтаж тулыландыра, аппаратның кешегә йөзендәме, күзендәме кечкенә генә үзгәрешләрне дә тотып ала алуы һәм әһәмиятле нәрсәләргә төп игътибарны юнәлтеп, шул әһәмиятле нәрсәне төрле алымнар ярдәмендә я ерагайтып, я якынайтып күрсәтүләре сурәтләүдә киң мөмкинлекләр ача. Ә. Фәйзи дә либреттосын язганда кинематографик хәрәкәтне яхшы тоеп, аның үзенчәлекле табигатен аңлап эш иткән. (Дөрес, автор бирегә әле драма язудан тулысынча котылып бетми, вакыт-вакыт Ә. Фәйзи пьеса язу юлына да төшеп киткәли. Шулай да сценарийда кино өчен отышлы күренешләр дә аз түгел.) Менә бер мисал:

«Тукай Ямашев квартирасына бара, ләкин ул гадәттәгечә өйдә юк...

Тукай үзенең бүлмәсендә. Аны күңелсез, төшенке уйлар биләп алган. Ул үзен

шагыйрь буларак халыкка кирәкми икән дигән фикергә килгән. Ә ул халыкка хезмәт итүдән башка тормышны күз алдына да китерә алмый. Димәк...

Тукайның күзләре кем тарафыннандыр өстәлдә калдырылган кәгазьгә төшә:

«Бүген 11 дә китәм. Әгәр пристаньга төшәргә кирәк дип санамасагыз, хушыгыз! Әминә».

Тукай вакытның соң булуына һәм юлның ераклыгына карамастан, караңгыда абынасөртенә пристаньга йөгерә.

Тукай пристаньга килеп җиткәндә генә пароход кузгалып китә.

Идел яры. Таң ату күренеше. Биек кыя тауда хәрәкәтсез басып торган кешенең силуэты. Шәүлә яктырганнан-яктыра бара. Ул — пароход китеп югалган якка күзләрен текәгән Тукай булып чыга. Аннан соң ул күз карашын кыя астындагы шаулы йөгерек дулкыннарга күчерә.

Шул урыннан ерак та түгел, большевиклар оешмасының яшерен җыелышы бара... Михайлов Лена прискасындагы канлы вакыйгаларга бәйле рәвештә Россия буенча күтәрелгән стачка һәм забастовка дулкыннары турында сөйли...

Тукайның күз алдыннан (дулкыннар фонында) үткән тормышына бәйле истәлекләр уза: Казанга беренче аяк басуы һәм шунда туган шатлыклы минутлары, яшьләр белән беренче танышуы. Әминә белән очрашу күренешләре...»

**Биредә, күрүегезчә, диалог юк. Шуңа карамастан, драматик хәрәкәт бар һәм ул кинематография мөмкинлекләреннән файдаланып, оптик күрүгә нигезләнеп, шактый киеренке итеп төзелгән. Вакыйга, күренешләр биредә тиз агышлы һәм үтә хәрәкәтчән. Без Тукайның бүгенге рухи халәтен дә күрәбез, уйлары аша үткән көннәренә дә сәяхәт кылабыз. Драмада, әлбәттә, боларны — шагыйрьнең үткәннәрен яки аның шәһәр буенча йөрүләрен сәхнәдә кинодагы шикелле күрсәтеп булмас иде. Пьесада сүз яки ремарка белән әйтелеп кенә үтелгән детальләр кинолибреттода кинематографик образга, драматик хәрәкәткә әверелгәннәр. Драматизмны Тукайның үзе турындагы газаплы уйлары да, хакыйкать эзләп Ямашев янына баруы да, акы таба алмыйча кире өенә кайтуы да, төнлә үзенең бәхете-мәхәббәте артыннан пристаньга чабуы да, хәтта төн дә, кыя тау да, дулкыннар да тудыра.**

**Идел дулкыннары бер контекстта безгә шагыйрь күңелендәге ярсулы «дулкыннарга» ишарә ясыйлар. Гадәти табигать көченнән ул тирән эмоциональ көчкә ия булган образга әйләнә. Икенче бер контекстта дулкыннарның мәгънәсе тагы да үзгәрә. Ул бөтен ил буенча күтәрелгән халык хәрәкәтенә ишарә ясый, революционер Михайловның политик стачкалар турында сөйләгән сүзләренә образлы бәйләнештә китерелә.**

**Ә. Фәйзинең архив материаллары арасында тагын берничә киносценарий либреттосы табылды. Берсе аның «Тарих рычагы» дип исемләнгән. Җәя эченә «Яшел манара» дигән икенче исем дә куелган. Ә. Фәйзи үзе әсәрнең жанрын «алты кисәктән торган киноповесть» дип билгеләгән. Либретто саран детальләрдә, әмма шактый киеренке вакыйгаларда илдәге олы социаль үзгәрешләрне, тарихны тудыручы көчләрне ачып сала.**

**...1919 ел. Кызыл гаскәр, меңгазаплар күреп, акларга каршы һөҗүм сугышлары алып бара. Күзге пычрак. Снаряд шартлаулары. Үлгән атлар. Үтерелгән кешеләр. Күренеш кабат алышына. Һәм без солдат котелогын, котелокка тыгылган 3—4 кашык һәм сыек балык шулпасы күрәбез. Зур планда — шуышучы тиф бете. Әсәрнең конкрет геройлары белән дә очрашабыз. Берсе аның — аклар армиясенең офицеры Ильяс. Ул офицер погоннарын ертып ташлап, крестьян киемнәре киенеп, фронттан кача. Вакыйгалар ерак тылга — Ильясның әтиләре авылына күчә. Зариф карт продразверсткадан үзенең ашлыгын яшерә. Аның улы Гариф — комсомолец. Ата белән бала арасындагы конфликт Гарифның яшерелгән ашлык турында ячейкага барып әйтүе белән кискен төс ала. Ләкин әле бу — конфликтның башы гына. Абыйсы Ильясның авылга кайтуы, аның кулаклар кубызына биюе белән вакыйгалар, социаль көрәш тагы да куера. Ике бертуган көрәшнең ике ягына баса...**

**Киноповесть комсомолец Гарифларның җиңүе, әтисенең һәм авылдагы башка күпләрнең дә иске индивидуалистик һәм дини карашларыннан арынып, авылдагы коллектив хуҗалыкка аяк басулары, культуралы тормышка омтылуларын сурәтләү белән тәмамлана.**

**«Тарих рычагы»ның язылу елы күрсәтелмәгән. Үзенең конфликты, стиле һәм образларының сурәтләнүе буенча ул егерменче елларның икенче яртысында язылган әсәрләргә охшаш. Автор үзенең төп игътибарын аерым геройларның индивидуаль психологиясенә түгел, ә социаль төркем һәм сыйныфларның көрәшенә, алар арасындагы каршылыкны ачуга юнәлтә. Шуңа күрә дә, образлар индивидуаль үзенчәлекләре белән ачылуга караганда, социаль-политик көрәштә тоткан урыннары яки шул көрәштәге нинди дә булса киеренке бер вакыйгага катнашулары белән генә аерылалар. Болар барысы да кинолибреттоның язылу елын егерменче елларның ахыры яки 1930—31 еллар дип билгеләргә мөмкинлек бирә.**

**Ә. Фәйзи 30 елларның ахырында нәфис кино өчен тагын бер әсәр — «Пәйгамбәр Әюп һәм итекче Сафа» исемле киносценарий либреттосы иҗат иткән. «Тарих рычагы» белән чагыштырганда, шагыйрьнең әдәби осталыгы үсүе күзгә ташлана. Ә. Фәйзи социаль көрәш күренешләрен сурәтләү белән генә чикләнми, геройның социаль психологиясен ачуга да нык әһәмият бирә. Шәхесне тирәнрәк тикшерүгә омтылу хәтта әсәрнең проблемасында, сюжет корылышында да күренә: автор төп герой итеп итекче Сафаны ала, аның революцион вакыйгалар барышында дини иллюзияләрдән арынуын, сыйнфый аңы үсүен җентекләп сурәтли.**

Башка либреттолары шикелле үк, «Пәйгамбәр Әюп һәм итекче Сафа» да беркайда да басылмаган. Шулай да «Сафа» драматик поэмасы белән таныш укучылар әсәрнең төп эчтәлеге белән нигездә танышлар дип уйлыйм. Чөнки «Пәйгамбәр Әюп һәм итекче Сафа» кинолибреттосы «Сафа» драматик поэмасына нигезләнеп, драматик поэма белән бер үк вакыттарак язылган. Биредә дә нигездә шул ук вакыйгалар, шул ук образлар, әмма инде алар киноэкран мөмкинлекләреннән чыгып бәетылганнар.

Кино «күзе» безгә артиллерия канонадасын да, фронт барган шәһәр күренешен дә, большевикларның өндәмәләре ябыштырылган урамнарны да күрсәтә, эшчеләрнең шәһәр төрмәсен һәм комендатураны камап, штурм белән алуларын да ачып сала.

Кинематографик фикерләү, күрүебезчә, язучының алган проблемасын чишү буенча иҗат мөмкинлекләрен беркадәр баетыбрак җибәргән.

Сценарий һәм поэманың бер үк вакыттарак язылуларына һәм поэмада кино өчен хас алымнарның очрауларына таянып, кинематографик фикерләүнең «Сафа» драматик поэмасына да тәэсире турында сөйләргә мөмкин булыр иде.

Ә. Фәйзи гомеренең соңгы елларына кадәр татар халкының ике бөек улы — Тукай һәм Җәлилгә багышланган фильм булдыру турында хыялланды. Җәлил турында кино чыгару буенча анық Мәскәүдәге кино оешмалары белән сөйләшүләр алып баруы да мәгълүм. Зәйнәп апа Фәйзиева Әхмәт Фәйзинең Муса Җәлилгә багышланган кинолибреттосы да булырга тиеш дип саный, тик әлегә андый либреттоның архивлардан табылганы юк.

Ә. Фәйзи үзе исән вакытта хыялларының тормышка ашуын күрә алмады. Нәфис фильм чыгару буенча барлык омтылышлары аерым әдипнең эшчәнлеге — көрәше генә булып калды, синтезлы сәнгать — кино әсәре булып гәүдәләнә алмады.

Әмма Ә. Фәйзинең барлык киносценарийлары да әнә шундый уңышсыз финал белән тәмамланды дип әйтү дә дөрес үк булмас иде.

В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының 150 еллык юбилеена багышлап Ә. Фәйзигә документаль кинsocherk язарга заказ бирәләр. Ул Булат Гыйззәтуллин белән берлектә киноочерк либреттосын яза һәм шул сценарий буенча 1954 елны документаль фильм куела. (Бу фильмның сценарие да шагыйрьнең архивында саклана.)

20 елларда кабынган «Койрыклы йолдыз»лар озын гомерле булмады. Алар кабынды да, тиз арада сүнде. Ләкин кино сәнгате кабызган иҗат ялкыннары алай тиз генә сүнәрлек булмаган. Сәнгатьнең яңа һәм иң яшь төре булган кино һәрвакыт татарның культура эшлеклеләрен, әдипләрен үзенә тартып торган. Архивлар шуны раслый.

Бәлки, 20—30 елларда татар тормышыннан алып язылган киносценарийлар югарыда искә алынган исемнәр белән генә дә чикләнми торгандыр. Әмма болары да татар әдипләренең чор адымыннан артка калмас өчен яңа дәвер цивилизациясенең бөек казанышын файдалану юлында зур гына эш алып барулары турында сөйли. Алар кино өчен сценарий язуны актуаль социаль заказ итеп кабул иткәннәр, кинолибретто язуны язучының гражданлык бурычы белән бәйләп караганнар.

Архивлар тагын әдәбиятта кино тәэсирендә туып килә торган олы һәм әһәмиятле яңалыклар турында да сөйлиләр. Кино татар әдәбиятында да яңа жанрлар тууга сәбәпче булган. Бу — нәфис һәм документаль фильмнарның либреттолары. Дөрес, бу жанрның үсеше анық базасы — нәфис фильмнар чыгару студиясе булмау белән нык тоткарлана. Татар нәфис фильмнарын чыгару мәсьәләсе исә озак еллар дәвамында чишелә алмый торган бер төен булып килде. Бу мәсьәләне тизләтү турында Мирсәй Әмирнең РСФСР Верховный Советының 1966 ел, декабрь сессиясендә сүз күтәрүе һич тә очраклы түгел. Төенне чишәргә, ниһаять, вакыт җиткәндер инде. Якын киләчәктә исә, үз җирлеге тугач, әдәбиятның бу төре дә күрелмәгәнчә үсеп китәр дип өмет итәбез.

Сценарий — фильмның нигезе. Безнең илдә һәр картинаның титрын сценарист исем-фамилиясе белән башлап җибәрү гадәте юкка гына түгел. Ул фильмның әдәбиятка нигезләнеп тууы турында да сөйли. Сценарий режиссер өчен материал гына түгел, ул, барыннан да элек, тулы кыйммәткә ия булган әдәби әсәр. Совет кинематографиясе атаклы режиссерлары белән генә түгел, Натан Зархи, Довженко, Е. Габрилович кебек атаклы кинодраматурглары белән дә горурлана.

Кинолибреттоларга үги итеп карау гомумән кино сәнгатенең баштарак чорлары өчен хас иде. Хәзер исә бу караш тамырыннан үзгәрде. Киносценарийлар рус совет сәнгатендә әдәбиятның роман, поэма шикелле үк тигез хокуклы бер жанры итеп карала. Алар «Кино сәнгате» журналында гына түгел, әдәби журналларда да басыла, аерым китап итеп тә чыгарыла. Хәтта моннан берничә ел элек Л. Леоновның «Мистер Мак-Кинлиның качуы» исемле киноповестена «Правда» газетасы да урын бирде.

Бездә исә, татар әдәбият белемендә дә, әдәбият тарихында да, киносценарийлар турында гадәттә язылмый. Кинолибреттолар да архив материаллары гына булып кала: алар журналларда да басылмый («Азат хатын» журналында Ш. Хөсәенов сценарийннан өзек басылуны шуңа да хуплап каршыларга кирәк), язучыларның әсәрләре тупланган томнарда да аларга урын бирелми.

Әгәр безнең матбугатта да кинолибреттоларга яшел семафор ачылса һәм язучыларның киноны күздә тотып язылган әсәрләре — киноповесть, кинопоэмалары, сценарийлары басылып торса, язучылар кино сәнгатенә ныграк игътибарлы булырлар, кинолибреттолар иҗат итүчеләр, шаять, беркадәр ишәер иде.

## Әдәбият тарихыннан материаллар

*Зәйнәп Максудова*

# ОНЫТЫЛГАН ШАГЫЙРЬЛӘРЕБЕЗ

Татар мәдәниятенең күп гасырларга сузылган бай тарихы бар. Ул тарихны халык үзе, аның талантлы уллары иҗат иткән.

Мәгълүм булганча, Болгар-Казан иле элек-электән атаклы галимнәре, рәссамнары һәм шагыйрь-әдипләре, алтын куллы һөнәрчеләре белән дан тоткан. Саксин шәһәре әдибе Сөләйман бине Давытның «Зәһрәтөрриаз» («Бакча гөле»)ын, Борһанетдин Ибраһим бине Йосыфның «Рисаләи Борһания» исемле фәлсәфи трактатларын, Якуп бине Ногманның «Тәварихы Болгария»сен алыгыз. Кол Галинең «Йосыф вә Зөләйха» исемле мәхәббәт дастанын, Мәхмүд бине Галинең «Нәһҗ эл-фәрадис»ын, Мөхәммәдъярның «Нуры содур», «Төхфәи мәрдан», «Нәсыйхәт» дастаннарын, Исмәгыйль Кәмал Өмми шигырьләрен искә төшерик. Ниһаять, алтын эшләре остасы Шәһидулла Муса углы кулыннан үткән нәфис сәнгать әйберләрен, Корбан Гали уллары тарафыннан матур рәсемнәр белән бизәлеп салынган мәһабәт биналарны күз алдына китерик...

Үз вакытында бу һәм күп кенә башка талантлар көче белән иҗат ителгән гүзәл әсәрләр Идел-Чулман буйларында гына таралып калмаган, ерак чит илләргә кадәр барып җиткән. Әмма күп гасырлык мәдәният тарихыбыз, шул тарихны тудырган сәнгать әһелләребез җитәрлек өйрәнелмәгән. Бу эшкә соңгы елларда гына ныклап керешелде, дисәк тә әллә ни арттыру булмас кебек.

Шул ук вакытта аерым кешеләр кулында, төрле китапханә һәм архив шүрлекләрендә, тикшеренүчеләр кулы тигәнне, галимнәр күзе төшкәнне көтеп, дистәләрчә әдәбитарихи истәлекләр, кыйммәтле кульязмалар онытылып ята. Без, мәсәлән, Ш. Мәрҗани тарафыннан Болгар әдәбияты үрнәкләре рәтенә кертелгән «Нәсыйхәтө с-салихин», «Бәдәвам» кебек дини-әхлакый китапларның, «Ике былбыл яки Нәүруз бәетләре» шикелле дастаннарның авторлары хакында әлегә чаклы берни дә белмибез. Әсәрләре кайчандыр халык арасында таралып та, исемнәре әдәбият тарихы китапларына кереп алмаган әдип һәм шагыйрьләребез дә байтак. Мисал рәвешендә Оренбург шагыйре Хәлиулла, Тирсә авылыннан Бәшир бине Габдулла, Таш-билге шагыйре Мирхәйдәр бине Гомәр ахун, Алмалы шәһәреннән Хөсәен бине Локман, Мәнгәр шагыйре Баһаветдин улы Фәхретдин, Тарханнан Зыятдин Әхмәт, Зариф Әхмәтҗан углы Казанлы, шагыйрь Вәлиулла Чүпрәле һәм алар кебек байтак әдипләрнең исемнәрен санарга, иҗатларыннан аерым үрнәкләр китерергә мөмкин.

Журналның бу санында укучыларны исемнәре моңарчы онытылып килгән шундый ике шагыйребез белән таныштырабыз.

# НИГЪМӘТУЛЛА БИНЕ БӘШИР

Бу шагыйрьнең тәржемәи хәле хәзергә тулысынча ачыкланмаган. Тик шулкадәресе мәгълүм: ул Казан тирәсендә туып үскән, үз заманының атаклы галим-мөдәррисләреннән саналган Бикчәнтәй Ибраһим углының Бәрәскә авылындагы мәдрәсәсендә укыган.

Бикчәнтәй мөдәррис исә, 35 ел буе үз мәдрәсәсендә укытканнан соң, 1779 елда Уфага казый итеп җибәрелгән. 1800 елда вафат булган һәм Бәрәскәдә күмелгән.

Димәк, Нигъмәтулла бине Бәшир Бәрәскәдә 1779 елга чаклы булган дәвердә укыган, дип уйларга нигез бар. Мәдрәсәдә ул, гадәти дин дәресләре белән бергә, гарәп, фарсы һәм төрки телләрен дә әйбәт үзләштергән. Түбәндә китерелгән шигыреннән күренгәнчә, Нигъмәтулланың теле матур, гарәп һәм фарсы сүзләрен ул бик аңлап, кирәк урыннарда гына куллана. 32 юллык шигырьгә кырыкка якын аңларга кыен сүз кергән (һәр юлга бер генә алынма сүз туры килә, дияргә була). Аларның берничәсе — үз телебезнең борынгы формалары, калганнары — гарәп яки фарсы телләреннән алынган сүзләр.

Мәхәббәт темасына багышланган бу шигырьнең мина очраган үрнәге — исемсез. Әлеге шигырьнең Мәҗлисидән алынган баштагы ике юлы Г. Кандалый җыентыгына да кертелгән.

* * *

Сәлямем ул йөрәкем парәсига,
Тәнем рухы, күземнең карасига;
Кызыл кандыр акар рохсарәсенчә,
Йөрәкем парәсенең ярасыга.

Саңа бер игнә санчылганда, и җан,
Мәңа йөз ук кадалгай иде асан;
Җәмалыңны әгәр күрсәтсә рәхман,
Күзем ягын кыйлам мөрһәм ушал ан.

Кулым, җаным, тамырым, тәндә халем,
Атамдин һәм анамдин миһербаным;
Мөрәввәтлик бәһадир кыйблагяһым,
Рәфигыль-кадер әмарәт дәстегяһым.

Төшебдер башыма сәүдаи пөршүр,
Гаҗәп сәүдаи ки пөршүр вә пөршүр;
Кәрамәт әйләсә хәлляко әүтад,
Кара рохсареми хак әйләгәй шат.

Сүзең сөҗүк, тәвазыглык әдәблик,
Хыялең би тамыг фәрхәндә ләблик;
Вәдаг әйләргә һәм булды домагым,
Һәлякәт килтерүр күп сүзламагым.

Олугларны хак үз лотфига салгай,
Күрешер вакты көнләр яхшы булгай;
Алар һәркайсы ширө вә пәләнги,
Аларның алдида мән мурө ләнги.

Мәни эварә һәм ул уртадин тиз,
Ушал эшкә билемни багладым тиз;
Ничә еллар, ничә көннәр, ничә ай,
Йөгердем — йилдем, әмма булмадым җай.

Ушал көндин бирү тарк итдем ул кяр,
Ходай үлгүнчә тәүфыйкъ әйләгәй яр;
Йәкыйн бел и олугым — ифтихарым,
Башым, малым, тәбарым, һәр нә барым.

Сүзлек:


рохсарәсенчә — йөзенә, бите буенча;
игнә — энә, инә;
асан — җинел, ансат;
җәмал — матурлык;
рәхман — рәхимле алла;
яг — май;
мөрһәм — пластырь, авырткан җиргә яба торган дару;
ушал — шушы;
ан — вакыт;
кыйблагяһ — табыныр урын;
рәфигыль-кадер — бик (югары) кадерле;
әмарәт — әмирлек, боерык бирү;
дәстегяһ — биредә «боерыклар ала торган урын» мәгънәсендә кулланылган;
сәүдай — кайгы, дәрт;
пөршүр — ачы, бик тозлы;
кәрамәт — йомшаклык, юмартлык;
халлякъ — барлыкка китерүче, алла;
әүтад — бу урында таулар мәгънәсендә;
хак — алла;
сөҗүк — татлы;
тәвазыглык — түбәнчелекле, буйсынучан;
хыялең — образың, шәүләң;
би тамыг — канәгатьле;
фәрхәндә — шат, көләч;
ләб — ирен;
вәдаг — аерылу, саубуллашу;
домаг — уй, фикер;
лотоф — шәфкать;
шир — арслан;
пәләнг — юлбарыс;
мур — кырмыска;
ләнг — аксак;
әварә — тилмереп йөрүче;
булмадым җай — урын тапмадым; мәгънәсендә;
тәрк — ташлау, кую;
кяр — эш;
йәкыйн — ачыктан-ачык;
ифтихарым — мактаулым;
тәбар — якын кеше.

# ШАГЫЙРЬ СӘГЪДЕТДИН БИНЕ ГАБДЕЛМӘҖИТ

Безнең поэзиядә реализм яралгылары XIX йөзнең беренче яртысыннан, аерым алганда, Габделҗәббар Кандалый иҗатыннан башлана, дигән караш киң таралган [1]. Инде әдәбият тарихын җентекләбрәк тикшерә башладыкмы, бу карашның бик үк төгәл булмавы ачыклана.

Элек-электән татар поэзиясендә капма-каршы ике агым яшәп килгән. Руханиларга, хаким сыйныфларга хезмәт итүче «югары» әдәбият, «олылар» җырын җырлаучы

[1] Г. Газиз. Г. Рәхим. Татар әдәбияты тарихы; Г. Сәгъди. Татар әдәбияты тарихы.



вагыйзлар, шәйхләр булган. Шул ук вакытта алдынгы карашлы мәдрәсә шәкертләре арасыннан чыккан шагыйрьләр тарафыннан дөньяви мотивлар белән сугарылган җырлар, шигырьләр, шул заман термины белән әйтсәк, **и л а һ и б ә е т л ә р** иҗат ителә килгән. Шәкерт-шагыйрьләр җир тормышына, мәхәббәткә дан җырлаганнар, явызлыкка, гаделсезлеккә каршы көрәшкәннәр. Бу соңгыларының телләре дә бик гади, бүгенге укучыларга җиңел аңлашыла.

Сәгъдетдин бине Габделмәҗитне без әнә шул соңгы төркем шагыйрьләр рәтеннән санын алабыз. Хәзергә аның тәрҗемәи хәленә бәйләнешле бер генә мәгълүмат та очрамады. 1803 елгы су билгесе куелган кәгазьдә фәкать ике шигыре сакланып калган. Шигырьләренең берсенә: «Сәгъдетдин бине Габделмәҗит бине Габделмән бине Габделкәрим бине Арыслан бине Урман» дип үзенең шәҗәрәсен язган. Әмма елын, урынын күрсәтмәгән. Кәгазьдәге су билгесеннән чыгып, Сәгъдетдинне XVIII йөздә житешкән шагыйрь дип уйларга мөмкин.

Сәгъдетдин бине Габделмәҗит шигырьләренең әдәби эшләнеше, теле хакында фикер йөртүне укучыларның үзләренә калдырабыз. Әдипнең бер шигыре тулы килеш басыла, икенчесенең фотокүчермәсе генә бирелә.

## ИЛАҺИ БӘЕТ

Бу кичә, аяз кичә, йиле салкын,
Аһ, яргенәм, сәнең күңлең нәдин салкын?
Аһ, яргенәм, тоткыл кулым, соргыл хәлем,
Валлаһ юкдыр сәндин үзгә сәүәр ярым.
Ишекдин килүб кердүм, кани сәлям?
Ул сәләмне оныттырган кашы каләм,
Кашың каләм, буйи зифа гүзәлләрдер,
Аһ, яргенәм, сәнең өчен нәзек җаным өзеләдер.
Бу кичә, салкын кичә, болыт торур,
Яңы ярлар иске ярны оныттырур,
Яңы ярлар нярләгән аттай торур,
Иске ярлар һич күрмәгән яттай торур.
Яңы ярлар табак-табак аш кәлтерүр,
Иске ярлар карачай күздин яшь кәлтерүр.
Ишекдин килүб кердүм, түр бәнем диб,
Бер екет кочуб ята, яр бәнем диб.
Кылыч алдым суыруб кыяем диб,
Күңлүмә хыял калди: бер аллага куяем диб,

Дингезнең уртасындин сал барадыр.
Сал өстендин бер тутый кош ялбарадыр.
Тутый кошны бавламага җефәк кирәк,
Кызлар белән уйнамага хәйлә кирәк,
Сән болыт тик торасән ай катында,
Ярлының хөрмәте юк бай катында.
Ярлыны ярлыдыр тип хурламаңыз,
Ярлының хөрмәте күп хак каршында.

Чут-чут иткән сувык чакда икәндер,
Уйнаганы-көлгәне җегет чакда икәндер,
Бакчадагы муйнануның яфрагы түгәрәк,
Картлар алса кызларны, яшьләр үбәр күбрәк,

Әрмәганым, әрмәганым, әрмәган,
Әрмәганым бер догадыр һәр заман.

---

Сүзлек

к а н и — кайда;
к а р а ч а й — кара гына (XIX йөзгә кадәр кайбер сүзләрнең азагына иркәләү төсмерен аңлатучы «чай» кушымчасы ялгана торгән була. А г а ч а й, ж и н ә ч ә й һ. б.);
б а в л а м а г а — бау белән бәйләргә;
м у й н а н у — шомырт агачы;
ә р м ә г а н — бүләк, истәлек.

# *Фәтхи Бурнашның тууына 70 ел*



*Коммунист язучы Ф. Бурнашның тууына 70 ел тулды. Һәм без аны талантын фидакарь төстә үз халкына багышлаганы өчен, әдәбиятыбыз һәм сәнгатебезне үстерүгә армый-талмый хезмәт иткәнлеге, художник буларак эзләнүчән һәм тынгысызлыгы, журналист буларак өлгерлеге, көнне төнгә ялгап эшләве, ялкынлы организатор булганы өчен тирән ихтирам белән искә алабыз. Аның фронт сәхнәләрендә дә, зур тамаша залларында да еш яңгыраган шигырь-поэмаларын укып сокланабыз, аларны безгә бүләк итеп калдырган каләм иясенең якты хатирәсе алдында хөрмәт белән баш иябез.*

*Яңалыкка сизгерлек, чорның сулышын тоя белү — язучы һәм публицист буларак Ф. Бурнашка хас сыйфатларның иң күренеклесе, мөгаен, шулдыр. Аның әсәрләре көннең актуаль мәсьәләләренә багышланалар, геройлары — чорның алдынгы фикерләре белән коралланган, яки шуңар омтылучы кешеләр.*

*Язучының яңалыкны кыю яклый белүе, мәсәлән, 30 елларда аның татар операсын үстерүгә куйган хезмәтендә дә ачык чагыла. М. Җәлил белән бергә ул студиянең әдәби бүлеген җитәкли. Шул ук вакытта, милли репертуар тудыру максатыннан чыгып, үзе дә либреттолар яза.*

*Журналның бу санында укучыларга аның «Яшь йөрәкләр» исемле опера либреттосының беренче пәрдәсе тәкъдим ителә. Либретто ахырынача язылып беткәнме, юкмы? — хәзергә кистереп әйтүе кыен. Гәрчә аның тәмамлануы хакында кайбер мәгълүматлар булса да, калган пәрдәләр әлегә табылганы юк. Ләкин аның бу сакланган өлеше дә игътибарга лаек. Геройларның характерларын тирән ачарлык арияләр, үзенчәлекле речитативлар, тыгыз хәрәкәтле һәм җанлы күренешләр язучының опера сәнгатен аңлап һәм белеп эш итүе турында сөйли. Либреттоның бу пәрдәсе һәм тулы планы язучының Мәсгудә һәм Вафа Бурнашевлар кулында саклаучы архивыннан табылды. М. Җәлил белән Ф. Бурнашның бербересенә хатлары да укучылар өчен кызыклы булыр дип уйлыйбыз. Чөнки аларда либреттоның язылуы хакында беркадәр белешмә бар, шулай ук ике шагыйрьнең әле 20 елларның беренче яртысыннан ук башланган керсез иҗат дуслыгы чагыла. М. Җәлил хатын журналга М. Бурнашева тәкъдим итте, ә Ф. Бурнаш хаты СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты архивында саклана.*

Азат ӘХМӘДУЛЛИН.

*Фэтхи Бурнаш*

# ЯШЬ ЙӨРӘКЛӘР

### 3 ПӘРДӘДӘ, 4 КҮРЕНЕШТӘ. ОПЕРА-ЛИБРЕТТОДАН ӨЗЕК

Хәйри, Сәйфулла, Гыйльметдин — Авыл яшьләре
Сәрби, Мәфтуха — Авыл кызлары
Маһирә — бикәч
Галимҗан — бай улы
Галимә — Сәрбинең анасы
Гыймади — Сәрбинең агасы
Сираҗи — Хәйринең агасы
Сафа — Галимҗанның ярчене
Староста
Мулла

Картлар, яшьләр, кызлар һ. б.

## I ПӘРДӘ

### I КҮРЕНЕШ

Галимәнең ишек алды. Уң кулда кыйшайган ике тәрәзәле өй, өй алды күренә. Артта читән, җил капка. Сулда тузган каралты, салам өеме. Арткы планда ямьшәйгән ярлы өйләр тезелеп китә. Еракта, мәчет тирәсендә, берничә яхшы йорт күренә. Кич. Тәрәзәдә ут. Пәрдә ачылганда өй эчендә салмак, моңсу кызлар хоры ишетелә.

Кызлар хоры:

Һаваларда йолдыз ничәдер,
Ничә генә баксаң күчәдер.
Бер карасаң йолдыз, бер уйласаң,
Яшь гомеркәй шулай үтәдер.
Алсуланып матур таң ата,
Асыл кошлар сайрап уята,
Газиз гомер зарыгып үтә ласа,
Бәхетле көн безгә кем ача.

Моңаймагыз, бадиян чәчкән җиргә
Очкан кошлар тавышын ишеткәч,
Кайтыр алар безгә язлар җиткәч,
Кайталмаслар кызлар бер киткәч.

Хәйри керә.

Хәйри җыры:

Һавалардан очкан кошлар кебек,
Ярсый-ярсый канат кагынып,
Туган илгә кайттым мин талпынып,
Күз нурларым, сезне сагынып.
Ай, сылу кызларым,
Ишетегез сагыну җырларым.

Өермәдәй чиксез далаларда,
Үрелдем мин ерак ягада,
Алтын кырлар, матур кызларыбыз,
Юксынмадым сезне кайларда!!!

Ай, җәүһәр ташларым,
Сездән матурларын тапмадым.
Тулкыннардай ярсу диңгездә,
Давылланды ярым, йөрәгем,
Сине сагынып кич тә, көндезен дә,
Сызлады лай минем йөрәгем.
Ай, Сәрбиҗамалым,
Кабул курсә кайнар сәламем!

*(Карана. Читәнгә барып сөяло. Тәмәке төрә. Сызгыра. Артта бер карагай күренә. Кызлар хоры тоных ишетелә.)*

Кызлар хоры:

Һаваларда йолдыз ничәдер,
Ничә генә баксаң күчәдер,
Бер карасаң йолдыз, бер уйласаң,
Яшь гомеркәй шулай үтәдер.

Сәйфулла, әче сызгырып, Хәйриннең артыннан килеп тота. Хәйри ярсынып кача. Кәләпүше төшеп кала. Сәйфулла кәләпүшен кесәсенә сала. Карана.

Сәйфулла җыры:

Илнең шомырт күзләре,
Мысыр күгәрченнәре,
Сезнең өчен бу башым
Ниләр генә күрмәде.
Ах, шаян кызлар сез —
Вафасызлар сез!
Күпме сезне күзләдем —
Дәрткә дәрман эзләдем,
Эргәгездә күп төнләдем,
Төн йокысы күрмәдем.
Ах, кызлар, кемләр сез,
Хәйләкәрләр сез!
Күп уйнады сүзегез,
Гел елмайды күзегез,
Кочакка алып сөйдегез дә,
Җаным, бәгырем, дидегез.
Иртән вәгъдә бирдегез дә,
Кичен алдап көлдегез.
Ах, чая кызлар сез,
Вафасызлар сез!

Гыймади керә.

Гыймади. Кайчан бетәр бу
Дөнья нужасы,
Әле урасы,
Әле җыясы...

Сәйфулла. Гыймади килә,
Тизрәк сызасы...
*(Сәлам арасына керә.)*

Гыймади. Иртәгә йортка
Килен төшәсе,
Бер хәзерлек юк,
Ни хәл итәсе!
Яшьләр бу чакта
Бик уңмаганнар,
Ишек алдын да
Җыямаганнар.
Тулганы чүп-чар,
Салам көлтәсе,
Бераз, булмаса,
Рәткә кертәсе.
Болай тормасын...

*(Сәнәк белән саламны җыя.)*

Сәйфулла. Монда ник качтым...
Гыймади. Салам тузмасын...
Сәйфулла. Хур иттең башым...
Гыймади. Кипсен, җил каксын...
Сәйфулла. Җеннәр сине алсын...
*(Качып китә.)*
Гыймади. Кем йөри монда?
Нинди бу качкын?
Башыңа җитәр,
Алла сакласын!

Сәнәген күтәреп куып китә. Еракта егетләр җырлаган тавыш килә. Мәфтуха чыга. Карана... Бераздан икенче яктан әйләнеп Сәйфулла керә.

Мәфтуха. Көттем, җаным, үзеңне,
Кул болгадым, күрдеңме.
Сәйфулла!
Мин сагынганны белдеңме,
Үзең сагынып килдеңме?
*(Күрешәләр.)*
Сәйфулла. Бәгырем, кыйгач кашкаем,
Әйләндерден башкаем,
Мәфтуха!
Ахыры мине ташладың да
Читкә карый башладың...
*(Әйләнеп китә.)*
Мәфтуха. Әрнетмәче күңелемне,
Җилләр алсын сүзеңне...
Сәйфулла!
Җанын сиңа фида иткән
Шул Мәфтуха түгелме!
*(Янына бара.)*
Сәйфулла. Калсын, җаным, шул көйгә,
Җан ярылмасын икегә,
Мәфтуха!
Сүзем чыкмас һич кешегә
Суырып үптер бер генә!
*(Кочаклый.)*

Дуэт.

Мәфтуха. Җырлар бетмәс бер көйләп,
Сүзләр бетмәс бер сөйләп,
Сәйфулла!
Күрешербез сирәк-сирәк,
Сабыр итәргә кирәк.
Сәйфулла. Хәйләкәр бик кодача,
Бер өметле сүз ача,
Мәфтуха!
Бер уйласаң ялындыра,
Гел алдаша лабаса!

Читән буенда сөйләшәләр, егетләр җырлап киләләр.

Егетләр җыры:
Кызарып кояш чыгадыр,
Белмим кайда бата икән.
Ак беләген ястык итеп
Җаным кайда ята икән.

Безнең урам такыры,
Җиз казанның бакыры.
Шул урамда бер матур бар
Алмый калмам ахыры.

Байның кызы бай кебек,
Өйрәнмәгән тай кебек,
Ярлы кызы, җан кисәгем,
Йомарлаган май кебек.

Урамынны узаем,
Яшел ефәк сузаем,
Яшел ефәк җитмәс җиргә
Бер җыр җырлап узаем.

Егетләр килеп җиткәндә, Мәфтуха керә. Сәйфулла китә һәм егетләр белән бергә әйләнеп керә, Хәйрине үчекли, бераздан каләпүшен бирә. Егетләрнең бер төркеме көлешә-көлешә киләләр.

Т а в ы ш л а р. Әйдәгез, бетерәбез,
Үзебезнең урамны гына бетерәбез,
Кызларның йөрәкләренә тиябез.
Х ә й р и. Әнә Сәйфулла язсын!
С ә й ф у л л а. Әйдә булмаса, үзегезне шайтан алсын!
Җә, Хөсни кызы нәрсә?
*(Гармун өстенә кәгазь куеп утыра.)*
Т а в ы ш. Хөсни кызы — йөзек кашы.
С ә й ф у л л а. Ә Миңли кызы?
Т а в ы ш. Миңли кызы — мунча ташы.
Ха-ха-ха!
С ә й ф у л л а. Аннан — читекче кызы.
Т а в ы ш. Читекче кызы — кура җиләге.
Кибетче кызы — апара чиләге...
Ха-ха-ха!
С ә й ф у л л а. Ә мөгаллимә? Ана кушабызмы?
Т а в ы ш. Кушабыз... Бездән сагынмалык булсын.
С ә й ф у л л а. Мөгаллимә нәрсә?
Т а в ы ш. Мөгаллимә — тел бистәсе.
Нәкъ үзе... тә-тә-тә! Тә-тә-тә! Ха-ха-ха!
С ә й ф у л л а. Ә помошнигы?
Т а в ы ш. Ә помошнигы — карабодай көлтәсе.
С ә й ф у л л а. Ә минә, минә... Мулла кызы нәрсә?
С а ф а. Мулла кызы — мәчет ае.
Х ә й р и. У, бик югары менде тагын. Минә нәрсә:
Мулла кызы — урам себеркесе.
Т а в ы ш л а р. Ха-ха-ха!
Укы, Сәйфулла, укы!
С ә й ф у л л а. Ярый. Бисмиллаһи дип әйтим.
Х ә й р и. Әгүзесен мин әйтим...
С ә й ф у л л а. Әйтсәң, әйтерсең. Мин башлыйм... *(Укый.)*
Тарих мең дә тугыз йөз дә уңдүртенче елында, җәй көнендә, бишенче июльдә, Сембер илендә, Бола буенда, картлар кунакта, яшьләр бурлакта, киленнәр чарлакта, кызлар аулакта чакта, бабайлар түр башында, эбиләр мич башында ятканда, абыстайлар килә сапканда, агайлар трубка тартканда, малайлар чапканда, егетләр «капканда», Бикшик кызларына кушылган кушаматлар:
Т а в ы ш л а р. Шәп-шәп...
С ә й ф у л л а. Хөсни кызы — йөзек кашы,
Миңли кызы — мунча ташы,
Читекче кызы — кура җиләге,
Кибетче кызы — апара чиләге,
Мөгаллимә — тел бистәсе,
Помошнигы — карабодай көлтәсе,
Зифа кызы — бәхет сөенчесе,
Мулла кызы — урам себеркесе,
Гыйрфан кызы — китап киштәсе,
Куштан кызы — керосин мичкәсе,

Сәлим кызы — бодай ярмасы,
Мәзин кызы — шайтан арбасы...

Т а в ы ш л а р. Ха-ха-ха!
Менә кызларны кыздырабыз,
Арчи кызлары алдында биетәбез...
Көертәбез...

Х ә й р и. Үзләре дә буш куймаслар, аны карагыз...
Тукта, тссс... Тәрәзә чиртәләр...

С ә й ф у л л а. Китсәнә!

*(Тәрәзәгә бара.)*

Кызлар, кызлар!
Ачыгыз әле пәрдәгезне!
Үлчим әле гәүдәгезне.

К ы з. Әллә кеше бар, шунын төсе бар?!

С ә й ф у л л а. Алла ярдәм бирсен.

К ы з. Синең кебек матурларны монда бирсен!

С ә й ф у л л а. Синең кебекләрне сөрсен, башкаларны бирсен, дисең булыр.

К ы з. Башкалар кибәк, синең кебек асыллар сирәк.

С ә й ф у л л а. Син инде бигрәк... Пәрдәңне сирә төш,
Мондарак килә төш.

К ы з. Җибәрермен ачып, китәрсең качып...

*(Ача. Сәйфулла бәрелә.)*

Т а в ы ш л а р. Ха-ха-ха!

С ә й ф у л л а. Әй билләһи үзегез, йөрәкне өзә сүзегез.
Карар идем, күрмим йөзегез, нәрсә дидегез?

К ы з. Ишетелми сүзегез, якынрак килегез.

С ә й ф у л л а. Ишетсән, ишетмәгәнгә салынасың...

К ы з. Ишетсәм йөрәгемә саламын да, ишетмәгәнгә аптырап каламын.

С ә й ф у л л а. Ялганлыйсың лабаса!

К ы з. Әгәр булса сүзем хата!

С ә й ф у л л а. Сүзләрең йөрәгемә ята да, ишетеп бетерә алмыйм пәрдә аша. *(Пауза.)* Мәфтуха, Сәрби, Хөсби, Камилә, Гадилә, торасыз агач кебек катып, тәкәббер бакчасына батып, нигә йөрим кызлар исемен сатып, ичмасам йокларга иде ятып. Кем йөри шунда идән пычратып?

К ы з. Кем кирәк?

С ә й ф у л л а. Синең кебек асыл кош кирәк.

К ы з. Канатым юк шул очарга!

С ә й ф у л л а. Кирәкми очарга, үзең кирәк кочарга!

К ы з. Аллам сакласын. Мин табармын башкасын...

С ә й ф у л л а. Әй күзгә бәрән, сиңа сүзем әрәм!
Кызлар, кызлар! *(Пауза.)* Хәдичә, Сәрби, Камилә, Гадилә, кара әле дим күземә, булмассыңмы үземә...

К ы з. Үзеңә буласы иде. Куеныңа туласы иде...

С ә й ф у л л а. Качма әле, монда карасана.

К ы з. Тәрәзәбез пыяла, карасам йөзем ояла.

С ә й ф у л л а. Курыкмагыз, тимәс күзебез, тисә күзебез,
Исме Әгъзәм укып өшкерербез үзебез.

К ы з. Сөйләсәнә гадәтчә, без белмибез гарәпчә,
Әйтерсеңлә, байбәтчә...

С ә й ф у л л а. Ай кабарган күркә. Адәм качар синнән бер күрсә...
Кара әле, кодача, кодача!

К ы з. Китегез булмаса, әнә хәзер ай калка... Йөрисез төнката. Аякларыгызда чабата, кайсыгызда киез ката, кайтыгыз, ичмаса... Кызлар ялгыз да ята...

Сәйфулла. Әй кырыкмыш тай... Бирсен ходай...

Сөйләшә, тәрәзәдән керә.

Егетләр. Әй, кертәләр, кертәләр!

Барысы да керәләр. Хәйри ялгыз кала, Сәрби чыга.

Хәйри.
Сине күреп ничек, Сәрбикәем,
шатлык белән тулды йөрәгем.
Ал, канатым минем, ал, санатым,
сагынычлы шушы бүләгем.

*(Төргәк чыгара.)*

Сәрби *(карап).*
Ничек кенә рәхмәт әйтим инде,
бүләкләрең кызлар күрерләр.
Һич беркемне түгел, бары сине
Хәйри егет сөя диярләр...

*(Бүләкләрне актаралар.)*

Хәйри.
Сине генә, Сәрби, сине генә,
сине генә сөям, чибәрем...
Тик син генә, иркәм, күрәләсең
йөрәгемнән сызган эзләрен.
Мин йөргәндә ерак Алтайларда,
Алтын-көмеш чыккан зур тауларда...
Тыныч сәгать жанга тапмадым.
Тик бер генә теләк мин ятладым —
Күз алдымда сине сакладым.

Эчтә акрын жыр ишетелә. Башта акрын, моңсу, аннан көчәя, жанлана бара.

Сәрби.
Сине сагынып үтте кыш айлары,
Буй-буй киндерләрне мин чиктем.
Озын юллар чигеп һаман көттем.
Бер чиктем дә, бәгырем, бер сүттем.
Сүтелмәсләр инде чигешләрем,
Морадыма хәзер ирештем.
Синең белән тагын мин күрештем.
Алтын сүзләреңне ишеттем.

Музыка бию көенә күчә. Хәйри Сәрбине кочаклап иркәли.

Дуэт.

Аерылмабыз инде, Сәрбикәем *(Хәйрикәем).*
Туй итәрбез көзләр житкәндә.
Ничек рәхәт булыр, жан дускаем,
Гөрелдәшеп гомер итәргә...
Кышын тагын эшкә мин китәрмен *(син китәрсең).*
Алтын тауның серен ачармын *(ачарсың).*
Алсу кырлар жәен бәдрәләнгәч,
Туган илгә тагын кайтырмын *(кайтырсың).*
Тормыш кырын бергә гизәрбез,
Өмет юлын бергә чигәрбез...

Фәтхи дускай!

Синең кечкенә генә хатыңны күптән алган булсам да, җавап яза алмадым. Чөнки нәкъ шул араларда Арканов үзе Казанга барды һәм ул анда сине күреп озаклап сөйләшергә, либретто белән танышырга һәм аны эшкә кертү юлларын конкрет киңәшергә булган иде. Ләкин ул сине ничектер күрми кайткан. Ә аннан соң Мансур һәм Җ. Фәйзи сине «шушы көннәрдә Мәскәүгә килә» дип әйттеләр. Менә шулай итеп сиңа җавап язылмады.

Хәзер эшләр болай тора: (...) 1/XII-дән студия үзенең эшен тәгәлли. 5/XII белән 20/XII арасында студиянең бөтен төп көчләре Казанга кайтып бетә. Шулай итеп хәзер безнең нәкъ күчүгә бәйләнгән оештыру эшләре (...) Шуңлыктан синең хәзер Мәскәүгә килеп, либреттоны тикшерергә куюың урынлы булып бетмәс, студия җитәкчелеге аңа вакыт таба алмас. Шуның белән бергә җитәкчеләребез 1/XII-дә үк Казанга китәләр.

Шул яктан килгәндә, синең либреттоны Казанга баргач уку — иң дөрес юл булыр. Управлениедә укылган һәм иҗаби кабул чыгарылган икән, анысы бик яхшы. Казанга баргач та (15/XII ләрдә) үзебезнең художество җитәкчеләре һәм композиторлар белән бергә җыйналып укырбыз да, алда эшләү юлларын конкретлаштырырбыз.

Казанга баргач, яңа план һәм яңа масштабта эшли башлаячакбыз инде. Анда якынаербыз. Хәзер киңәеп эшләргә мөмкин булыр. Мин тематик план төзеп ятам. Баргач, аны бергәләп тикшербез, тутырырбыз. Мин тематик планга синең «Яшь йөрәкләр»не керттем. Тагын нинди тема һәм сюжетларың бар? Уйлый тор. Хат яз.

25/XI—1938. Сәлам белән: Муса Җәлил.

Муса!

Әминә ханымга һәм кечкенәгә күп сәлам! Соңлап булса да дөньядалыгыңны белдергән өчен, әлбәттә — үзеңә дә!

Мин кичә тагын маләри белән егылдым. Гомумән бу 1938 ел җәйдән бирле 3 ай авырдым, бусы 4 нче кат китте. Һич авырмый идем болай, шайтан белсен, нәрсә булды: — һавалар шулай булды, ахры, бу ел.

Һәр хәлдә, авырудан бик эч пошып, нервланып ятканда синең хатыңны алу миңа бик күңелле булды. $t^\circ$ 39° белән үк җавап язарга таяндым.

Кайтуыгызны белеп, синең кайтуыңа бик шатландым. Бөтенләй кайтырга иде сиңа. Мин сиңа алмашка бер квартира да уйлап куйган идем инде. Һәр хәлдә, кайтуың бик, бик һәйбәт. Синең белән сөйләшәсе сүзләр бик күп — операдан башкалар.

Ә бу мәсьәләдә шулай:

Авыру сәбәпле, үзем дә һаман келәнеп кенә барырга җыена идем, ә соңгы тапкыр Җ. Фәйзи белән сөйләшкәч, сезне монда күтәргә карар биргән идем инде.

«Таһир-Зөһрә»не бик тырышып, озак һәм күп эшләремә, авыру-саулыгыма зарар итеп булса да, бирелеп эшләдем, укыган кешеләр бик яраттылар. Үзем бик тыныч — чөнки, беләсең, аның кирәклеге, вакытлылыгы һаман да, һәр вакыт. Бертигез — аның белән теләсәң кайчан шөгыльләнергә мөмкин. Ярый, кайткач укырбыз, киңәшербез.

«Яшь йөрәкләр» турында да сөйләшербез.

Аннан: мин шигырь белән 4 пәрдәлек балалар пьесасы яздым. Управление алды, басарга алдылар, Җ. Фәйзи һәйбәт музыка язган. Мин һәм Җәүдәт, бу эшне тиз дәвам иттереп, опера театры өчен аны балалар операсы итәргә кирәк, дип уйлыйбыз. Бик кызыксындыра торган эш, дөрес бит?

Планда моны кузда тоту безнең өчен дә, сезнең өчен дә, яна эш буларак җәмгыять өчен дә, күңелле бер эш булыр иде. Җәүдәт аның белән тулы таныш — сөйләшерсең.

«Аталар һәм балалар»ның яңадан тәрҗемәсен бетердем.

5—10/XII ларда «Онегин»ны редакцияләштерергә керешәбез. Редакторлары — Подьячев һәм Әхмәт Исхак. Апрель башына бетермәкчебез.

1 нче майга бөтенләй бушап, бөтен җәйне сезнең эшкә багышларга уйлап торам. Менә шул.

Тагын сәлам, тагын рәхмәт белән — Ф. Бурнаш. 28/XI — 38.

P. S. Хатына кадәр үзегез кайтып җитегез. Ф.

*Сәлам Алишев*

# БӘХТИЯР КАНКАЕВ

*Журналыбызның узган елгы 1 санында СССР Фәннәр академиясенең Казан тел, әдәбият һәм тарих институты фәнни хезмәткәре С. Алишевның «Пугачев полковнигы» исеме астында татар халкының легендар герое Мәсәгуть Гомәров турында тарихи очеркы урнаштырылган иде. Бу очерк басылып чыккач, редакциягә дә, авторның үзенә дә укучылардан бик күп хатлар килде. Алар 1773—75 елларда Пугачев восстаниесенә татар халкының катнашуы турында материалларны тагы да урнаштыруны, крестьяннар сугышында күтәрелеп чыккан башка татар полководецлары белән таныштыруны үтенәләр. Укучыларның шул үтенечләрен искә алып, без түбәндә С. Алишевның Пугачев полковнигы Бәхтияр Канкаевка багышланган язмасын тәкъдим итәбез.*

Редакция.

Халык арасында «Бәхтияр юлы», «Бәхтияр аланы» дигән сүзләр йөри. Картлар элек вакытларда Бәхтияр турында җырлар җырлануын хәтерлиләр. Менә шундый җырларның берсе:

Бәхтияр егет ир, имеш.
Буй бирмәм мин, дигән, имеш.
Әрмияләре таралгач,
Бер ходаем орды, дигән, имеш.

Кем соң ул Бәхтияр? Кайларда булган, ни эшләп йөргән ул? Нигә аның образы, исеме халык хәтерендә хәзергә кадәр яши бирә?

* * *

Күп документларда Бәхтияр Канкаев «мишәрләр полковой старшинасы», «мишәрләр полковнигы» дип йөртелә.

XVIII гасыр галиме П. И. Рычков әйткәнчә, «мишәрләр шул ук татарлар алар, исемнәре белән генә аерылалар»[1].

Татарларның бу төркеме Башкортстан җирләренә элек-электән урнашкан була. Казан һәм Зөя провинцияләреннән рус алпавытларының нык изүе һәм патша хөкүмәтенең көчләп чукындыру политикасы үткәрүе нәтиҗәсендә, татар крестьяннары авыллары-авыллары белән дә, берәмләп-берәмләп тә Оренбург ягына таба күчеп китәргә мәҗбүр булганнар. Башкортстан территориясендә татарлар саны монда күчеп утыручы Казан татарлары исәбенә XVIII гасыр азагына кадәр арта барган. Бу турыда бик күп фактларны китерү урынына шул заман кешесенең, Казан губернаторы Волынскийның, сүзләрен искә төшереп кенә үтәбез. Ул болай яза: «20 ел элек башкортлар үзләре генә 35 мең яки, күп булса, 40 мең генә иделәр, ә хәзер (1730 еллар — С. А.) качкыннар белән 100 меңнән артып киттеләр, бигрәк тә Казан, Сембер һәм башка өяз ясаклы

[1] П. И. Рычков. Топография Оренбургской губернии. Спб. 1762, стр. 103.

татарларының күп өлеше Башкортстанга күчтеләр»[1]. Ә инде 1770—1771 елларга караган рәсми документлардан Оренбург губернасында: татарлар (шулар эчендә бераз гына мари һәм чувашлар) — 115315; мишәрләр — 15517; барысы — 130832 ир кеше; башкортлар барысы — 105938 ир кеше булуы билгеле[2].

XVIII гасырда Башкортстан җирләрендә яшәүче халыкның социаль-экономик көнкүреше нык начарайган. Моның сәбәбе: беренчедән, промышленниклар тарафыннан заводлар салу өчен җирләрнең үзләштерелүе булса, икенчедән, патша хөкүмәте алып барган милли-колониаль политиканың монда да көчәюе, өченчедән, халыкның үз феодал эксплуататорлары тарафыннан торган саен ныграк изелүе.

XVIII гасырның беренче яртысында башкортлар һәм мишәрләр бер йорттан елга 25 тиен ясак түләргә, чиновникларны, офицерларны озату, авылдан авылга йөртү өчен олау бирергә, аларны ашатырга һәм һәр елны хәрби хезмәткә 1500 дән артык кеше озатырга тиеш булганнар.

Мишәрләр исә шулар өстенә башкорт старшиналарына оброк та түләргә мәҗбүр булганнар. Бу нәрсә мишәрләр белән башкорт старшиналары арасында каршылыклар тудырган һәм 1735—1740 еллардагы восстание вакытында мишәрләр, хөкүмәт яклы булып, башкортларга каршы чыкканнар. Шуның өчен хөкүмәт мишәрләрне башкорт старшиналары бәйлелегеннән коткарган, ягъни алар били торган җирләрне башкортларныкы дип түгел, ә мишәрләрнең үз хосуси милке дип таныган. Берничә ел алар ясак түләүдән дә азат ителеп торганнар. Ләкин тиздән мондый льготалар бетерелгән һәм мишәрләр патша хөкүмәте тарафыннан башкортлар белән бертигез дәрәҗәдә талана башлаганнар. 1754 елдан башлап башкортлар һәм мишәрләр мона кадәр үзләре табып житештерә торган тозны казнадан сатып алырга мәҗбүр ителгәннәр. Тоз ул вакытта бик кыйммәт булган. Арыш онының поты 10 тиен булганда, тозның поты 40—50 тиен йөргән. Тоз сагып алуны керткәннең соңында ясак җыю бетерелгән, ләкин хөкүмәт тоз сатудан ясакка караганда да күбрәк файда алган. Башкортлар һәм мишәрләр шулай ук тигез рәвештә рекрут, ат, олау биргәннәр, һ. б. йөкләмәләрне үтәгәннәр. Болар өстенә алпавытлар, заводчы-промышленниклар аларның җирләрен, урманнарын тартып алган, чиновниклар төрле кыерсытулар күрсәтә торган булганнар.

Башкортстанның татар, мари, чувашлардан торган, типтәрләр һәм бобыльләр дип йөртелгән халкы 80 тиенлек ясак (тозны алар сатып алмаганнар) һәм башкорт старшиналарына җир өчен оброк түләгәннәр, крепостьлар төзү эшен башкарганнар.

Татарларның күпчелеген тәшкил иткән ясаклы крестьяннар, шул вакытлардан аз гына элегрәк Казан һ. б. өязләрдән куылган булып, дәүләткә җан башыннан 1 сум 10 тиен налог түләгәннәр.

Крестьяннарның бу төркемнәре арасында каршылыклар XVIII йөзнең икенче яртысында бетә барган. Мишәрләр инде башкортлар белән берлектә патша хөкүмәтенең колониаль политикасына каршы көрәшкә чыкканнар. Мәсәлән, 1747 елда яңа салым турындагы указга каршы типтәрләр һәм мишәрләр восстаниесе кабынып киткән. Ә 1755 елда Башкортстан территориясендәге барлык халыклар бердәм булып Батырша восстаниесендә катнашканнар. Батырша (Абдулла Мязгилдин) үзе мишәр, ә аның иң якын ярдәмчеләреннән унысы татар, бишесе башкорт булган[3]. Восстаниечеләр милли-колониаль изүне, руслаштыру политикасын бетерүне максат итеп куйганнар. Восстание җиңелгәч, патша хөкүмәте һәм аның ялчылары — урындагы чиновниклар — колониаль изүне тагын да көчәйткәннәр. Бу үз чиратында халыкның һәр төркемендә көчле ризасызлык тудырган. 1773—1775 еллардагы Пугачев восстаниесенә массаларның теләп кушылулары нәкъ әнә шул ризасызлыкның чагылышы. Башкортстан территориясендә яшәүче төрле милләт крестьяннарының Пугачев восстаниесенә кушылуын күрсәткән саннарга күз салыйк. 1775 елның 16 февралендә Уфа провинциаль канцеляриясе Уфа провинциясендәге рус булмаган халыкларның восстаниегә кушылулары турында Оренбург губерна канцеляриясенә ведомость төзеп җибәрә. Бу ведомость буенча восстаниегә катнашучы башкортлар — 42114, татарлар — 34285 (шулар эченнән мишәрләр —

[1] Н. А. Фирсов. Инородческое население... Казань, 1869, стр. 552—553.
[2] Материалы по истории Башкирской АССР. М. 1956, т. IV, ч. 2, стр. 12—14.
[3] В. Н. Витебский. И. И. Неплюев и Оренбургский край... Казань, 1897, т. III, стр. 882.

7056) мари, удмурт һәм чувашлар — 10180 кеше була[1]. Сугышның Себердән алып Мәскәү губернасы чикләренә кадәр җәелгән булуын искә алсак, аңа никадәр күп халык катнашуын һәм крестьяннар сугышының ни күләмдә зур һәм дәһшәтле булуын күз алдына китерү читен түгел.

* * *

1773—1775 еллардагы крестьяннар сугышында һәр халык үз эченнән атаклы полководецларын биргән. Алар арасында «мишәр полковнигы» Бәхтияр Канкаев зур игътибарга лаеклы.

Бу исем махсус тарихи әдәбиятта еш телгә алына, аңа кагылышлы булган документлар да байтак. Ләкин моңа кадәр Канкаев турында аерым язып чыгучы булмады. Бәлки, моңа сәбәп аның кайда, кайчан туганлыгын, ничек үсүен, гомеренең соңгы елларын ничек уздыруын һәм кайда үлүен белдергән документларның булмавы яки әлегә кадәр табылмавындадыр.

Пугачев полковнигы Бәхтияр Канкаев крестьяннар сугышына, аның башланган көннәреннән алып соңгы айларына кадәр диярлек, актив катнаша. Ул 1773 елның октябрь — ноябрь айларында Красноуфимск тирәсендә күтәрелгән татар крестьяннарының берсе була. Ноябрь башында ул инде восстаниечеләр арасында «полковой старшина» булып таныла. Шул ук елның 5 декабрендә Пугачев, аның исеменә адреслап, махсус указ бирә. Бу указда крестьяннар патшасы «Петр Федорович» — Пугачев полковой старшина Бәхтияр Канкай углын рус администрациясенә һәм помещикларга каршы көрәшкә чакыра: «Кемнәр баш тарткучы вә каршылык кылгучы — бояр, янарал вә майор, вә капитан, вә гайренең башын кисегез, малын талагыз... бер вакыт сезләрне анлар ашады вә янә минем колларымны ирексез, ихтыярсыз итте... Кем бояр колы вә крестьян залимдан грифтар[2] улса, бүген андин азат»[3].

Пугачевның Бәхтияр Канкаевка аталып язылган бу указы белән рухланган крестьяннар урындагы власть кешеләрен, алпавытларны үтерәләр, аларның имениеләрен, промышленникларның заводларын тар-мар итәләр. Югары Серги заводында эшләүче крестьяннар старостасы Аким Ратошкин: «Декабрь аенда Бәхтияр Канкаев һәм Гомәр Күскеев җитәкчелегендә мишәрләр отряды заводка килеп төн кунды, алар завод приказчигы Петр Блинов кибетеннән товарлар, тегермәненнән 2 яшьлек айгыр һәм «господский» йорттан җәйге кибитка алдылар, ә крестьяннарга бернинди начарлык эшләмәделәр»[4], — дип күрсәтте.

Декабрь аенда Бәхтияр Канкаев үз отряды белән Югары Серги заводыннан Тура заводына кадәр барып җитә. Бу заводларда вакытта ул Зарубин — Чика белән элемтә урнаштыра. «Үз хезмәтен күрсәтергә килгән» Канкаевка Зарубин «патша хәзрәтләре Петр Федоровичка турылыклы хезмәт итәргә» кушып указ бирә. Бу указда полковой старшина Канкаевка Абдулкәрим Күскеевны ярдәмче сотник итеп билгеләү һәм «тирәяктагы башкортлар, мещеряклар (мишәрләр), татарлар, черемислар һәм россияннардан: ике өйдән бер кешене армиягә алырга» рөхсәт бирелүе турында язылган. Канкаев пугачевчыларның икенче бер танылган полководецы Иван Наумович Белобородов белән дә тыгыз элемтәдә була һәм аның күрсәтмәләреннән чыгып эш итә. Белобородов белән язышу кәгазьләреннән Канкаевның Үзәк Урал районында, Кунгур белән Екатеринбург (хәзерге Свердловск) арасында восстаниечеләрнең төп җитәкчеләреннән берсе булганлыгы күренә. Ул, Белобородов «корпусының» бер командиры буларак, үзенең вәкилләрен восстание күтәрү өчен районның иң ерак почмакларына җибәрә. Крестьяннар сугышының беренче чорында Бәхтияр Югары Серги заводыннан Тура заводына, Тура заводларыннан Кунгур һәм Красноуфимск шәһәрләренә кадәр булган гаять зур территориядә хәрәкәт итә. Аның восстание барышы турында аңлаткан, крестьяннарны көрәшкә чакырып язган хатларын авыл җыелышларында укыганнар һәм аннары отрядларга тупланып җыелу пунктларына юнәлгәннәр.

---

[1] Н. Ф. Демидова. Ведомость об участии нерусского населения Башкирии в крестьянской войне 1773—1775 гг. Материалы по истории СССР, М., 1957, т. V, стр. 573—602.

[2] Грифтар улса — усал кешегә бәйле булса.

[3] БАҮДА (Борынгы актлар үзәк дәүләт архивы), 6-р. 416 эш, 2 кис. 106 бит.

[4] БАҮДА, 6-р. 416 эш, 2 кис. 144 бит.

Канкаев житәкчелегендәге крестьяннар отряды Красноуфимск шәһәрен алуда, аның өчен сугышларда актив катнаша.

1774 елның февраль — март айларында ул Үзәк Уралда, Кунгур өязендә хәрәкәт итеп, бик күп крестьяннарны восстаниегә күтәрә, Пугачев армиясен кеше көчләре белән тәэмин итүдә зур роль уйный. Март аенда пугачевчыларның төп көчләре Оренбург һәм Уфа янында җиңелгәннән соң да ул Кунгур өязендә крестьяннарны мобилизацияләү, алар арасында восстание лозунгларын пропагандалау белән шөгыльләнә.

Кеше көчләре туплау белән бергә, Канкаев восстаниечеләрне коралландыру, артиллерия өчен ядрәләр табу, дары ясау һәм корал житештерү эшенә дә зур игътибар иткән. Белобородовның күрсәтүе буенча, ул Кунгур өязендә дары ясау эшен юлга салырга тырыша, төрле волостьларга кешеләр җибәреп күкерт ятмалары эзләтә. Ләкин жирле башкорт старшиналары моңа комачаулык итәләр. Дары һәм корал ясау татарлар өчен үлем җәзасы белән куркытылып тыелган була. Шуңа карамастан, татарларның ул вакытта корал ясый белүләре һәм аңа омтылулары аларның промышленность үсешендә артта калмаганлыкларын күрсәтә. Алар арасында корал ясаучы тимерчеләр, хәтта мылтык, пистолет белән яшертен сату итүчеләр дә булган. Канкаев үз отрядында туплар булдыра, «хужаларның байлыкларын, имениеләрен» кулга төшерә һәм восстаниечеләр арасында тигез итеп бүлә, шул ук вакытта нык дисциплина булдырырга тырыша, башбаштаклыкка һәм сүлпәнлеккә, таркаулыкка каршы чаралар күрә.

1774 елның апрель — май айларында ул Татарстаннан ерак түгел жирләрдә — Буй елгасы районында хәрәкәт итүче крестьяннар отряды житәкчесе була. Май башында ул инде полковник, ә аның ярдәмчесе Абдулла Мустаев полковой старшина исеме ала. Канкаевка күп кешеләр олылап рапортлар, хатлар язалар, үзләренең хезмәтләрен тәкъдим итәләр. Июнь аенда, Пугачевның Казанга таба походы башланыр алдыннан, Канкаев, беренче булып, үз отряды белән Казан өязенә юнәлә.

Ул июнь аенда Кама буйлап Казан провинциясе татарлары арасына, Алабуга һәм Мамадыш тирәләренә килеп чыга. Мондагы крестьяннар 1773 елның ноябрендә үк инде восстаниегә күтәрелгән булалар. Ләкин аларны хөкүмәт гаскәрләре тар-мар итеп, баш күтәргән авылларны яндырып-туздырып китәләр. Б. Канкаев килү белән, бөтен Кама алды яңадан восстаниегә күтәрелә. Рус, татар крестьяннары аның отрядына кушылалар һәм ул инде өлкән полковник исемен йөртә башлый. Хәзерге Татарстан территориясендә ул Пугачевның Хәрби коллегиясе белән язма бәйләнеш булдыра, рапортларын «почта аша» шунда җибәрә. Шундый рапортларның берсендә татар хезмәт иясе массаларының Пугачевка һәм аның башлаган эшенә мөнәсәбәтләрен күрсәтеп ул болай яза: «Казан өязендә һәртөрле чиннардан булган кешеләр яше-карты шатланып государ хезмәтенә әзер торалар, безләрне икмәк һәм тоз белән берничә чакрым каршы чыгып алалар, император хәзрәтләренә исәнлек һәм күп еллар телиләр».

Мамадыш өязенә килү белән үк өлкән полковник Кама һәм Вятка аша кичү урыннарында контроль урнаштыра. Менә Б. Канкаевның бер приказы: «Полковник Бәхтияр Канкай углындан бирелде приказ. Син керәшен Гирачим Сабай углына. Чистай кичүенә һәм кичү алларына, янә үзләренә әввәл Көчек авылына, янә Тәберде Чаллысына, янә Букәш авылына, янә Чураш авылына, янә Казаклар авылына, янә Сатлыган авылына, янә Мокшы авылына, янә Чаллы башына һәм һәр вакытта даимчелек илән унбиш кеше тотмак үзәренә. Кичүдә ошбу эш тапшырылды. Көчек авылының Мәнди Туктамыш углына һәр вакытта яхшыдин һәм ямандин хәбәр булырга, югарыда язылган Гирачимга рапортовайть итмәгә. Бу мәзкүр югарыдагы язылган сигез авыл җәмәгатьләренә поход сорап һич кем рәнҗетмәгәй. Ошбу мәзкүр кичү хакында боердык. Атланганнары булса (ягъни атка атланып восстаниече отрядка кушылганнары булса — С. А.), һәм кайтарырга һәм көн-элгәре анларны кеше сорап рәнҗетмәскә». Бу сигез авыл исемлегенә полковник озакламый тагын ике авылны — Әрнәш баш һәм Түбән Әрнәшне кертә. Шулай итеп, күрсәтелгән авыл кешеләре Чистай кичүен, башка авыл кешеләре бүтән кичүләрне күзәтергә, дошманнардан сакларга, ә зуррак хөкүмәт гаскәрләре килү беленсә, тиз хәбәр итәргә тиеш булалар. Үзенең якын кешеләрен Б. Канкаев тирә-як авылларга отрядлар оештыру өчен җибәрә. Абдулла Мустаев, Кама арьягына чыгып, крестьяннарны восстаниегә күтәрә һәм Пугачев Казанга юнәлгән вакытта әзәрлекләп килүче хөкүмәт гаскәрләренә каршы сугыш алып бара, Бәхтияр тарафыннан төрле якка җибәрелгән һәм үзләренә отряд оештырып хәрәкәт иткән Канкаев керәштәшлә-

реннән Надыр Тохтаралин, Гаврила Лихачев, Рахманкул Дүслиев, Ульян Ивановларны күрсәтергә мөмкин. Надыр Тохтаралин, Васильев белән бергә, 600 кешелек отряд белән Шихазда, Казиле, Аркатово, Страховка авылларында алпавыт утарларын тар-мар итеп йөри. Подполковник Рахманкул Дүслиев (Катмыш авылы крестьяны) крепостной крестьяннарны азат итәргә, отрядка кушылучыларны булган кораллары белән алып килергә Воронцовларның Шумбут аракы заводына җибәрелә. Рахманкул Дүслиев, заводтан 3 чуен, 1 лафетсыз бакыр пушка алып, күп кешеләр белән Б. Канкаевка килеп кушыла. Ә өлкән полковник исә бу кешеләрнең күбесен, Пугачевка ярдәмгә дип, Казан янына җибәрә. Бу вакытта ул үзе Әрнәш, Катмыш, Үсәли һ. б. авылларда йөри. Бәхтияр Канкаев карамагына кергән кайбер крестьян отрядларының исемлекләре сакланган. Бу исемлекләрдән күренгәнчә, төрле авыллар төрлечә санда кешеләрен халык армиясенә биргәннәр. Мәсәлән, Пакшино авылы 2 кеше, Кече Берсут — 6, Урманчи — 5, Теплое болото — 5, Иванаево — 6, Мишәбаш — 5, Шумбут — 7, Полянки — 16, Иске Казаклар — 5, Шумбут аракы заводы — 15, Катмыш — 11, Шөн — 6, Югары Берсут — 6, Кәчек — 10, Тәберде Чаллы — 8, Чаллы башы — 3, Мишә — 2, Кукчишмә — 2, Ямаш — 11, Кучкә — 11, Кирмәнбаш — 7, Котлы-Бүкәш — 8, Мордовское — 2, Таулар — 2, Казаклар — 4, Чураш — 3, Сатлыган — 3, Уразбахты — 6, Берсут Мишәбашы — 9, Чаллы — 1, Кирлы — 21, Урта Шөн — 10, Кече Шөн — 11, Югары Шөн — 9, Югары Яки — 5, Түбән Яки — 8 һ. б. авыллардан төрле сандагы кешеләр бер отрядка оешканнар [1]. Алар (исемнәре һәм кем уллары икәнлеге күрсәтеп язылган) үз теләкләре белән сыйнфый дошманнарга каршы күтәрелгәннәр. Моны ачыклый торган язмалар да сакланган: «Субай сотнясыннан Колчуги авылы крестьяны Мәшли Сулешев үз теләге белән хезмәткә килде», «Гомәр сотнясыннан Кече Миретәк авылының Мортаза Шәрипов дигән кешесе хезмәткә үзе теләп килде», «Казан өязенең Катмыш авылы крестьяны Миңлебай Есенеев, Таулар иленнән Ишмөхәммәт Бохараев үз теләге белән казак хезмәтенә килделәр» һ. б.

Документларны тикшергән вакытта тагын шул нәрсә ачыклана: рус, татар һ. б. милләт крестьяннары бергәләп, бер теләктә булып көрәш алып барганнар. Б. Канкаев Пугачевка атап язган бер хатында төрле милләт крестьяннарыннан торган зур гаскәр җыюы турында әйтә. Пугачев исә указ белән аңа, берләштерелгән армия җыеп, дошманнарга каршы торырга әмер бирә. Бу хәл хәзерге Татарстан территориясендәге төрле милләт крестьяннары арасында булган дусларча мөнәсәбәтнең восстание вакытында бергәләп көрәшкә китергәнлеген, дуслык бәйләнешләренең нык барууын ачыклыйлар.

Бәхтияр Канкаевның поход канцеляриясе даими рәвештә һәм төгәл эшләгән. Ул үзе дә һәм аның якын көрәштәшләреннән подполковник Абдулла Мустаев, Рахманкул Дүслиев грамоталы булган, ә секретаре Әбүбәкер Телячев татарча да, русча да укыйяза белгән. Канкаев канцеляриясеннән чыккан төрле документлар Пугачевның башка полководецларыныкына караганда күбрәк сакланып калган. Аларны восстаниегә күтәрелгән крестьяннарның үз куллары белән язулары бик әһәмиятле.

Кама алды крестьяннары, канкаевчылар хәрәкәте нәтиҗәсендә восстаниегә күтәрелеп, Пугачевны зур түземсезлек белән көтәләр һәм һәркайда аны зур хөрмәт белән каршы алалар. Пугачев Мамадышка килеп җиткәч, 1774 елның 3 июлендә, Канкаев та аның янына бара. Моңа кадәр Пугачев һәм аның якын көрәштәшләре, Хәрби коллегия белән язма элемтәдә торса да, ул әле крестьяннар патшасы «Петр Федоровичны» күрмәгән була. Мамадышта алар беренче тапкыр очрашалар. Бу очрашу турында соңыннан патша гаскәрләренә әсир төшкән Әбүбәкер Телячев менә нәрсәләр сөйли: «Без Пугачев янына кергәч, җиргә тезләндек һәм аны патшабыз дип атадык. Ул безне үзе янында кунарга калдырды. Иртәгесен безнең белән килгән отрядны үз армиясенә кушты. Бәхтиярга инструкция биреп, төрле авыллардан «казаклыкка» кеше җыярга һәм тизлек белән аларны Казан астына җибәрергә дип, алты кешесе белән кире озатты...» [2]. Бу инструкциядә Пугачевның татар крестьяннарын һәртөрле салымнардан, рекрут бирүдән коткаруы, җир бирүе турында язылган була. Шул ук вакытта анда бу азатлыкка Мәскәүне алып, ул патша булып утыргач кына ирешергә мөмкинлеге турын-

[1] БАУДА, 6-р. 416 эш, 2 кис. 57—60 битләр.
[2] БАУДА, 6-р. 467 эш, 6 кис. 3 өлеш, 243 бит.

да, шуның өчен барлык халык аның кешеләрен, манифестларын тыңларга тиешлеге, азатлык өчен көрәшергә, тыңламаган, каршы килгән кешеләрне каты җәзага тартырга кирәклеге турында әйтелгән була. Б. Канкаев мондый күрсәтмәләрне ахрына кадәр тормышка ашыру өчен бөтен көчен куеп эшкә керешә. Канкаев Хәрби коллегиягә язган бер рапортында: «Кичүләргә 100—150 шәр кешелек отрядлар җибәреп күзәтәбез, күзәтчеләр барысы турында хәбәр итеп торалар», — дип яза. Дөрестән дә, кичүләр буенча куелган крестьяннар Михельсон гаскәрләренең Вятканы Шөн кичүе аша чыгуын, Мельгунов отрядының Сокольки янында Кама аша кичүен һәм Вятка буйлап югары китүен хәбәр итәләр.

Пугачевның зур армиясе Казанны алган һәм шәһәр өчен сугыш алып барган көннәрдә аның арьергард отрядлары полковник Б. Канкаев җитәкчелегендә Кама һәм Вяткадан Лаеш өязендәге Меретяк, Мәтескә, Сауш авылларына, Мамадыш өязенең Караширмә, Иөри һ. б. авылларына кадәр таралган була. Күбесенчә Лаеш, Мамадыш, Арча өязе крестьяннарыннан торган бу отрядлар үз авылларын хөкүмәт тарафыннан җибәрелгән карательләрдән саклыйлар, урыннарда үз властьларын урнаштыралар, Пугачев армиясенә кешеләр, азык-төлек һәм фураж җибәрәләр. Канкаев шул көннәрдә Хәрби коллегиягә язган бер рапортында: «2 мең кешелек армиям, 5 пушкам бар, ләкин дары һәм кургаш юк. Дошманнар белән һәр көн диярлек сугышабыз»[1], — дип яза. Б. Канкаевның үзенә Омар волостеның крестьяннары Иске Чишмә крепосте воеводасының алар өстенә килүе, Г. Лихачевның Балык Бистәсендә булган дошманнарга каршы баруы һәм анда сугышып 11 кешене пленга алуы турында хәбәр итәләр. Өлкән полковник тарафыннан Кама аръягына җибәрелгән Абдулла Мустаев Талкыш, Исләй, Сарсаз һ. б. авыл крестьяннарыннан оештырылган 700 кешелек отряд белән хөкүмәт гаскәренә каршы сугыша, ләкин регуляр армиягә каршы тора алмый һәм җиде пушкасын югалтып, чигенергә, калган кешеләре белән яңадан Бәхтияр Канкаевка кушылырга мәҗбүр була. Восстаниечеләр, Балык Бистәсенең баш күтәргән крестьяннары белән бергәләп, шул авыл янында майор Муфель командасын Кама аша чыгармас өчен сугышалар һәм Муфельның Михельсонга ярдәмен тоткарлыйлар. Канкаев җитәкчелегендәге отрядларның шундый сугышчан хәрәкәтләре 1774 елның июль ахырына кадәр дәвам итә. Билгеле булганча, Пугачев Казанны 12 июльдә ала, 12 июльдән 15 июльгә кадәр Казан янына килеп җиткән Михельсон белән көчле сугышлар алып бара һәм, армиясе тар-мар ителгәч, 17 июльдә Иделнең уң як ярына чыгып китә. Хөкүмәт гаскәрләре Пугачевны куганда йончыган атларын яңаларга алыштыра алмыйлар, чөнки атлар, Б. Канкаев әмере буенча, халык армиясенә алынган була. Казанга якынлашучы гаскәрләр восстаниече отрядлар хәрәкәт иткән территорияне зур югалтулар белән ерып чыгарга, соңга калырга һәм хәлсезләнергә мәҗбүр булалар.

Пугачев Иделнең уң ярына киткәч, хәзерге Татарстан территориясендә крестьяннар сугышы сүрелә, көчсезләнә башлый. Казан өчен сугышлардан соң, төрле якка таралган крестьяннарны эзәрлекләү, тотып алу һәм киң күләмдә җәзалаулар үткәрелә, төрле якка җәза отрядлары җибәрелә. Шундый отрядларның берсе Бәхтияр Канкаев группасын эзәрлекли. Сугышчан отрядларның бу вакытта иң көчлесе аның отряды була. Мамадыш өязе Иске Иөри авылы янында 1774 елның июль ахырында ике арада көчле сугыш була. Бу сугышта ике як та җиңүгә ирешә алмый. Казан тирәсендә зур армиянең җиңелүен ишетеп белгән Канкаев, көчләрнең хөкүмәт гаскәрләре файдасына үзгәрүен аңлап, чигенә башлый. Аның әле кешеләре дә, пушкалары да була. Чигенә барып ул отряды белән Төньяк урманнарга яшеренү өчен Вятка аша чыгарга ният итә. 400 кешедән торган бу отряд Кләүш авылы янында көчле хөкүмәт гаскәренә очрый һәм тар-мар ителә, восстаниечеләрнең күбесе, шулар эчендә Канкаевның секретаре (ул вакытта писарь дип йөрткәннәр) Әбүбәкер Теләчев та пленга эләгә[2]. Ә Бәхтияр Канкаев бернечә иптәше һәм бер бакыр пушкасы белән качып котыла. Ул, мөгаен, Вятканы кичеп, халык арасында куркынычсызрак урын таба алгандыр, я булмаса, тагын да ераграк китеп, Урта Азиягә юнәлгәндер. (Урта Азиягә качып китүче кайбер пугачевчы

---

[1] Пугачевщина, т. 1, М.-л., 1926, стр. 105.

[2] Ә. Теләчевны яшерен комиссиянең «Халыкка язган кулын кисәргә, аннары башын кисеп асып куярга, гәүдәсен кичке сәгать 4 кә кадәр дар агачыннан алмаска», дигән карары нигезендә җәзалыйлар. (БАУДА, 6-р. 467 эш, 6 кис. 3 өлеш, 246 бит.)

татарларны Ш. Мәрҗани үзенең «Мостафад әл-әхбар» китабында телгә ала.) Кем белә, бәлки нинди дә булса бер сугышта үтерелгәндер. Ләкин шунысы билгеле: хөкүмәт гаскәрләре һәм органнары, никадәр генә эзләмәсеннәр, аны таба алмыйлар. Императрица Екатерина II, крестьяннар сугышыннан курыккан «әби патша», манифест чыгарып, восстаниегә кушылучылар үзләре килеп бирелсәләр, аларның «җинаятьләре гафу ителәчәк», дип белдерә. Ләкин Казанда пугачевчылар эшен тикшерүче яшерен комиссия председателе П. Потемкин Канкаевны бу хокуктан мәхрүм итә. Аны эзләп табып китерергә кешеләр җибәрә, тапкан кешегә акчалата бүләк билгели. Крестьяннар үз батырларын хөкүмәттән яшерәләр, аның турында хәбәр итмиләр.

Халык бәхете өчен көрәшүчеләрнең күренекле вәкиле Бахтияр Канкаевның тарихи әһәмияте халыкның аны яратып үз арасында саклавында гына түгел, ә бәлки соңыннан да аны легендар герой итеп үз күңелендә йөртүендә.

* * *

1773—1775 елларда барган Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар сугышы җиңелә. Ләкин халыкның алпавыт һәм патша чиновникларына, эксплуатациягә каршы көрәше гасырлар буена бара. Крестьяннар ирек һәм җир өчен революцион көрәш юлын Бөек Октябрь социалистик революциясе җиңеп чыкканчыга кадәр дәвам иттерделәр.

Октябрь революциясенең данлыклы 50 еллыгында без пролетариат җитәкчелегендә барган Октябрь алды көрәшен генә түгел, ә бәлки аңа кадәр булган көрәш юлын да күз алдына китерәбез, үткән буын көрәшчеләренең дә бөек җиңүне яулап алуда керткән өлешләрен онытмыйбыз.

● ● ●

# МӘРҖАНИ ТУРЫНДА БЕРНИЧӘ СҮЗ

Шушы елның 16 январенда заманының күренекле тарихчысы, педагог һәм җәмәгать эшлеклесе Шиһабетдин Баһаветдин улы Мәрҗанинең туууна 150 ел тулды.

Беренче карауга, галимнең тормыш юлы әллә ни катлаулы да түгел сыман: башлангыч белемне авылда үз атасыннан ала, аннары, башка рухани балалары кебек үк, «Бохараи-шәриф»тә ун елга якын гомер уздыра. Казанга кайткач, руханилык дәрәҗәсен кабул итә һәм шунда 1889 елның маенда вафат була.

Әйе, тыштан караганда, шулай шома гына узган, төссез генә бер гомер сыман. Ләкин мәсьәләгә якынрак килеп, фактларның асылына керә башласаң, бөтенләй икенче картина ачыла. Безнең алда — феодализм туңлыкларын җимерә-җимерә туып килүче капиталистик мөнәсәбәтләрнең, милли һәм иҗтимагый аңы формалаша башлаган яшь татар буржуазиясенең эшлекле вәкиле, бунтарь идеологы, шул ук вакытта гаҗәеп каршылыклы фикер иясе. Бер яктан, гасырлар буена яшәп килгән рухи богауларны өзеп, кеше аңына хөрлек, азатлык таләп иткән акыл иясе, гуманист. Икенче яктан, ислам динен нечкәртеп, аны сыгылмалырак итүдә шактый хезмәтләр күрсәткән философ-идеалист. Бер яктан, фактлар нигезендә фәнни тарих язучы галим, ә икенче яктан исә никах укып, җеназалар чыгучы мулла...

Әйе, Мәрҗани эшчәнлеге катлаулы да, каршылыклы да. Аның иҗатында прогрессив идеяләр күп, чикләнгәнлек тә җитәрлек.

Тарихи шәхесләрнең урынын ачыклаганда, алар эшчәнлегенең гел тискәре моментларын күпертү нинди күңелсез нәтиҗәләргә китерсә, аларның бары уңай яклары турында гына сөйләү дә безне хакыйкатьтән ераклаштырыр иде. Мәрҗани мирасы моңар хәтле, кызганычка каршы, шул пландарак тикшерелеп килде. Мәсәлән, 1915 елда галимнең туууна 100 ел тулу мөнәсәбәте белән чыгарылган, фактларга бай «Мәрҗани мәҗмугасы» исемле китапта, галимнең эшчәнлеге гел ислам дине күзлегеннән генә каралып, аның иҗатының дөньяви, социаль-иҗтимагый әһәмияте танылмаслык дәрәҗәдә бозылган иде. Шуның тәэсиредер, күрәсең, соңрак вакытларда кайберәүләр баш турында сөйлисе урында, баш өстендәге чалмага күбрәк игътибар иттеләр, һәм, нәтиҗәдә, катлаулы иҗат объектив бәһасын ала алмыйча ятты.

Шуннан файдаланып булса кирәк, чит илләрдәге кайберәүләр, Мәрҗани авторитеты белән уйнап, татарлар арасындагы иҗтимагый фикер тарихын бозып күрсәтүче фальсификацион әйберләр чыгара башладылар. Бер генә мисал китерик. Үзенә «Таймас» дип псевдоним алган ак эмигрант Абдулла Баттал Көнбатыш Германиядә бастырган соңгы мәкаләләренең берсендә Мәрҗани канаты астына Зәки Вәлиди кебек авантюристларны да кертеп маташа [1]. Максат бик ачык: янәсе, Вәлиди дә иҗтимагый фикер уяну дәверенең, мәгърифәт-мәгарифчелек идеяләренең җимеше, Ш. Мәрҗани «тудырган тарих мәктәбе»нең бер кешесе... Чынлыкта исә алар ике чорның, ике платформаның вәкилләре, кырык мәртәбә кайнатсаң да «шулпалары» бергә кушылмый торган ике автор, ике идеологик юнәлеш кешесе.

Биредә бу мәсьәләгә очраклы рәвештә туктадмыйбыз. Чөнки Мәрҗани мирасы, ул яшәгән катлаулы дәвер кебек үк, төрле ил, төрле идеология галимнәренең игътибар үзәгендә торган мөһим мәсьәләләрнең берсе. Һәм аның тарихтагы урынын дөрес билгеләү өчен буржуаз фальсификаторлар белән совет тарихчылары арасында кискен бәрелешләр булачак. Бу мәсьәләдә буржуаз галимнәргә иркен мәйдан калдырып китәргә безнең бернинди хакыбыз юк [2].

---

[1] „Handbuch der Orientalistik, V. Band, Altaistik, 1. Abschnitt, Turkologie", немец телендә, Лейден-Кёльн, 1963, 431 бит.

[2] Совет галимнәре тарафыннан киңрәк тикшерелгән К. Насыйри эшчәнлеге турында чит ил тарихчыларының нигездә безнең галимнәр фикере белән исәпләшергә мәҗбүр булулары, әлбәттә, күп нәрсә турында сөйли. Мәсәлән, француз тарихчысы Ш. Келькежейның К. Насыйри иҗатына багышланган мәкаләсе нигездә совет галимнәре хезмәтләренә таянып язылган. Кара: „Cahiers du Monde Russe et sovietique", 1—2, v. IV, француз телендә, Париж, 1963, 117—142 бб.

Инде Мәрҗани эшчәнлегенең төп әһәмиятенә килсәк, ул — иң элек, дөньявилык һәм гыйльмилекне беренче планга куйган күренекле галим. Хөр фикерләре өчен аны карагруһ татар руханилары эзәрлекләде, прогрессив хезмәтләре өчен надан татар җәмәгатьчелеге «зиндикъ», «мөртәт», «чукынчык» дип атады.

Чыннан да, татар укымышлыларыннан «шәрех» чәйнәүләрне ташлап, мәктәп-мәдрәсә программаларына реформа кертү, дөньяви фәннәр укыту идеясен башлап кем күтәреп чыкты? Һәм «Бохараи-шәриф»нең битлеген кем ертты?

— Мәрҗани.

Кайбер адәмнәр «рус теле — хәрам», «русча уку — диннән язу» дип лаф орып, халыкны котыртып яткан бер заманда, «безнең өчен рус телен белү — вәҗиб (һичшиксез мөһим)» дигән кыю фикерне кем беренче булып әйтте?

— Мәрҗани.

Фанатик Казан татарларының тискәрелеген җиңеп ачылган Русско-татарская школада авторитетлы татар укымышлыларыннан беренче укытучы булып эшләүче кем иде?

— Мәрҗани.

Бөтен мөселман дөньясы: «Иҗтиһад монкарыйз», янәсе, актив фикер йөртү дәвере узган инде, шулай булгач, социаль-рухи изүләргә түзәргә, фикерсез, юаш мөэмин булып яшәргә кирәк дип, бер тавыштан гөр килеп, туктаусыз тукынып ятканда, «юк, иҗтиһад дәвере үлмәде, үлмәячәк, кеше фикердә дә, гамәлдә дә хөр булырга тиеш», — дип, бөтен шәрыкта хөкем сөргән догмага кем каршы чыкты?

— Мәрҗани.

Җыр-музыка — хәрам, алар шайтан эше дип, халык талантларын буган, җыр-музыка сәнгатен мәйханә белән фәхешханәләргә куып керткән гомуми фанатизмга каршы Россия мөселманнарыннан беренче буларак кем тавыш күтәрде?

— Мәрҗани.

Ниһаять, тарихның караңгы дәверләрендә, һәркемгә «мөселманлык»ны тәкъдим итеп, мөстәкыйль халык булуыңны онытырга тырышкан заманда конкрет Болгар-Казан тарихын кем язды? Үзеңнең гарәп һәм таҗик та, нугаи һәм үзбәк тә булмыйча, «татар» дигән аерым халык икәнлегенне кем исбат итте? «Тәварихы Болгария» кебек сафсаталарның мулла-монтагай мистификациясе булуын фаш итеп, тәнкыйть белән сыналган фактларга нигезләп, беренче дөньяви тарихыңны кем язды?

— Мәрҗани.

Әйтергә кирәк, Мәрҗани эшчәнлегенең гыйльми әһәмиятен иң элек рус ориенталистлары бәяләделәр. Аның беренче тарихи хезмәте турында югары фикерне 1877 елда ук күренекле тюрколог В. В. Радлов әйтте. «Мостафад әл-әхбар фи әхвале Казан вә Болгар» исемле капиталь әсәре турында исә Н. Ф. Катанов болай язган иде: «Этнографик һәм тарихи фактларның байлыгы җәһәтеннән, бу хезмәт бер рус теленә генә түгел, бәлки башка Европа телләренә дә тәрҗемә ителергә лаек».

Шулай, Мәрҗани иҗатының төп әһәмияте — аның дөньяви, гыйльми хезмәтләрендә. Тагын бер характерлы деталь. Әгәр Мәрҗанинның теологик темаларга багышлангап әсәрләре күләм ягыннан 15—20 процентган артмаса, дөньяви, бигрәк тә тарихи, темаларга багышланган хезмәтләре 75—80 процентны тәшкил итә. Нәтиҗә үзеннән үзе чыга. Вафатыннан ике көн элек, үлем түшәгендә яткан килеш язган соңгы әйбере «Мостафад әл-әхбәр»га өстәмә булуын һәм соңгы васыятьләренең тарихи хезмәтләре турында әйтелүен игътибарга алсак, картина тагы да ачыклана төшә.

Ләкин галим мирасының шушы уңай һәм прогрессив якларын өйрәнгәндә дә, мәсьәләгә гыйльми тәнкыйть, нисбилек принциплары белән якын килергә кирәк. Киресенчә булганда, реаль шәхес урынына идеаль әһел менеп басачак. Мәсәлән, Бохараишәрифнең тетмәсен теткән, уку-укыту эшләренә радикаль реформалар мәсьәләсен күтәреп чыккан Мәрҗани үз мәдрәсәсен әллә ни яңарта алмаган.

Рус телен уку вәҗиб дип, үзе шул карашны актив пропагандалау белән бергә, ул фамилиягә «ов» кушымчасын өстәүдән һәм тарихи даталарны милади ел исәбе белән язудан качкан.

Кеше фикере хөр булырга тиеш дип, шул мәсьәләдә барлык иске авторитетларны тибеп җимерсә дә, фикер азатлыгы принципларын Мәрҗани коръәнне «дөрес» аңлауга кайтарып калдырудан уза алмаган.

Музыканың хәрам түгеллеген дә ул аять-хәдисләр һәм «нәкыль»ләр (борынгылар сүзе) нигезендә исбат итәргә тырышкан.

Үзенең яңа рухтагы, реалистик тарихи әсәрләрен иске формага төреп биргән; гомуми нәтиҗәләр чыгара башлаганда исә, үткен күзле, айнык акыллы тәнкыйтьче Мәрҗани да тәмам аптырап калган һ. б. ...

Әмма, болардан чыгып, Мәрҗани эшчәнлегенә тәкәбберлек белән, бүгенге көн бизмәннәре белән якын килү, һәм аның алдына реаль булмаган таләпләр куеп, аны хаксызга гаепләү дә дөрес булмас иде. Чөнки, В. И. Ленин өйрәткәнчә: «тарихи хезмәтләр турында тарихи эшлеклеләрнең хәзерге таләпләр белән чагыштырганда нәрсәне бирмәүләренә карап түгел, бәлки аларның үз элгәрләре белән чагыштырганда нинди яңа нәрсә бирүләренә карап хөкем ителә» (В. И. Ленин. Әсәрләр. Татар телендә. 11 нче том. 172 бит).

Бу принципны нигез итеп алсак, Мәрҗани иҗатында без күп яңалыклар табарбыз.

Мәрҗани мирасына бәя биргәндә, аның Париж яисә Петербургта түгел, бәлки Бохарада укып, Казандагы Иске бистәдә яшәгән булуын онытмаска кирәк. Һәм ул яшәгән дәвернең феодализм җимерелү чоры булуын да истән чыгармыйк. Менә шунда гына без Мәрҗани эшчәнлегендәге уңай якларны да, тискәре моментларны да дөрес аңлаячакбыз. Аның чикләнгәнлекләре иске татар тормышыннан, «шәүкәтле» Бохара мәдрәсәләреннән калган реликт булса, аның радикаль чыгышлары, прогрессив фикерләре яңару юлына баскан Россия җәмгыятенең революцион идеяләре тәэсире иде. Чөнки татар буржуазиясенең язмышы — гомуми Россия күләмендә җиңеп килә торган капиталистик мөнәсәбәтләрнең бер өлеше иде. Димәк, Мәрҗани аңындагы чикләнгәнлекләр буржуазия сыйныфының табигате белән дә бәйләнгән иде.

Кайберәүләрне Мәрҗанинең һаман мулла булып кала бирүе гаҗәпләндерә шикелле. Ләкин мондый шелтәләр бөтенләй урынсыз: академиясе, университет-институты түгел, хәтта дөньяви бер мәктәбе дә булмаган татар халкының укымышлылары мәчет-мәдрәсәдән башка кая бара алсын? Әмма Хөсәен Фәезхановның татарлар өчен дөньяви гимназия ачу һәм Казан университетында татар бүлеге булдыру турында хыялланып, утопик проектлар язуын һәм ул проектка Мәрҗанинең югары бәя бирүен искә төшерсәк, мәчет-мәдрәсәләргә мәҗбүри куып кертелгән татар укымышлыларының фаҗигасен тагы да ачыграк аңлый алырбыз.

Шул ук вакытта Петербург университетында укыткан гади авыл егете Х. Фәезханов Мәрҗани шәкерте иде. Шул шәкерте аша Мәрҗани прогрессив рус ориенталистләры белән якын мөнәсәбәттә тора. Фәезханов үзе исә В. Д. Стасов кебек демократлар белән таныш-утырдаш, Чокан Вәлиханов, Ибраһим Алтынсариннар шикелле атаклы мәгърифәтчеләр белән дус-фикердәш була. Шуларның барысын да игътибарга алсак[1], Мәрҗани һәм аның даирәсе турындагы берьяклы карашларның бик субъектив булуын да чамаларбыз.

Кыскасы, Мәрҗани эшчәнлегенең төп әһәмияте аның дөньяви, гыйльми якларында. Культурабыз тарихында да Мәрҗани, беренче чиратта, талантлы тарихчы, мәгърифәтче педагог һәм гуманистик карашлы җәмәгать эшлеклесе буларак үз урынын били. Прогрессив татар җәмәгатьчелеге дә аны менә шул якларыннан чыгып тәкъдир итте. Бөтен иҗаты мәгърифәтчелек идеяләре белән сугарылган мәшһүр Акмулла аны «мәгърифәт кояшы» дип мактап җырлады. Бөек Тукай да Мәрҗанинең тарихи урынын дөрес бәяләде:

**Мәгарифкә әүвәл башлап адым салган,**
**Милләт өчен бәһа җитмәс кыйбат хәзрәт.**
**Ул итсә дә хәдис, аятьне күп нәкыль[2],**
**Булып бетми аның гаклы нәкыльгә кол;**
**Инсан дигән шәрәфле бер мәхлукта ул**
**Бар дип белә хаким гакыл вә хөр гакыл.**

Киң колачлы фикер иясе Г. Ибраһимов аны «бөек остаз» дип атады. «Аның бөтен әсәрләре фикердә хөррият белән, киләчәккә якты карау белән, адәм гаклына ихтирам белән сугарылган булуын» ассызымлап әйтте. Һәм Мәрҗани иҗатының әһәмиятен аңлар өчен, ул яшәгән караңгы дәверне истән чыгармаска кирәклеген махсус күрсәтте («Аң» журналы. 1915 ел. 1—2 саннар). Әйе, Мәрҗани эшчәнлегенә бәя биргәндә, тун тормышның барлык ачысын җилкәләрендә татыган Акмулла, Тукай, Ибраһимов кебек көрәшчеләрнең фикерләрен дә игътибарга алып хөкем чыгарырга тиешбез.

Галимнең мирасына гыйльми тәнкыйть белән килеп, аңа әтрафлы бәя бирү, әлбәттә, киләчәктәге бурычларның берсе. Бу кечкенә мәкаләдә исә без төп мәсьәләләрнең берничәсенә генә кагылдык. Мәрҗанинең тормыш юлы турында тәфсыйлләп сөйләмәгән кебек, ул иҗат иткән тарихи әсәрләрне санап, тасвирлап чыгуны да бурыч итеп куймадык. Мәрҗанидан калган кульязма мирас турында сөйли башласаң да, яңа мәкалә килеп чыгар иде. Аңар хәтле татар иҗтимагый фикере үсешендә туган беренче яралгыларны (Курсави мирасын) тикшереп бәяләү, ул орлыкларның Мәрҗани иҗатында ничек үстерелүен күзәтү, ниһаять, яңа җирлектә җитлеккән Фәезханов һәм Насыйриларны киң планда яктырту, һичшиксез, зур монографияләр таләп итәр иде. Болар, әлбәттә, чираттагы бурычлар.

Түбәндә галимнең ике хатының текстын хәзерге әдәби телгә күчереп бирәбез[3]. Бу хатлардан Мәрҗанинең һәм көчле, һәм көчсез сыйфатларын күрергә була. Бер яктан, бөтен искелек символы булган Бохарага нәфрәт тоткан айнык акыллы фикер иясе. Икенче яктан, адым саен аллага сыенып мескенләнгән «хак мөселман». Өченче яктан, безнең алда төпченә белүче чын тарихчы, һәр фактны тәнкыйть күзлегеннән кичерүче таләпчән галим.

М. ГОСМАНОВ.

[1] Фәезхановның соңгы вакытларда без тапкан хатлары галимнең биографиясенә тагын яңа мәгълүматлар өсти. Ул хатлар киләчәктә махсус басылыр.

[2] Нәкыль — борынгылар сүзенә таяну; борынгылар сүзе.

[3] Р. Фәхретдиновның 1966 елда безнең тарафтан Уфада табылган архивында Мәрҗанинең тагы 10 хатының тексты саклана. Аларның эчтәлекләре турында сүз башка урында булыр.

### МӘРҖАНИ — КӘЛИМУЛЛАГА [1]

Кадерле дустым, алланың сөеклесе милла Кәлимуллага, барлык өй-эчегез, танышбелешләрегез белән бергә, сансыз-хисапсыз догаларыбыз күндерелә! Ислам йоласы буенча сәламнән соң, без фәкыйрьләрне барлык таяныч-якыннарыбыз белән элеккечә сау-сәламәт дип белерсез.

Сезнең тарафтан безгә күнделелгән нәзакәтле хатыгыз, бер тәнкә сәдакагыз белән бергә [2] тапшырылып, сезнең хакка хәер-догалар кылынды. Кабул итмәк алладандыр. Һай мескенем, милла Хөсәен мәрхүм вафат булган икән ләбаса! Ни кылмак кирәк, тәкъдиргә буйсынмыйча ни чарабыз бар? Аллаһе тәгалә чиксез рәхмәтләр кылып, урынын җәннәт эчендә итсен иде. Күп-күп хезмәтләр кылып, ниһаятьсез файдалар китергән иде. [Аның хезмәтләренә] мул әҗер һәм мактаулы алкыш белдерү белән бергә, изге бүләкләр бирүне бары бөек тәңрегә тапшырудан башка кулыбыздан ни килсен! «Ә кайгыбызны аллага белдерү белән чикләнәбез»[3].

Безгә бик зур хәсрәт булды. «Дөреслектә кадерле кешеләр кыска гомерле була»[3]. Гыйльми гамәл, үткен акыл, хәкимлек һәм диңлелек җәһәтләреннән аның тиңен хәзер кайдан табарга? Табылса да, бик сирәк кенә табылыр. Шулай ук гаҗәеп һәйбәт кеше дә иде ул. Гавәмнең юк-бар сүзләренә, шау-шуларына исе китми торган олы җанлы кеше иде. Аллаһе тәгалә әхирәтен җайлы итеп, бала-чагаларына хәерле тормышлар бүләк итсен. Бичаракайларым, бик хафа булганнардыр. Дөнья көтеп, көн күрерлек матди хәлләре бар микән? Аллаһе тәгалә үзенең рәхмәте белән иркен тормыш мөмкинлекләре бүләк кылсын, амин! Ул бичараларның хәлләреннән белгәнегез кадәре безгә хатыгызда тәфсыйллап язып җибәрүегез көтеләдер.

«Шәрхе гакаид»ны [4] [Хөсәеннең] үзенә бүләк кылган идек, ул безнең милек түгел. Ләкин лаексыз [кешеләр] кулына төшеп кадерсез булмаса икән. Тиешле бәһасен биреп үзең алсаң ничек булыр икән?

Йәнә аның һәртөрле җыентыклары һәм китаплары булса кирәк иде. Безгә кул [булырлык] китаплары булган хәлдә, әгәр сатарга ихтыяр кылсалар, без, бәлки, алыр идек. Хосусән, кешеләр тормышына, тарихлар һәм дөнья хәлләренә мөнәсәбәтле җыентыклары булса, безгә зарур иде.

Һәм тагын да аның мәдрәсә хакында язган бер каралама китабы бар иде [5], аны акка чыгарып бастыру ниятендә иде. Бичара, акка чыгарырга форсаты булмагандыр. Шул китап югалмаса икән; мин үзем аны акка чыгарып бастыру чарасына керешер идем. Һич булмаганда, нөсхәләре күбәйсен өчен, биш-алты нөсхә яздырыр идем. Бичараның тырышлыгы һәм иҗтиһады әрәм булмаса икән. Ул бик яхшы һәм бик файдалы нәрсә иде. Гавәм халык шау-шулар, ялалар [чыгарып], теләсәләр ни сөйләсеннәр. Наданлык, куралмаучанлык һәм көнчелек сәбәпле, юк нәрсәләр яла кылып хәбәр тараттылар. Ул могтәбәр түгел, чөнки көнчелектән туган әйберләр ят нәрсәләр түгел. Минем үз каршымда исә егерме ел Бохарада дәрес укып йөреп, монда кайтып [йәнә] егерме ел дәрес укыткан кешеләр шуны игътибар белән тикшерсәләр, ата-бабаларына да ирешмәгән гыйлемлекләр хасил итәрләр иде. Ни кылмак кирәк! Надан, көнче [кешеләр], дөреслеккә колак салмыйча, явыз ният белән ялган яла ягалар. Дөреслекне дошман саныйлар. «Ярдәм итүчеләрнең иң хәерлесе — алланың үзе генә»[6]. Озын сүзнең кыскасы: мөмкин булса, тизлек белән мәрхүмнән калган китапларның исемнәрен язып, тәфсыйллы исемлек ясап, мөмкин булса, баягы китапны һәм шуңа мөнәсәбәтле аерым кәгазьләрдә булган язмаларны да безгә җибәрерсез. Элегрәк [Хөсәеннең] үзе туплаган бер җыентыгы булырга тиеш иде. Йәнә татар телендә тәртип кылган нәхү һәм сарфы булса кирәк иде. Болгар һәм Казан хакында мәкаләләре булса кирәк иде.

Безнең хатыбызның эчтәлеген хат белән җәмәгатенә аңлатырсыз. Вәссәлам.

Нәҗип мәхдүм сәламәт кайтып җитте; хәерле турылыклар булсын иде.

Әлми кисәге [7] саумы? Бездән үзенә сәлам.

1283 ел җөмәдие-л-ахирнең соңгы биш көненең якшәмбесе [8]. Язучы Габдулла [9] Шиһабетдин Бәһаветдин улы Мәрҗани.

---

[1] Кәлимулла — Хөсәен Фәезхановның шәкерте. Бу хатның фоторәсеме «Мәрҗани мәҗмугасында» бирелгән. Текстның бер өлеше Р. Фәхретдиновның кулъязма «Асар»ендә бар. Мәгәр аның тулы килеш бер җирдә дә басылганы юк. Шуңа күрә дә моңарчы «Мәрҗани Фәезханов проектына каршы булган» дигән ялгыш фикер яшәп килде.

[2] Остазларына хат язганда, элекке шәкертләр, фатиха сорап, акча җибәрә торган булганнар.

[3] Гарәпчә әйтемнәр.

[4] Мәрҗани әсәренең исеме.

[5] Сүз Фәезхановның татарлар өчен дөньяви гимназия ачу буенча төзегән мәшһүр проекты турында бара («Казан утлары» журналының 1966 елгы 9 санындагы безнең мәкаләгә карагыз).

[6] Гарәпчә әйтем.

[7] Бу кешенең кем булуын ачыклый алмадым. Мәрҗанинең якын итеп шаяртуына караганда, аның шәкертләреннән булырга охшый.

[8] 1866 ел, 9 декабрь.

[9] «Габдулла»ның мәгънәсе — алла колы. Бу исемне Мәрҗани шул мәгънә ягыннан чыгып файдалана.

## МӘРҖАНИ — РОССИЯ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕНӘ[1]

Безнең мәсҗетебездә булган ташның озынлыгы бер вершоксыз ике аршын, киңлеге өч чирек [аршын], калынлыгы бер вершок; түбәсе очланып тора, алты юл текст өстендәге өчпочмакта язулар юк. [Текстның] язулары ачык, мәгәр сул яктагысы бераз кубып төшкән, мәсәлән, бу рәвештә[2]:

«Калә аллаһе тәбарәкә вә тәгалә:
Көлле мән галәйһа фанин вә йәбкый вәҗһ,
Раббикә зу-л-җәлали вә-л-икрам[3].
Тарих тукыз йөз утыз
алтыда Шәһмөхәммәд-бик углы Мөхәммәдгали-бик 15 зөлькагдасында[4]
кяфир кулындин шәһид».

[Ташның уң як кырыенда]:
«Калә-н-нәби галәйһессәлам: әд-дөнья сәгатөн фәҗгальһа тагатән»[5].
Ташның аркасында язылган:
«Бу ләүхне углы Тәңреколый-бик бина кылды»[6].

Бу сул тарафыннан кубып төшкән. Мәгәр «калә» сүзе калган янә «әлиф» һәм «лям» бар; «Әл-җәлал» яисә «ән-нәби» сүзләренең [башлары]мы[7]?

«Зу-л-җәлал» дигән, гадәти укылышча «зи-л-җәлал» димәгән. «Шаһ» сүзендәге «һ» бу сурәттә куелган[8]... «Кяф»ларны «бик» һәм башка сүзләрдә бу сурәттә куйган, мәсәлән...[9] Кәләч юлы кешеләре арасында дәвам иткән гадәтчә ата исемен бала исеменә тәкъдим кылган[10]. «Кяфер кулындин» дигән, «кулындан» димәгән. Янә «шәһид» дигән, «булды»сын әйтмәгән. «Фәҗгальһа»ны бу сурәттә язган: «ф»ны кушмаган, ләкин, гайн» (гъ) вә «һа» (h) бөтенләй җуелып беткән. Икенче яктагы (арт яктагы — М. Г.) «бу ләүхне» дигән сүздәге «х» астына, Мавәрәннәһер гадәтенчә йомшак «х» астына, һәмзә галәмәте куелган.

Кыскасы, бу язу куелган кабернең иясе Мөхәммәдгали-бик Шаһмөхәммәд-бик углы дигән кеше икән, 936 ел 14 нче зөлькагдада «кяфер кулындин шәһид» икән. Бары алла үзе генә дөреслекне белә! Казанны руслар алудан элгәре сугышларның берсендә үлгән булуы ихтимал. Иә сугыш кырында үлгән, яки көч белән үтерелгән[11].

Әмма бу ләүхне исеме аталган Мөхәммәдгали-бикнең углы Тәңреколый-бик бина кылган, ягъни яздырып куйган икән.

Мәсҗетебез җәмәгатьчелегеннән алтмыш-җитмеш яшьләрдә булган кешеләрдән соралды. Алар: «Без белгәннән бирле бу таш шушында; бирегә кайчан китерелгәнлеген белмибез», — диделәр. Хосусән Сәгыйт мөәзин, — яше алтмышка җиткән, ата-бабасы шушы мәсҗеттә мөәзин булып торган, — үзен белгәннән бирле шул мәсҗеткә беркетелгән кеше. Боларның кайберләре Печән базарыннан чыккан дип әйтәләр, кайберләре Гостинныйдан чыккан диләр. Болар фараз һәм нигезсез сүзләр генә. Ләкин яше туксанга җиткән Әхмәт Исмәгыйл углы дигән бер карт бар; сәламәт гакыллы һәм үз гомерендә булган вакыйгаларны яхшы хәтерли торган кеше. Ул элек шушы мәсҗет әһеленнән булган икән, [шул] әйтә: «Бу таш югары Гостинныйда Чәй рәтенең Черек күлгә таба булган почмагын казыганда милади белән 1798 елда безнең күз алдыбызда чыкты. [Ул вакытны] без анда читек-башмак сәүдәсе белән утыра идек», — дидер.

---

[1] Мәкалә формасында төзелгән бу хат Россия фәннәр академиясенең гыйльми секретаре академик В. В. Вельяминов-Зерновның Х. Фәезханов аша ясаган махсус үтенечена җавап рәвешендә язылган («Казан утлары» журналының 1966 елгы 9 санында басылган безнең мәкаләгә карагыз). Мөрәҗәгать кеше аша булгач, Мәрҗани да үз җавабын Фәезханов аша җибәргән. Хаттан бер-ике өзек Вельяминов-Зерновның «Исследование о касимовских царях и царевичах» исемле китабында басылган. Документның тулы текстын без СССР Фәннәр академиясе архивының Ленинград бүлегендә таптык (778 фонд. 1 оп. 16 сан).

[2] Мәрҗани ташның рәсем-схемасын да ясаган, без бары текстны гына бирәбез.

[3] Кабер ташларында языла торган трафарет сүзләр. Мәгънәсе: «Мактаулы һәм бөек алла әйтте: [җирдәгенең] бөтенесе фани, [бары] синең мөхтәрәм кодрәтле тәңрең генә калачак».

[4] 1530 елның 10 августына туры килә. Һ. Юсупов китабында «14» төшеп калган, ә «10 август» урынына «10 июль» бирелгән (Г. В. Юсупов. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. М. 1960. Рус телендә. 68 таблица).

[5] Мәгънәсе: «Пәйгамбәр галәйһессәлам әйтте: дөнья сәгать [кенә], аны гыйбадәт [юлында] файдалан».

[6] Бу сүзләр ромб рәвешендәге сызыклар эченә алынган; ләүхә — язу.

[7] Эпитафия тексты шунда бетә.

[8] Йөрәк яки гарәпчә «5» саны кебек язылган.

[9] Гади «кяф»ның өстенә һәмзә галәмәте куелган.

[10] Ягъни «Мөхәммәдгали-бәк Шаһмөхәммәд-бәк углы» диясе урынга... «Бик» кушма исем өлеше түгел, бәлки «бәк» — титул.

[11] Җөмләнең икенче өлеше белән Мәрҗани Казан ханлыгында барган эчке низагларга ишарә ясый булса кирәк.

Сонра «әфәнде» дип мәшһүр булган Ибраһим Хужаш углы шушы мәсҗеткә китереп куйдырды, ди. Ибраһим әфәнде мәсҗет салынгач булган имамнарның өченчеседер. Нурмөхәммәт-мәхдүм мөхтәсибнең атасы. Йәнә әлеге карт: «Бу кабер иясе Шаһгали [хан]ның якын кешеләреннән шикелле», — дип әйтә. Бу якынча фикер һәм арттыру. Бәлки, [Шаһмөхәммәднең] туганының углы Шаһгали [хан] булгандыр, чөнки һәр икесенең исеменнән дә «шаһ» сүзе чыгарылган [12]. Бу ташның хәле ачык, ул монда тәмам булсын.

Әмма Архиерей [дачасы] алдындагы ташны үзегез дә ничә мәртәбәләр күргәнсез. Бик зур таш: биеклеге биш аршын, киңлеге биш чирек [аршын], калынлыгы якынча ун вершок. Без фәкыйрь [моннан] элек аны ике мәртәбә барып карадык — һич тә укылмады. Ләкин элегрәк булган «һүә-л-хәйе әлләзи ля йәмутө» янә «һәза кабер әс-солтан әл-әкбар вә-л-мәлик әл-мозаффар» сүзләре, алардан [берничә] юл түбәндә «әл-мәлик зәлл-аллаһе» дигән сүзләре беленә. Болардан башкаларын аңлый алмадык. Фәкыйрегезнең фикеренчә, бу бик борынгы әйбер булса кирәк. [Текстның] өсте алтын йә көмеш белән бизәлгән булырга тиеш, [аларның] урыннары бар [13].

Бу [кабер иясе] Туктамыш яки Тукайтимер һәм башкаларның нәселеннән булган Үзбәк-ханнар гына булмаса кирәк. Чөнки Үзбәк вә аның аталары нигездә бабаларының асыл ватаны булган Кытай мәмләкәтендәге борынгы гадәтләрен һәммә эшләрендә дә ригая кылалар. Шуңа күрә сөйләм тел белән язма һәм башкаларда да, шулай ук кабер ләүхәләре белән исемлекләрендә дә ул гадәткә нык тотынып, үзбәкчә сарыфны [14] һәм төркилекне алга сөрәләр. Ә бу таш исә гарәпчә язылган. «Солтан» һәм «мәлик» исемнәре бар. Үзбәкиләр, ягъни Җуҗи я Чыгтай нәселендә исә «хан» һәм «бәк» сүзе күп кулланыла. Бу [кабер иясе исә] Болгарның элекке мәликләреннән берсе булырга охшый. Чөнки аларның иң элек мөселман булганнары, Алмас-хан Сәлки-хан углы, Габбасилардан [15] Моктадир Биллаһга буйсынуны бурыч итеп алып, Габбасиларны баш белеп, акчаларны алар исеменә [сугалар], хөтбәләрне [16] аларга кылалар иде. һәм бар эштә дә аларга охшауны үзләренә һөнәр итеп алганнар иде. Хәтта электәге гади «хан» титулын «әмир»гә, ә үз исемен «Алмас»тан Җәгъфәргә алыштырып, «әл-әмир Җәгъфәр» дип исемләнде, ә углына «әмир Әхмәт» дип куйды. Шулай ук [Алмасның] нәселләреннән әл-әмир Мөэмин, әл-әмир Талиб һәм башкаларның Насрлиддини-ллаһ Габбасига [17] кадәр нигездә шул тәртипне тотулары мәгълүм бит. Минем фикеремчә, аның [Алмасның] нәселе Тимур һөҗүменә кадәр [18] исән иде. Ләкин Үзбәкләргә, ягъни Чыңгыз нәселләренә буйсынуда иделәр. Болгар әмирләреннән Тимур тарафыннан үтерелгән әмир Габдулла шуларның соңгысы дип уйлыйм [19]. Бу династиядән Чыңгыз нәселләренә [беренче булып] буйсынучы кешенең исеме йә Мөслим, йә Ислам иде. Бу минем фаразым гына, әлбәттә.

Йәнә Казанга руслар һөҗүм кылганда казый Шәрифкол, Икъбал-бик һәм Миркәш-бик дигән кешеләр бар иде дип кайбер җыентыкларда күргәнем бар иде. Шулай ук Казан ханнарының башы Туктамыш [нәселеннән] дип фикер кылам.

Язды Габдулла [20] Шиһабетдин Баһаветдин углы әл-Мәрҗани, җомга көне 25 җөмадие-л-үла, 1277 ел [һиҗри] [21].

Наср-лиддини-ллаһ әл-Габбаси исеменнән Болгарда сугылган дирһәмнәрне [22] күргәнем бар. Шулай ук Талиб һәм Мөэмин дирһәмнәрен дә күргәнем бар [23].

---

[12] Сүз Мөхәммәдгали һәм Тәңреколыйлар исеме турында бара: аларда, чыннан да, «шаһ» сүзе юк.

[13] Соңрак Мәрҗани таштагы текстны тагы да тулырак итеп укып, аны «Мостафад әл-әхбар» китабында китерә (1 нче кисәк, 30, 93 битләр). һ. Юсупов шул укылышны үзгәртмичә кабул итә (күрсәтелгән әсәр, 2 таблица).

[14] Сүз Алтын Урда дәверендә киң таралган Идел буе һәм Урта Азия әдәби төрки телләре турында бара. Ләкин ул вакыттагы әдәби телләрне «үзбәкчә» дип әйтү, әлбәттә, дөрес түгел.

[15] Габбасилар — гарәп хәлифәләренең бер династиясе (750—1258). Болгар дәүләте 921—922 елны ислам динен официаль рәвештә кабул иткәч, шул Габбасиларны башлыклары дип игълан кылалар.

[16] «Хөтбә» — биредә: мәчетләрдә дәүләт башлыкларына багышланган дога.

[17] 1225 елда үлгән гарәп хәлифе.

[18] Тимур, XIV гасырның 90 нчы елларында Идел буен яулап алып, Сарай һәм башка шәһәрләрне җимерә. Кайбер чыганаклар аның Болгар һәм Биләр шәһәрләрен җимерүе турында да хәбәр итәләр («Дәфтәре Чыңгыз-намә» китабындагы «Елъязма» исеме белән йөртелә торган соңгы бүлек).

[19] Мәрҗани «Дәфтәре Чыңгыз-намә»гә таянып сөйли.

[20] Беренче хатка бирелгән соңгы аңлатмага карагыз.

[21] 1860 ел, 29 апрель (яңа стиль белән).

[22] Урта гасыр шәрык илләрендә акча берәмлеге. Болгар җирендә сугылган көмеш таңкалар да «дирһәм» дип аталган.

[23] Датадан соңгы бу сүзләр хатка өстәмә рәвешендә язылган.



# ВИРТУОЗ МАНДОЛИНЧЫ

*(Исмәгыйл Һилаловка 70 яшь тулу уңае белән)*

Мандолин, гармун белән скрипкага караганда, безнең халыкка соңрак кергән музыка коралы. Бары XX гасырның башларында, бигрәк тә 1905 елгы революциядән соң гына, татарлар арасында мандолин күренә башлый. Ләкин гади халык, бигрәк тә авыл халкы арасында, ул киң тарала алмый. Ихтимал, бу — мандолинның, башка уен кораллары белән чагыштырганда, катлаулырак төзелешле булуы белән аңлатыладыр. Гади нарат агач, ат койрыгы кылы, киптерелгән эчәге — скрипка ясау өчен шулар да җиткән. Ә мандолин өчен корыч кыллар, тешле җиз тәгәрмәчләр, бакыр тасмалар кирәк. Гади авыл агае аларны каян тапсын?!. Аның каравы, алдынгы карашлы татар яшьләре, мәдрәсә шәкертләре арасында мандолин зур хөрмәт казана. Бу уен коралын популярлаштыруда Г. Тукай, Ф. Әмирхан кебек әдипләр якыннан катнаша. Шәйхзадә Бабич хәтта аңа багышлап махсус шигырь дә яза:

**И үзәк өзгеч тавышлы, моңлы, зарлы мандолин,**
**Килче, моңланчы өзеп бер, мин дә тыңлап моңланыйм.**
**Син минем җан сердәшем, җан моңдашымсың, мандолин!**
**Сергә беткән, моңга беткән зарлы тавышың җанга им.**
**Шул синең тавышың гына тик дәртемә дәрман бирә,**
**Шул бирә һәр нәрсәне; шул җан бирә, шул ямь бирә...**

Шушындый шигырьләр укып зәвыкланган яшьләр арасында мандолинның популяр булып китүе бер дә гаҗәп түгел, билгеле.

Мандолин белән мавыгу халык музыка кораллары оркестрлары тууга китерде. Шундый оркестрларның берсе 1910 елда Троицк шәһәрендә дә оеша. «Театр вә му-

зыка сәнгатьләрен тәрбиҗ итү» җәмгыяте тарафыннан төзелгән 16 кешелек бу оркестр белән һәвәскәр музыкант Салих Айманов җитәкчелек иткән.

Шулай бер вакыт, оркестрга яшьләрне тарту, аны зурайту турында сүз барганда, кемдер:

— Гобәйдулла малае Исмәгыйльне чакырырга кирәк. Ул мандолинда ифрат яхшы уйный, — дип киңәш итә.

12 яшьлек Исмәгыйль, үзе кадәр мандолинын күтәреп, Айманов оркестрына килә. Оркестрда эшләү дәверендә ул скрипкада уйнарга өйрәнә, хосусый рәвештә укып, музыка грамотасына төшенә, нотага карап уйнау серләрен үзләштерә башлый.

1912 елда Троицкига Габдулла Тукай килә. Шәһәрнең алдынгы карашлы кешеләре һәм яшьләр шагыйрьгә зур игътибар күрсәтәләр. Шул көннәрдә Исмәгыйль Тукай белән танышу бәхетенә ирешә. Ул аңа мандолинда «Әллүки» һәм «Җәмилә» көйләрен уйнап күрсәтә. Шагыйрь бәләкәй музыкантның сәләтенә югары бәя бирә.

Исмәгыйльнең «артист» булып йөрүенә туган-тумачалары шатланмый, билгеле. Ялгыш юлдан киткән малайны «кеше» итү, аны юньлерәк һөнәргә өйрәтү турында уйланалар алар. Йомшак табигатьле Исмәгыйль, картлар сүзен читкә какмас өчен, 1916 елда Оренбург шәһәренә килергә, андагы фельдшерлар мәктәбенә укырга керергә мәҗбүр була. Бәхеткә каршы, Оренбургның алдынгы карашлы интеллигенциясе 18 яшьлек талантлы музыкантка вакытында ярдәм кулы суза, үз юлын табарга булыша. Музыкант Газиз Булатов, «Ширкәт» артистлары, труппаның җитәкчесе Муртазин-Иманскийлар йогынтысында ул яңадан зур сәнгать дөньясына әйләнеп кайта. Фельдшерлар мәктәбендә уку белән бергә, музыкаль белемен арттыра, Австриядән килгән Богачко исемле музыка остазыннан дәресләр ала.

Бөек Октябрь социалистик революциясен Исмәгыйль Һилалов җитлегеп килүче музыкант буларак каршылый. Озакламый аны «Музыка җәмгыяте»нең рәсми рәисе итеп сайлыйлар. Җырчы Газиз Әльмөхәммәдев белән бергә, ул революцион солдатлар яшәгән казармаларда, Карвансарай диварларында концертлар оештыра.

1918 елда Оренбургка шагыйрь Шәйхзадә Бабич килә. Исмәгыйль берничә ай Бабич белән бер бүлмәдә яши. Эштән буш араларда алар парлап мандолин уйныйлар. Талантлы шагыйрь Һилаловның осталыгына сокланып бетә алмый. «Син мандолин патшасы», ди ул аңа. Бабич белән Исмәгыйль Һилалов безгә туган тиешле Газизә апа Хөсәеноваларда тордылар. Мин еш кына Газизә апаның улы Гомәр янына уйнарга килә идем. Мәшһүр шагыйрь белән талантлы музыкантны беренче мәртәбә әнә шунда күрдем. Әле дә хәтеремдә. Музыка тавышын ишетүгә, без йөгереп өйгә керәбез. Ишек төбендә авызларыбызны ачып, шаклар катып, аларның ничек уйнаганын карап торабыз. Безнең карап торганны күргәч, алар тагын да арттырып җибәрәләр: кулларын кыллар өстендә әйләндереп-болгандырып уйный башлыйлар. Безгә кызык. Кычкырып көлмәс өчен, уч белән авызларны каплап, әкрен генә хихылдыйбыз. Кара кучкыл йөзле, өрәңге яфраклары шикелле яссы колаклы Шәйхзадә абый, күз кысып, елмаеп куя. Шәп уйныйбызмы, янәсе. Ә теге ак чырайлы, калын иренлесе безгә бөтенләй игътибар да итми кебек. Каядыр бер читкә караган да, уйный да уйный.

Шулай күпмедер торгач, Шәйхзадә абый, уйнавыннан туктап, өстәлдән нәрсәдер ала. Ымлап кына үз янына чакыра. Без, аның учындагы сары һәм ал помадкаларны алып, урамга чыгып чабабыз...

Шәйхзадә абыйның ялгыз гына уйнап утырганын да күргәнем бар. Ул мандолинны әллә ничек, үзенчә тотып уйный иде. Инструментның башы аның зур колагы янына ук күтәрелгән. Үзе, серле сүз тыңлаган шикелле, башын грифка салган. Авыз янына ук күтәрелгән уң кулы әкрен генә кыллар өстендә тибрәлә. Тавыш тонык та, моңлы да чыга...

Бер башлагач, сөйләп бетерим инде. Муса Җәлил дә мандолинны Бабич кебек үк уйный иде. Бәлки, аннан күреп калгандыр. Ф. Кәрим, киресенчә, грифны аска төшереп, медиаторны подставка төбендә үк чиртеп, чыңлатып уйнарга ярата иде. Ә мин Хәсән Туфанны күргәнем юк. Бик оста уйный, хәтта нотаны да әйбәт таный, дип сөйләгәннәрен генә ишеткәнем бар...

1919—20 елларны Исмәгыйль Һилалов, Газиз Әльмөхәммәдев белән бергә, Уфа тирәсендә концертлар куеп уздыра. 1921 елда без аны яңадан Оренбургта күрәбез. Бу килүендә ул «Шәрык музыка мәктәбе»нең директоры, булачак композитор Салих

Сәйдәшев белән таныша, Кәрим Тинчурин һәм Бари Тархановлар белән аралаша. Авыр тормыш шартлары, ачлык аны Ташкентка китәргә мәҗбүр итә. Анда ул һәвәскәр композитор Исхак Хәмзин һәм шагыйрь Һади Такташ белән дуслаша. Шундагы татар артистлары оештырган концерт һәм спектакльләрдә катнаша. Бу вакытта инде Исмәгыйль Һилалов зур осталыкка ирешкән атаклы мандолинчы булып танылa. Ул Советлар Союзының бик күп почмакларында була, йөзләрчә концертлар бирә. Ниһаять, 1924 елда Һилалов Казанга килә. Композитор Солтан Габәши, Гөлсем Сөләйманова, Мәрьям Рахманкулова,Ситдыйк Айдаров кебек җырчылар аны үз араларына алалар, үзләре оештырган концертларда катнаштыралар.

Мин шул елларда чыккан газеталарны, журналларны актарам. Вакытлы матбугат битләрендә Исмәгыйль Һилалов иҗатына багышланган материаллар байтак икән. Аларда танылган музыкантның эшчәнлегенә гаять югары бәя бирелә. Менә шуларның кайберләре:

«Һилаловның мандолины матур чиртте, мандолин короле икән, диделәр».

*(«Кызыл Татарстан» газетасы)*

«Исмәгыйль Һилалов мандолинда уйнавы белән исемне китәрде. Рустан, татардан да аны алай уйнаучыны күргәнем юк иде. Медиаторны гаҗәп бер осталык, матурлык белән йөртә, фигуралар бирә, круглар ясый. Таланты алдында баш иеп утырдым», дип яза танылган драматург Мирхәйдәр Фәйзи.

«Исмәгыйль Һилалов иптәш үзенең мандолины белән күптән сөелеп тыңлаган кеше. Аның бу чыгышында иң матур момент «Яңалиф» маршы һәм татар көйләре тезмәсе булды».

*(Уфа. «Яңа авыл» газетасы)*

«Татарлар яшәгән шәһәрләрдә Исмәгыйль Һилаловны белмәгән кеше юктыр. Мандолинда оста уйнавы белән ул халыкның дикъкатен дә, мәхәббәтен дә үзенә тарткан... Чынлап та, Һилаловның уйнавында гадилектән бик күп югары тора торган осталык, виртуозлык, гадәттән тыш бай техника күрәбез» — дип язды 1928 елда журналист Сафа Борһанов.

«Танылган татар мандолинчысы — виртуоз Исмәгыйль Һилалов үзенең концерт чыгышлары белән Ташкентка яхшы таныш. Төрләндерелгән репертуары Һилаловка башкару техникасын бөтен гүзәллеге белән күрсәтергә ярдәм итте. Виртуоз җиңеллек һәм иркенлек белән ул татар халык көйләре тезмәсен һәм берничә марш башкарды».

*«Правда востока» газетасы. 1936 ел.*

Исмәгыйль Һилалов ничек шундый зур дан казана алган? Уңышның сере нәрсәдә?

Беренчедән, ул зур тойгылы, эмоциягә бай музыкант, һәм мандолин уйнаучылар арасында иң матур тавышлысы.

Икенчедән, аның уйнау техникасы бик югары. Ноталар алучы сул кулы да, кылларны тирбәтүче уң кулы да искиткеч тизлек белән оста хәрәкәт итәләр. Аның медиаторы бервакытта да сөртенми, һәрвакыт тигез тавыш чыгарып тора. Шуның белән бергә, ул мандолин грифының теләсә кайсы җирендә уйный, әсәрнең настроениесенә карап, тавыш тембрын үзгәртә ала. Йомшак яки каты чиртеп, нюанслар кертә. Әсәрнең эчтәлеген тулы һәм дөрес ача белә. Мандолин көй уйнаучы музыка коралы гына булуга карамастан, Һилалов көй белән генә чикләнми. Ул — көйне берничә тавыштан торган аккордлар белән баетып уйнау осталыгына ирешкән виртуоз артист. Бу исә мандолин яңгырашы өчен яңалык булды. Нәтиҗәдә, аның уенын тыңлаганда, без урыны-урыны белән лютна, гитара һәм казакъ думбрасы тавышларын да ишетәбез.

Шуны да истән чыгармаска кирәк: Исмәгыйль Һилалов үзенең бөтен артистлык гомерендә концерт репертуарын үзе тудырды, композиторлар аңа булышмадылар. Шуңа да карамастан, Исмәгыйль Һилалов башкарган әсәрләр үзләренең форма төзелеше, контрастлылыгы белән камил иделәр. Ул уйнаган попурри һәм вариацияләр моның ачык мисалы. Шәһәрдән-шәһәргә, концерттан-концертка, алкыштан-алкышка тантаналы йөреш белән үзенең 70 яшьлегенә килгән олы артист ул Исмәгыйль Һилалов!

Шул урында сүзне бетерергә дә булыр иде. Ләкин аның иҗат портретын тулыландыру өчен, музыка сәнгате юлындагы оештыру эшчәнлегенә дә тукталырга кирәк.

Исмәгыйль Һилалов татар музыка сәнгатен үстерүгә, аны пропагандалауга күп хезмәт куйды. 1930 елларда ул Мәскәү консерваториясе каршындагы башкорт һәм татар опера студияләрен оештыруда актив катнашты. 1938—39 елларда үзбәк филармониясенең уку һәм производство бүлеге мөдире булып эшләде. 1940 елда без аны Татарстан радиосының музыка бүлеге редакциясендә күрәбез. Бөек Ватан сугышы елларыннан алып 1958 елга кадәр ул — Татар дәүләт филармониясенең концертлар оештыру администраторы. Галиәсгар Камал исемендәге татар дәүләт академия театры да, республика Күчмә театры да аның администраторлык ярдәменә бик еш мөрәҗәгать иттеләр. Урта Азия республикаларында үз кеше булып танылган Исмәгыйль Һилалов бу коллективларның гастрольләрен бик күп мәртәбәләр югары дәрәҗәдә оешканлык белән уздырды.

«Сания» һәм «Эшче» операларын язганда, В. И. Виноградов, Солтан Габәши һәм Газиз Әльмөхәммәдевларга Исмәгыйль Һилалов уңай иҗат шартлары тудырышты. Яшь талантлар өчен ул сизгер тәрбияче, киңәшче һәм дус та иде.

1958 елда Исмәгыйль ага Һилалов лаеклы һәм хөрмәтле ялга китте. Ләкин хәзерге көндә дә сәнгать оешмалары әледән-әле аңа киңәш, ярдәм сорап, яки радиода, телевидениедә чыгышлар ясавын үтенеп мөрәҗәгать итәләр. 57 ел буена кулыннан мандолин төшермәгән, татарның музыка һәм театр сәнгатен пропагандалау һәм яшь кадрлар тәрбияләү эшендә зур хезмәтләр күрсәткән сәнгать ветераны Исмәгыйль Гобәйдулла улы Һилаловны 1968 елның 15 январенда 70 яшь тулу көне белән чын күңелдән тәбрик итәбез. Аңа таза-саулык һәм бәхет телибез!

Аның исеме татар халкының Заһидулла Яруллин, Солтан Габәши, Фәйзулла Туишев кебек беренче профессиональ музыкантлары белән беррәттән торырга хаклы!

ҖӘҮДӘТ ФӘЙЗИ,
композитор.

• • •

# *Язучы һәм педагог*



Язучы Хөсни ага Кәрим революция дулкыннары ярдәмендә зур юлга чыккан мәдәният кешеләребезнең берсе иде.

Ул Уфа губернасының Бөре өязе, Туйморза авылында ярлы крестьян семьясында туа. Ундүрт яшеннән үз көнен үзе күрә башлый. Җәй көннәрендә азмаз акча туплап, баштарак авыл мәдрәсәләренең берсендә тузан исни, соңыннан укуга булган дәрте аны Уфадагы Галия мәдрәсәсенә китерә. Шул вакытларда ук М. Гафури, Г. Ибраһимов һәм Шәйхзадә Бабичлар белән дуслашып ала, шулар ярдәмендә, күп авырлыклар кичереп булса да, мәдрәсә тәмамлый. Мәдәнияткә, белемгә омтылган яшь егетне мәдрәсә биргән белем генә канәгатьләндерми. Ул рус теле һәм әдәбияты белән кызыксына, учительлеккә имтихан биреп, рус-татар училищесында укыту хокукы ала. Шул көннән башлап, ул халыкка хезмәт күрсәтү юлына баса. Астраханьга килеп, рус-татар училищесында укыта, шагыйрь Сәгыйт Рәмиев, революционер Нариман Нариманов һәм башкалар белән аралаша, «Идел» газетасында мәкалә һәм фельетоннар бастыра. Аның яңа фикерле мәкаләләре карагруһларга ошамый, ул полиция күзәтүе астына алына. Хөсни ага тагын Уфага китәргә мәҗбүр була. Ул анда шәкертләр укыта, иҗат эшләре белән шөгыльләнә. Менә шундый эшләр өстендә ул февраль революциясен каршылый. Бу көннәр аның «Ертылган приказ» исемле әсәрендә бик тулы сурәтләнгән.

Хөсни аганың әдәби иҗат эше мәдрәсә почмакларында ук башлана. Аның «Атнакич яки Шакир хәлфә» исемле ике пәрдәлек драма әсәре 1910 елда басылып та чыга. Г. Ибраһимов, М. Гафурилар аның шушы өйрәнчек әсәренә үк уңай бәя бирәләр. Шул көннән башлап, ул күп санда хикәяләр һәм повестьлар яза. Хөсни ага Кәримнең «Ике дус», «Җан исәбе алганда», «Ак песи», «Ачлар шатлыгы», «Югалган межалар» кебек әсәрләре әле хәзер дә тарихи кыйммәтләрен җуймаганнар.

Хөсни ага 1919 елдан партия члены иде. Аның Совет властен ныгыту юлында күрсәткән хезмәтләре зур. Казанга күчеп килгәч тә, ул төрле культура учреждениеләрендә, Наркомпроста, главлитта эшли, зур иҗади эшләр башкара. Кызганычка каршы, бу зур йөрәкле, киң күңелле, шуның белән бергә бик тә гади, тәкәллефсез чын совет кешесе, өлкән коммунист арабызда юк инде. Озак һәм каты авырудан соң 1965 елда ул безнең арабыздан китте. Шулай да без аны онытмыйбыз, аның зур педагогик һәм иҗади хезмәтләрен искә төшерәбез.

Г. БАКИР

# ЯҢА ТАБЫШМАКЛАР

„Яшь ленинчы» газетасы аша без мәктәп балаларына үзләре һәм семьяларындагы өлкән кешеләр белә торган табышмакларҗны язып җибәрүләрен сорап мөрәҗәгать иткән идек [1]. Нәтиҗә матур булып чыкты. Укучылар ярдәмендә җыелган табышмаклар саны меңнән артып китә. Алар табышмакларыбыз фондын тагын да баету һәм халык иҗатының бу афористик жанрын фәнни яктан өйрәнү өчен әһәмиятле чыганак булырлар, дип ышанасы килә.

Татарстан районнарыннан тыш, без Башкортстан, Чувашстан, Мари автономияле республикаларыннан, Төмән, Оренбург, Омск, Пермь, Куйбышев, Горький, Ульяновск, Пенза, Киров өлкәләреннән табышмаклар алдык. Бу исә аларның географиясе — кайсы табышмакларның кайларда һәм нинди үзенчәлекләр белән яшәвен тикшерү өчен киң мөмкинлек ача. Бер генә мисал. Бездә ай һәм йолдызлар турындагы матур бер табышмак киң таралган: «Мич тулы пәрәмәч, уртасында бер калач». Менә шушы табышмак Омск өлкәсендә, гәрчә төп метафоралары саклапса да, шактый үзенчәлекле формада әйтелә икән:

Мич, мич, мичәкәй,
Мич эчендә чичәкәй.
Чичәкәйдә бер бәлеш,
Түгәрәге бәрәмеш.

Традицион, ягъни элекке табышмакларның бүгенге яшәү формалары турында фикер йөрткәндә, гадәттә, ике моментны күрсәтәләр. Мондый табышмаклар я берниндн үзгәрешсез яшәүләрен дәвам итәләр, я кайбер сүзләрен алыштыру юлы белән алардан яңа табышмаклар ясала [2]. «Яшь ленинчы» газетасы аша тупланган материаллар нигезендә, без моңа өстәп тагын шуны әйтә алабыз: кайбер табышмаклар, элекке формаларын саклаган хәлдә, үзләренә яңа җавап алып, бөтенләй башка әйберне яки күренешне белдереп яшәргә дә мөмкин икән. Оренбург өлкәсеннән безгә «Кайчысыз киселә, җепсез тегelә» дигән табышмак килде. Җавабы — пилмән ясау. Шул ук табышмакны Тымытыктан да алдык. Җавабы — электросварка. Күрәсез, ике җавап та бик тапкыр, һәм бу табышмакның соңгы вариантта үзенең икенче тормышын башлап җибәрү ихтималы юк түгел. Моңа охшашлы мисалларны тагын берничәне китереп була. «Нәрсә үсә тамырсыз?» (Таш) дигән табышмакка байтак балалар «гөмбә» дип җавап бирәләр. Арадан берсе үзенең җавабын фән ярдәмендә дәлилләп үк куя: «Бу сорауның җавабын мин «Ботаника» китабыннан таптым. Анда, гөмбәләрнең сабаклары да, тамырлары да юк, дип язылган»,— ди. «Арбага утырмас, җәяү йөрмәс» табышмагына «шофер», «очучы»; «Нәрсә оча канатсыз?» (Җил) соравына «ракета» дигән җаваплар күп. Кызыклы бер момент. Соңгы вакытта иҗат ителгән русча табышмакларның берсендә ракета шулай ук «канатсыз очучы кош» итеп тасвирлана [3].

---

[1] Х. Мәхмүтов. Табышмак капчыгын чишәбез. «Яшь ленинчы» газетасы. 1967 ел. 14 январь.

[2] Н. Исәнбәт. Табышмаклар. Казан. 1941 ел. 14 бит.

[3] «Мурзилка» журналы. 1967 ел. 3 сан. 19 бит.

Укучылар җибәргән табышмакларның кыйммәтле бер ягы шул — алар арасында яңалары, ягъни моңа кадәр матбугатта күренмәгәннәре шактый очрый (Без моңда нигездә традицион табышмакларны күздә тотабыз). Электән билгеле табышмакларның кызык-кызык вариантлары да бар. Әйтик, «Үзе бара бикәдәй, эзе кала тәңкәдәй» дигән табышмак (җавабы — таяк. Чирмешән районыннан килгән). Моның төрле вариантлары матбугатта байтактан бирле күренеп килә: «Үзе бара, эзе кала»[1], «Үзе бара, уймак-уймак эзе кала», «Озын агай үзе бара, тәңкә-тәңкә эзе кала»[2] һәм башкалар.

Безнеңчә, укучы җибәргән вариант арада иң уңышлысы. «Үзе бара, эзе кала» дип кенә әйтү таяк дигән җавапны табу өчен һич тә җитәрлек түгел. Чөнки барган вакытта бик күп нәрсәләрнең эзе кала. Соңрак китерелгән табышмакларда бу җитешсезлек инде төзәтелә. «Тәңкә-тәңкә» яки «уймак-уймак» эз калдыру, чыннан да, таяк өчен хас. Без китергән вариантта исә табышмакның тасвир көче тагын да арттырылган. Таякның «баруы» гәүдәсен шәмдәй турайтып, кәперенеп йөрүче бикәгә охшатыла. Монда рифма да матуррак яңгырый.

Без мәктәп балалары булышлыгы белән җыелган яңа табышмакларның кайберләрен журнал укучыларына тәкъдим итәбез. Табышмакның моңа кадәр матбугатта басылу-басылмавын билгеләгәндә төп критерий итеп Н. Исәнбәтнең югарыда телгә алынган җыентыгын файдаландык. Чөнки ул татар табышмакларының иң тулы җыелмасы.

Моннан тыш М. Иванов, венгр галиме Г. Балинт, М. Салихов, К. Насыйри, Т. Яхин, Г. Арсланов җыентыкларындагы, шулай ук «Татар халык иҗаты» антологиясендәге (1954 елгы басма) табышмакларны да күздән кичердек.

Соңгы сүз итеп, табышмакларыбыз фондын баетуга өлеш кертүләре өчен, «Яшь ленинчы» редакциясе коллективына, табышмак җибәргән барлык укучыларга зур рәхмәт белдерәбез.

Х. МӘХМҮТОВ,
аспирант.

●

1. Ак күл, ак күл эчендә сары күл

*(Мари АССР, Мари-Төрек районы).*

2. Ару бодай эчендә алтын йозак

*(Буа районы).*

3. Билен буган Күктимер
Ишектән түргә сикерер

*(Төмән өлкәсе, Төмән районы).*

4. Бушка килә, акчага китә

*(Оренбург өлкәсе, Шарлык районы).*

5. Варвараның бармагы, җитмеш ике тырнагы

*(Минзәлә районы).*

6. Зыр-зыр-зырманый,
Зырачтри, пәчтри

*(Татарстан, Алан авылы).*

7. Зыр-зыр әйләнә,
Үзе килеп бәйләнә

*(Татарстан, Алан авылы).*

8. Йөгерек-йөгерек, ни йөгерек?

*(Балтач районы һәм Оренбург өлкәсе, Шарлык районы)*[3]

9. Кечкенә генә Петра, билен буып утыра

*(Горький өлкәсе, Кр. Октябрь районы).*

---

[1] С. Е. Малов. Из поездки к мишарям. Казан университеты типографиясе. 1904 ел. 17 бит; Хуҗа Бәдиг. Халык әдәбияты. Мәкальләр, табышмаклар. Казан. 1926 ел. 76 бит.

[2] Н. Исәнбәт. Табышмаклар. 150 бит.

[3] Н. Исәнбәт җыентыгында «Җитездән җитез — ни җитез?» дигән варианты бар.

10. Кызыл сандык эчендә күкеле сәгать кычкыра

*(Чирмешән районы).*

11. Ләбәтәй, ләбәтәй, тау астына тәгәрәтәй

*(Башкортстан, Дүртөйле районы).*

12. Мине тотып ашамыйлар,
Миннән башка туй да ясамыйлар

*(Әлмәт районы)* [1].

13. Олы киленем эшлекле,
Кече киленем кешелекле.
Үзем бай остабикәсе,
Эшемне кем эшләсе?

*(Киров өлкәсе, Вятские Поляны районы)* [2].

14. Падишаның күркәләре
Галдыр-галдыр итәдер.
Муенындагы мәрҗәннәре
Ялтыр-ялтыр итәдер

*(Алабуга районы).*

15. Уты юк, төтене бар

*(Кукмара районы).*

16. Читекне мин кыйнадым,
Читек мине сыйлады

*(Өлкәсе күрсәтелмәгән. Благовар районы, Ломово авылы).*

17. Читән аша эт тырнаша

*(Башкортстан, Бурай районы).*

18. Шылдыр-шылдыр-шылаука,
Өсте бар да былаука.
Аягы җиргә тимидер,
Көн яктысын күрмидер

*(Чувашстан, Батыр районы).*

19. Яшел шинель кигән, сары пояс буган,
кешеләрне бик нык шелтәлим дигән

*(Баулы районы).*

20. Әндри күзен ак алган

*(Апас районы).*

21. Үзе жырлый, үзе сыйлый

*(Мамадыш районы).*

## ТАБЫШМАКЛАРНЫҢ ҖАВАПЛАРЫ

*1. Йомырка. 2. Йолдызлар һәм ай. 3. Себерке. 4. Авыру. 5. Пычкы. 6. Йон эрләү. 7. Йон эрләү. 8. Уй. 9. Солы көлтәсе. 10. Авыз эчендә тел. 11. Ашау. 12. Тоз. 13. Сәгать һәм аның телләре. 14. Кук күкрәү, яшен яшьнәү. 15. Томан. 16. Киндераш сугу. 17. Кабадан сүс эрләү. 18. Балык. 19. Мунча себеркесе. 20. Тәрәзәгә бәс төшү. 21. Самовар.*

---

[1] Билгеле вариантларыннан моңа иң якын торганнары: «Аны ашап булмый, ансыз ашап булмый», «Мине корылай ашамыйлар, мине ташламыйлар» (Н. Исәнбәт җыентыгы. 148 бит).

[2] Беренче ике юлы «Олы кызым Мәлиха, кече кызым Сәлиха», «Бер киленем туң тимер, бер киленем туң күчән» вариантларында очрый. Безнең вариантта сәгатьнең олы телен «олы киленем эшлекле» дип алу бик тапкыр.

*Нияз Хәкимуллин*

# Һиндстанга сәяхәт

Илебез халыкара хатын-кызлар бәйрәме — 8 мартны тантаналы рәвештә каршыларга әзерләнгән кичтә без Шереметьево аэродромында идек. Март башы — безнең киңлекләрдә елның шактый салкын вакыты. Мәскәү тирәсендәге кырлар, урманнар ак карга капланган, җәяүле буран себереп тора, ә салкынлык — 15°.

Сәгать төнге уникедә ТУ—114 самолетына утырту башланды. Без, 170 пассажир, һәркайсыбыз үз урыннарыбызга утырдык. Менә самолетның ишеген дә яптылар. Аннары турбиналар гөрелди башлады һәм самолет йомшак кына итеп урыныннан кузгалды да очу кырына юнәлде. Тизлеген арттырганнан-арттыра барып, шактый йөгергәч, җирдән күтәрелеп китте һәм, күп тә үтмәде, Мәскәү тирәсендәге авыл һәм шәһәрләрнең утларын артта калдырып, Һиндстанның башкаласы Делигә юл тотты. Без хәзер тугыз километр биеклектә очабыз. Тизлек — сәгатенә 750 километр. Һаваның температурасы 52° салкынлык. Ләкин бу самолет эчендә түгел, тышта. Ә эчтә җылы, рәхәт. Кечкенә самолетлардагыча, селкенү дә юк. Әйтерсең, бер җирдә, өйдә утырабыз. Һәм һәркемнең йөзендә шатлык, күңелендә канәгатьлек, горурлык хисе. Шулай булмый хәле дә юк, чөнки бу гаҗәеп җайлы һәм тиз оча торган самолет безнең илдә, безнең кешеләр кулы белән төзелгән бит! Әйтергә генә ансат: Һиндстанга беренче булып барган рус сәяхәтчесе Афанасий Никитинга бу ерак араны узу өчен берничә айлар кирәк булган икән, без аны нибары берничә сәгатьтә үтәчәкбез!..

Мин шулай уйланып барганда, кайсыдыр кычкырып җибәрде.

— Карагыз әле, таулар өстеннән очабыз!

Барыбыз да иллюминаторларга текәлдек. Искиткеч матур күренеш: тирән ярыклар белән ерганланган бозлыклар, соңгы кебек очлы тау түбәләре яңа чыгып килә торган кояш нурында ялтырап күзләрне чагылдыра, ә астарак тиз агышлы тау елгалары күренә. Гиндукуш таулары бу. Үзәнлекләргә урнашкан әфган авыллары, алар тирәсендә утлап йөрүче сарык, кәҗә көтүләренә кадәр ап-ачык күренә.

Аннары таулар артта калды, тигезлек башланды. Кая карама — анда иген кырлары, сугару каналлары, бер-беренә бик якын утырган авыллар. Кисәк-кисәк булып яткан яшел «паласлар» арасында ара-тирә сарылар да күренгәләп кала. Игене инде җыеп та алынган җирләр ул. Һинд-Ганг түбәнлеге бу — без хәзер Пакистан җирләре өстеннән очабыз.

Тагын байтак очкач, самолетыбыз түбәнәя башлады. Түбәндә Дели каласы. Ак стеналы, яссы түбәле йортлар, һәркайда куе яшеллек. Менә нинди икән Һиндстанның башкаласы!

Шереметьеводан күтәрелеп китүебезгә җиде сәгать дигәндә, без Дели аэропортында идек инде. Ап-ак карга төренеп яткан җирдән «мәңгелек җәй» иленә килдек тә җиттек.

Самолеттан төшүгә беренче тәэсир иткән нәрсә эсселек булса, икенчесе — чәчәкләр иде. Алар шундый күп, әйтерсең, монда бөтен үсемлекләр дә чәчәк атып тора. Һавасы да бездәгечә түгел, гадәттән тыш зәңгәр һәм чиста.

Без 500 миллион халык яши торган илдә [җир йөзендәге һәр алты кешенең берсе һинд]. Җире безнекеннән 7 мәртәбә кечерәк булуга да карамастан, Һиндстанның халкы Советлар Союзы халкыннан ике тапкыр артыграк.


Без аэропорттан кунак өенә юнәләбез. Монда бөтенләй башка дөнья. Һәркайда төзелеш: йортлар ремонтлыйлар, юллар төзиләр, әмма техника дигән нәрсәнең әсәре дә юк. Барысын да кул көче белән эшлиләр. Комны да, ташны да, кирпечне дә корзинкаларга төяп, баш түбәләренә куеп яисә көянтәгә асып ташыйлар. Ә кайбер җирләрдә бер рәткә тезелеп басканнар да төзү материалларын кулдан кулга тапшырып, ягъни «конвейерлап» күчерәләр.

Адым саен диярлек миңа инде күптәннән таныш булган велорикшалар очрап тора. Транспортның мондый төрен беренче мәртәбә Пекин, Шанхай, Нанкин урамнарында Кытай Халык Республикасында булган вакытымда күргән идем. Инде менә монда, Делидә дә шул ук рикшалар. Монда да Кытайдагыдан аз түгел икән алар. Юлдашларымның мондый транспортны беренче күрүләре икән, шунлыктан аларга гаҗәп тоела. Хәер, сәерсенмәскә мөмкин дә түгел шул: муенына сөлге аскан чал чәчле, шыр сөяккә калганябык кына карт, ябь-яшь кенә кыз белән егетне утырткан да, җан тиргә батып, велорикша педален әйләндереп бара. Гашыйклар, моңа һич тә исләре китмичә, бик рәхәтләнеп сөйләшеп, көлешеп, сәйранлык кылып баралар... Юк, без нәләшмәгән мондый күренешкә! Әлеге карт, мөгаен, гомере буе шушы рикшасында кеше ташып йөргәндер. Ихтимал, ул бу эшкә күнегеп тә беткәндер инде. Авыр эш, әлбәттә. Карт бик кызганыч. Әмма монысы әле бер хәл. Ә менә велорикша педален көч-хәл белән әйләндереп, юан, симез әфәнделәрне утыртып алып баручы яшь кенә малайлар очраганда йөрәкләр чемердәп, тешләр кысылып китә. Ничек итеп шул сабыйны кызганмыйча утырып бара икән ул капкорсаклар! Җитмәсә авыз ерып, малайны ашыктырып баралар бит әле!

Кызганычка каршы, Дели урамнарында һәм гомумән Һиндстан шәһәрләрендә велорикшалар әлегә төп транспорт булып тора һәм, гадәттә, аңа байлар утырып йөри.

Дөрес, соңгы вакытта моторикшалар [өстенә япма куелган өч көпчәкле мотоцикл] күренгәли башлаган инде башлавын. Алар велорикшаларга караганда тизрәк тә йөри, уңайлырак та. Әмма алар әле аз һәм гади халык өчен бик кыйммәт.






Һиндстан — филләрнең туган иле. Инде берничә йөз еллар буена алар һиндларга гадел хезмәт итеп килә. Йөк тояп йөрүдән тыш, филләрне «шәһәр транспорты» итеп тә файдаланалар.

Делигә килүебезнең икенче көнендә үк Джавахарлал Неру һәм Лал Бахадур Шастри каберләрен карарга бардык. «Кабер» сүзе Һиндстанда башка мәгънәдәрәк йөри. Эш шунда, анда мәетләрне күммиләр, бәлки яндыралар. Мәет янып беткәннән соң, аның көлен елгага сибәләр. Мәрхүм президентларның да мәетләрен шулай ук яндырганнар һәм яндырылган урыннарына мрамор плиталар куйганнар. Һиндстан халкы үз җитәкчеләрен бик нык хөрмәт итә. Аларның каберләренә туктаусыз килеп тора. Биредә һәрвакыт бик күп чәчәкләр була. Без дә президентлар каберенә чәчәк бәйләмнәре куйдык. Шунда мин Лал Бахадур Шастри каберен рәсемгә дә төшереп алдым.

Һиндлар — матур халык. Алар, гадәттә, зифа буйлы, ачык, мөлаем йөзле, йомшак, нәфис хәрәкәтле. Безне бигрәк тә һинд кызларының матурлыгы таңга калдырды. Бу очраклы хәл түгел. Капитал илләрендә ел саен матурлык королевасына конкурс үткәрелеп тора. Махсус билгеләнгән жюри иң матур кызларны сайлап ала һәм шул матурларның матурын җиңүче, ягъни матурлык королевасы дип таба. Минем Австрия, Париж кызларыннан иң матурын күргәнем бар. Аларның рәсемнәрен, бөтен халык күрсен өчен, кеше күп йөри торган урыннарга ябыштырып куялар. Һәм, әйтергә кирәк, ул кызлар чыннан да матур була торганнар иде. Ә менә быел матурлык конкурсында дөнья беренчелеген һинд кызы алган булып чыкты. Алса да гаҗәп түгел, чөнки, инде әйткәнемчә, һинд кызлары һәм гомумән һинд халкы бик матур халык.

Һинд ирләре дә, хатын-кызлары да һәрвакыт үз милли киемнәрен киеп йөриләр. Һиндстанның эссе климатлы ил икәнлеге халыкның киеменнән үк күренеп тора: анда юка, җиңел киемнәр кияләр. Ирләр, кагыйдә буларак, озын ак күлмәктән, чалбар урынына ак материя кисәге бәйләп йөри, ә башларында кызыл, я ак яки сары тостәге чалма уралган була.



Хатын-кызлар сари урап йөри. Сари — биш-алты метр озынлыгындагы материя. Аны хатын-кызлар бик оста итеп урыйлар һәм һәрвакыт бер башын иңнәренә салып куялар. Бай хатын-кызларның сарилары крепдешин яки ефәк, ә фәкыйрьләренеке гади тукыма. Ә сариларның төсләре бик күп төрле — һинд хатын-кызлары чуар бизәкле кием яраталар.



Делидә тормыш һич тә безнекенә охшамаган, барысы да башкача, үзенчә. Соң бер ярым яки ике метрлы кыярларга гаҗәпләнмичә мөмкинмени! Ә алар Дели базарларында гадәти күренеш. Яки менә бу полицейскийлар. Безнең милициягә охшамаган бит алар, киемнәре дә, үз-үзләрен тотышлары да башкача.

Маймыллар да безнең өчен гайре табигый күренеш. Ә алар Дели урамнарында да, өй түбәләрендә дә, агач башларында да бик күп. Хәтта Һиндстан парламенты тирәсендә дә бер көтү маймыл уйнап йөргүен күрдек без. Тагын шунысы кызык: ул маймыллар синең һәр адымыңны бик җентекләп күзәтеп торалар, берәр әйберсңне кулыңнан ычкындыра күрмә, кызык итеп, хәзер алып китәргә генә торалар. Кыскасы, маймыллар тирәсендә саграк булуың хәерле.

Күп кенә маймыллар кулга ияләштерелгән. Хуҗасы аларның «телен» бик яхшы белә. Әгәр хуҗа барабан кагып сигнал бирә икән — маймыллары шундук бик һәвәсләнеп биергә тотыналар яки чынчынлап сугыша башлыйлар. Әгәр инде хуҗа я барабан кагып, янсә сүз белән икенче төрле сигнал бирсә, тегеләр хәзер шып буләлар, әйтерсең, беркайчан да биемәгәннәр дә, сугышмаганнар да. Маймылларны болай уйнату — Дели урамнарында гадәти күренеш, урам сәхнәсенең бер төре.





Яки менә тагын безнең өчен шактый сәер күренеш. Шәһәр мәйданнарының берсенә күп кенә халык җыелган. Мәйдан уртасында озын кара чәчле һинд. Ул шыбыр тиргә баткан. Муенына, хатын-кызларныкы кебек, ниндидер муенсалар аскан. Өстендә һиндларга хас булмаган кара кием. Күрәсең, ул кара озын күлмәк белән киң юбканы башкалардан аерылып торыр өчен кигәндер инде. Шуның өстенә үзе, туктаусыз кычкырып, нидер сөйләнә, кулларын, аякларын болгый-болгый, җирдә яткан ящик тирәсендә бөтерелеп йөри. Аннары ул әлеге ящикны ача һәм, аннан яман ачы сызгырышып, елан башлары килеп чыга. Менә һинд бер еланны кулына ала. Безнең аркалар чымырдап куя. Ә һинд, исе дә китмичә, юан буар еланны үзе ничек тели — шулай бөгә... Соңыннан белдек, еланнар өйрәтүче кеше икән ул.

...Делиның үзәк урамы. Анда төрле машиналар мыж килеп тора. Һәм шул ук урамда... сыерлар. Алар урам читләрендә, хәтта шәһәр мәйданнарында ашыкмыйча гына утлап йөриләр яисә күшәп яталар. Кирәк тапсалар, машиналар кайнап торган урамны да аркылы чыгып китәләр. Светофорда нинди ут януында эшләре юк аларның. Сыерларга транспортның барлык төрләре дә юл бирә, чөнки Һиндстанда да, Непалдагы кебек ук, сыер изге хайван санала. Тар гына тротуарларда берничә сыерның рәттән яткан очракларын бик еш күрергә мөмкин. Алар халыкка комачаулыйлар, әлбәттә. Әмма беркем дә ризасызлык белдерми. Алай гына да түгел, җае чыкканда сыерларга азык та каптырып китәләр әле.





Иске Делине карагяннан соң, Һиндстанда сыерлар тормышы ярлы кешеләрнекенә караганда күп тапкыр әйбәт икән, дип куясың. Әйе, без Делинең иске, ярлы халык яши торган өлешендә дә булдык. Эшчеләр, кустарьлар, вак хезмәтчеләр, ялчылар һәм эшсезләр яши анда. Урамнар шапшак, йортлар төссез, җимерек. Хәтта аларда кешеләр яши икәнлегенә башта ышанасы килми тора. Адым саен фәкыйрьлек, ачлык-ялангачлык күзгә бәрелә. Бөтенләй йортсыз-җирсез кешеләр дә күп. Андыйлар семьялары белән ачык һавада, агач ышыкларында көн күрәләр. Балаларын да урамда коендыралар, керләрен дә шунда юалар, ашарга да шунда пешерәләр, иске-москыларына төренеп, шунда ук төн дә үткәрәләр. Менә бу рәсемдә — шундый семьяларның берсе. Хатыны баласын юатып утыра, ә ире, өстенә нидер ябынып, йоклап ята. Елның коры вакытында болай яшәүгә, ярый, түзәргә дә мөмкиндер әле. Ә яңгырлар башлангач нишли икән соң бу бичараләр! Һиндстанда айлар буена яңгыр яуган чаклар була лабаса!..



Менә шул йортсыз-җирсез кешеләргә карыйсың да, аларның түземлегенә хәйран каласың... Хәер, барысын да бер юлы хәл итеп булмыйдыр шул. Колониализм тарафыннан шушындый коточкыч хәлгә дучар ителгән халыкның тормышын яхшырту өчен, 17 ел вакыт бик аз бит. Киләчәктә һинд халкы да үз дигәненә ирешер, хаклык тантана итәр дип ышанырга кирәк.

Нигә каһәрләмәскә соң колониализмны! Англиянең ике йөз еллык колониаль режимы шушы хәлгә төшергән бит бу халыкны! Ә байлар! Әллә сез алар әлеге иске Делидә яши дип уйлыйсызмы! Юк! Алар хәтта бу якка килеп тә карамыйлар. Алар башка җирдә — яңа Делидә. Анда урамнар да киң һәм туры, йортлар да зур һәм матур. Алар агачлар арасында утыра. Тирә-якларында — чәчәкләр. Элек монда инглизләр яшәгән, ә хәзер Һиндстан байлары яши.

Әгәр синең чәч алдырасың яисә сакал-мыек кырдырасың килә икән, зур көзгеле, йомшак креслолы парикмахерскийлар эзләп йөрмә. Делидә парикмахерскийлар, кагыйдә буларак, урамда. Тузанлы тротуарга бөтен кирәк-яракларын җәеп салып, чәч алдыручыларны яисә сакал-мыек кырдырырга туктаучыларны көтеп утырган парикмахерларны чат саен күрергә була. Теләге булган кешене турыдан-туры әлеге тузанлы тротуарга утырталар да кирәк икән — чәчен ала, кирәксә — сакал-мыегын кыралар икән. Һәм аларга беркем дә комачауламый да, игътибар да итми. Парикмахерлар күп булганлыктан, беркайда да чират юк. Теләсә кайсы оста янына бар да утыр, берсе дә эш хакын кыйммәт алмый.

Без яшәгән кунак өй Дели мәктәпләреннең берсеннән ерак түгел. Һәр көн иртән безнең турыдан, шау-гор килеп, мәктәпкә баручы кызлар һәм малайлар үтеп китә. Ялан аяк, арзан материалдан тегелгән сәләмә киемнән булсалар да, аларның йөзләре ачык, күңелләре күтәренке, чөнки алар мәктәпкә укырга баралар бит! Һәркайсының бер кулында уку әсбаплары салынган ситса букча, икенче кулында — куна тактасы сыманрак итеп ясалган дүрт почмаклы тоткалы такта кисәге.

Һиндстанда балалар, гадәттә, урамда укый. Без башта бу такталарны асларына салып утыралардыр, күрәсең, дип уйлаган идек. Әмма алай булып чыкмады. Әлеге такталар ул балаларга дәфтәр хезмәтен үти икән. Аларга акбур белән язалар да



соңыннан бозалар һәм тагын язалар икән. Кыскасы, «гомерлек» дәфтәрләр икән ул такталар... Сораша торгач, тагын шул да мәгълүм булды: Һиндстанда балалар биш яшьтән үк мәктәпкә йөри башлыйлар икән. Тик шунысы кызганыч, мәктәптә хәллерәк кешеләрнең балалары гына укый, ярлылар баланарын укыта алмыйлар икән әле.



Һиндстанда халык бик күп. Халык саны ягыннан бары тик бер Кытайдан гына калыша ул. Ярлылар яши торган иске Делидә, авыл җирләрендә халык аеруча тыгыз урнашкан. Кая карама — анда бала-чага. Хәер, шулай булмыйча мөмкин дә түгел. Һәр һинд семьясы унар-уникешәр бала үстерә!

Хәзерге вакытта Һиндстанда ачлык хөкем сөрә. Күп кенә семьялар тәүлеккә нибары бер ашау белән яшәргә мәҗбүр. Бу кыенлыкның сәбәбен ил башлыклары халык күплек белән аңлаталар. Шунлыктан хәзер халык саны артуга каршы көрәш алып барыла. Юл читләрендә, шәһәр мәйданнарында «Кечкенә семья — иң бәхетле семья» дип язылган плакатларны һәм шул рухтагы рәсемнәрне бик еш очратасың.

Бу — халык саны артуга каршы көрәшнең бер төре. Шул ук вакытта икенче, тәэсирлерәк төре дә бар. Һиндстанда «Семья планлаштыру пунктлары» оештырылган. Больница характерындагы ул учреждениеләр ярлы халык аеруча тыгыз утырган районнарда урнашкан. Безгә Делидә шундый бер пунктның эше белән танышырга мөмкинлек бирделәр. Ике бүлмә. Шуларның берсендә клиентларга профилактика ясала, врач тарафыннан киңәш бирелә, ә икенчесендә операция ясала икән. Пункт президентының безгә әйтүенә караганда, бу оешма биш ел эчендә ике мең кешегә хезмәт күрсәткән. Монда операция бөтен кешегә дә бушлай ясала. Шул ук президентның әйтүе буенча, Һиндстанда миллионнан артык ирләр һәм хатын-кызлар операция ясаткан икән инде һәм алар киләчәктә нәсел арттырмаячаклар икән. Операциягә яткан кешеләргә хәтта билгеле бер күләмдә акча да бирелә икән. Фәкыйрьлектән һәм ачлыктан котылу өчен Һиндстан хөкүмәте менә шушындый чаралар кулланырга мәҗбүр.



Авыл хуҗалыгының бик түбән дәрәҗәдә торуы да илдәге ачлык сәбәпләренең берсе. Дәрес, Һиндстан җире уңдырышлы, юмарт. Анда елына бер җирдән 3—4 тапкыр уңыш алырга мөмкин. Ләкин, шулай булса да, ул җир үз халкын туйдыра алмый. Крестьяннар, бер караңгыдан икенче караңгыга тикле кырда эшләсәләр дә, ярым ач яшәргә мәҗбүр. Хикмәт шунда, әлеге әйбәт җирләрнең күбесе эре җир биләүчеләр



кулында, ә бик күп крестьяннарның җирләре бөтенләй юк. Җир участогы булган кешеләр дә аны тиешенчә эшкәртә алмый, чөнки аларның берсендә дә авыл хуҗалыгы техникасы юк, алар җирләрен ашлый да алмыйлар. Шунлыктан уңыш бик түбән була. Һиндстанның авыл хуҗалыгы белән танышу өчен, без байтак кына авылларга, тәҗрибә станцияләренә бардык, әмма, кызганычка каршы, анда бер генә трактор да, бер генә комбайн да күрмәдек һәм, гомумән, мотор тавышы ишетмәдек. Бөтен авыл хуҗалыгы эше сыер җигеп яки кул көче белән башкарыла. Болар барысы да әлеге шул Бөек Британия алып барган колониаль изүнең нәтиҗәсе инде.





Һиндстанда безгә һинд туенда да булырга туры килде. Парламент члены, Һиндстан яшьләре оешмасы президенты Хида әфәнде безне үз малаеның туена чакырды. Аның өенә туйга каршы көнне килдек. Хида әфәнденең зур йорты кунаклар белән тулы иде. Алар бүген ял итәләр, җырлар, биюләр өйрәнәләр, кыскасы — туйга әзерләнәләр икән.


Икенче көнне егетне кыз янына озату тантанасы башланды. Ишек алдына төрле алтын әйберләр белән бизәлгән бик матур ак ат чыгардылар. Аңа көмеш подноска салынган ниндидер азык ашаттылар. Аннары ул атка кияү менеп атланды. Унтугыз яшьтә генә булса да, кияү үзен хәйран иркен тота. Ә кунакларның исәбе-хисабы юк! Кияүне кинога һәм фотога төшерүчеләр дә бик күп. Барысы да бу тантаналы минутны эләктереп калырга тырыша. Шулай булмый хәле дә юк — бай малае өйләнә бит! Аннары кияүнең дус һәм туган егетләре, кулларына факеллар тотып, капкага юнәлде. Алар артыннан милли инструментлар оркестры китте. Аннары кияү, аннары кунаклар кузгалды.

...Без кәләш йортында. Монда кунаклар тагын да күбрәк. Барысы да кияүне көтә. Менә, ниһаять, оркестр тавышы ишетелә башлады. Димәк, кияү якынлашып килә. Менә ул кәләш йорты каршына килеп җитте. Атыннан төште. Өйгә үтмәкче булган иде дә барып чыкмады — кәләшнең иптәш кызлары аның юлына каршы төштеләр; ниндидер җыр җырлыйлар, кияүдән нәрсәдер сорыйлар, әмма кияү аларны тыңларга да теләми, бөҗраны ерып, кәләше янына омтыла. Тик аның юлы тагын бүленә — кәләшнең әти-әниләре тоткарлый. Алар кияүдән нидер сорыйлар. Күрәсең, бер-берегезне хөрмәт итәрсезме, турылыклы булырсызмы, ди торганнардыр.

Аннары туй йолалары башланды. Кияүгә су, дөге сиптеләр, танып та булмаслык хәлгә китергәнче төрле буяулар белән битен буядылар һәм муенына чәчәк бәйләме асып куйдылар. Бары тик шуннан соң гына кәләшне кияү янына алып килделәр. Кәләшнең битенә пәрәнҗә сыман итеп ак ефәк япма капланган. Аннары кияү белән кәләш үзләре өчен әзерләнгән бүлмәгә кереп киттеләр, ә кунаклар (ике йөзгә якын кеше) сый-хөрмәт куелган өстәлләр янына таралыша башлады. Әле яз башы гына булуга карамастан, кып-кызыл помидорлар, зур-зур кыярлар һәм бананнар белән өстәлләр тулган. Болар барысы да бу елгы уңыш.

Өстәлләр йортның ишек алдына куелган. Әмма алар тирәсендә бер генә урындык та юк. Һәркем басып ашый. Берәүне дә кыстап-сыйлап йөрмиләр. Нәрсә телисең, бар да үзеңә кирәген алып аша...

Кыскасы, ике көн кунак булдык без ул туйда. Һәм милли һинд ризыкларын да ашадык. Коймак ашый башлап, авызларын яндырып алучыларыбыз да булды — һиндлар коймакка күп итеп борыч сибеп пешерәләр икән. Тагын шунысын да әйтеп китәргә кирәк: ике көн кунак булып, ни ир, ни хатын-кыз затыннан хәмер эчкән кешене күрмәдек без анда. Хәтта шундый зур туйда да булмый икән ул нәрсә. Һиндстанда «коры закон» икән. Әмма аңа карап кына туйның яме китмәде. Һиндларның бик күңелле, музыкаль халык икәнлегенә без шунда тагын бер тапкыр ышандык. Сәгатьләр буена җырлыйлар, биилөр алар. Туйда олылар белән бергә үк бала-чагалар да күңел ача икән.



Һиндстанның кайсы гына шәһәренә барсаң да, һинд осталары кулы белән эшләнгән архитектура корылмаларына сокланмыйча мөмкин түгел. Моннан берничә йөз еллар элек эшләнгән булсалар да, алар әле яңа гына җиткерелгәндәй мәһабәт күренәләр.

Берниндн төзү техникасы булмаган заманнарда салынып, әкияттәгедәй матур бизәлгән бу храмнарны ничек эшли алды икән ул һинд осталары! Аларның һәр бизәгендә халыкның эш сөючәнлеге, акылы чагылып тора.

Менә без Кутб-Минар манарасы янында. Делидән 20 километр чамасы ераклыкта торган бу манара 13—14 гасырларда ук ясалган. 85 метр озынлыктагы ул манара төрле төстәге ташлардан салынган. Ә стеналарында зур гарәп хәрефләре белән язулар язылган, күрәсең, коръәннән алынган сүзләрдер инде алар. Бу манара салынганга инде күпме вакыт үткән, күпме җил искән, күпме яңгыр яуган һәм аны кояш күпме кыздырган, әмма ул әле яңа гына эшләнеп беткәндәй матур булып балкып тора.

Манара эченә бормалы баскыч ясалган. Әгәр менә калсаң, утырып ял итәр өчен балконнары да бар. Башың әйләнмәсә, манараның очына ук менәргә мөмкин. Әмма аның очына менеп җитүчеләр, менеп җитеп тә, курыкмыйча җиргә караучылар, ихтимал, сирәктер. Һәрхәлдә, безнең яшьләр делегациясеннән берәүнең дә моңа кодрәте җитмәде. Аны төзүчеләр шул тикле биектә ничек итеп шул балконнарны һәм бизәкләрне эшләделәр икән! Җитмәсә, Кутб-Минар манарасы берниндн фундаментсыз эшләнгән диләр әле. Моннан биш йөз еллар элек шушындый могҗизалар тудырган һинд халкының әле һаман да туйганчы ашарлык ризыгы булмавы гына бик кызганыч.



Һиндстанның борынгы шәһәрләреннән берсе булган Лакхнаудагы архитектура корылмалары да хәйранга калдырды безне. Мөселман мәчетләрендәге кебек оста итеп эшләнгән мәчет манаралары, белмим, башка җирдә бармы икән!

Әйе, Һиндстанда архитектура истәлекләре бик күп. Әмма аларның иң яхшысы, ихтимал, Агр шәһәрендәге бөтен дөньяга билгеле булган Таҗ-Махалдыр. Юк, аның бөтен матурлыгын, күңелгә ничек тәэсир итүен сөйләп яки язып кына аңлату һич тә мөмкин түгел. Аны үз күзең белән күрергә кирәк. Таҗ-Махалның бөтен матурлыгын шунда гына тоярга мөмкин.



Унҗиденче гасырда Таҗ-Махал мавзолеен 20000 оста төзегән. Аны төзүгә 20 елдан артык вакыт киткән. Сөйләүләргә караганда, аның төзелү тарихы менә болай.

Заманында Һиндстанда Шаһ-Джахан исемле патша булган. Ул Мөмтаз исемле фарси кызына гашыйк булган һәм шуңа өйләнгән. Соңыннан алар бер-берен яратышып унсигез ел бергә яшәгәннәр. Шул унсигез ел эчендә Мөмтаз ундүрт бала тапкан. Аннары ул авырып киткән һәм үләр алдыннан иренә, ягъни Шаһ-Джаханга, өч васыять әйтеп калдырган: өйләнмәскә, балаларын укытырга һәм дөньяда тиңе булмаган сарай-мавзолей төзетергә кушкан.

Менә шулай ак мәрмәрдән әлеге Таҗ-Махал барлыкка килгән. Мәрмәр симфония дип атыйлар аны. Ә һиндләр исә: «Таҗ-Махалны күрмәгән кеше — Һиндстанда да булмаган», — дип әйтәләр.

Әйтерлекләре дә бар шул. 75 метр биеклегендәге ул мәһабәт корылманың матурлыгы әйтеп кенә бетерә торган түгел. Мавзолей бинасы өстендәге гөмбәзе генә дә ни тора аның: үзе шундый зур, ә үзе шундый җиңел булып тоела, әйтерсең, ул һава тутырылган зур шар һәм менә-менә очып китәр төсле. Гөмбәзе генә түгел, бөтенләе белән шундый нәфис һәм җиңел булып тоела ул. Ихтимал, стеналары ап-ак мәрмәрдән салынган булганга шулайдыр. Аның стеналарындагы мәрмәргә ювелирларча төшерелгән бизәкләрнең төгәллегенә кем генә хәйран калмас икән! Таҗ-Махалның дүрт ягында да, сакчы каланчалары сыман булып, дүрт зифа манара басып тора. Хәзер ул манараларга менәргә рөхсәт ителми: үз исемнәрен Таҗ-Махал белән бәйләп калдырыр өчен, ул манаралардан сикереп үлүчеләр булгалаган, ди.

Мавзолей каршында зур гына бассейн. Анда фонтаннар эшләнгән. Җилсез көннәрдә Таҗ-Махал шәүләсе, нигезеннән түбәсенә тикле, шул бассейнда чагылып-күренеп тора.

Таҗ-Махалның эче тып-тын. Тавыш чыкмасын өчен, анда кергәндә аяк киемен салып керәсең. Мавзолейның аскы катында ике табут тора. Алар шулай ук ак мәрмәрдән ясалган. Берсендә — Мөмтаз, икенчесендә Шаһ-Джахан үзе күмелгән.

— Таҗ-Махалны гомеремдә бер генә тапкыр булса да күреп калырга хыялланмаган һинд юктыр Һиндстанда, — диде безне мавзолейга алып барган шофер.

Әйе, сокланып карарлык нәрсәләр күп шул анда! Шундый искиткеч сарайлар төзегән һинд халкын бөек халык дип атамыйча мөмкинме соң! Юк, бу халык гел болай ярлы яшәмәс. Колониализм богавы гына хәлен алган аның. Ул богау өзелде инде. Күп тә үтмәс, Һиндстан тагын бай, алдынгы илгә әйләнер.

• • •



# *Балаларга укыгыз*

*Галимҗан Латыйп*

## Балыкчылар җылым тарта

Балыкчылар җылым тарта
Елгада.
Җыр биредә тавыш-тынсыз
Җырлана.

Сагаялар, балык сизгер,
Качар, дип.
Буш кул белән кайтулары
Начар бит!

Җылым бара әкрен генә,
Тын гына.
Кайчак аңа бака кабыгы
Тыгыла.



Ә кай вакыт җылым куя
Калтырап.
Балыкчылар калмый аңа
Аптырап.

Сизеп тора балыкчының
Куллары:
— Керә, — ди ул, — балыкларның
Зурлары.

Ярга чыккач, әйткән сүзләр
Хак була.
Йөзләр якты, ә күңелләр
Шат була.

Сайлый җылым гел үзенә
Кирәген.
Оста йөртә су астында
Иләген.

Вак-төякне әләктерми,
Китсен, ди.
Алар әле, балык булып
Җитсен, ди.

Балыкчылар җылым тарта
Елгада.
Җыр бу чакта тавыш-тынсыз
Җырлана.

## Үз дигәнен итә ул

— Мин дә шуам чаңгыда, — дип,
Тик син аны ал гына, — дип,
Безнең Сәет ялына
Үзенең абыйларына.

— Сиңа әле биш кенә, — дип,
Шаулама, син кечкенә, — дип,
Шаярталар Сәетне:
— Синең кечкенә булуга
Әллә безме гаепле!

Сәет елап та карый,
Биеп, җырлап та карый.
Тик чаңгыны алмыйлар,
Менә нинди абыйлар...

Сәет тапкыр малай ул,
Иске чана табанын
Ала да чаңгы итә,
Һәм тауга менеп китә...



Бер сөртенә, бер ава,
Як-якка карап ала.
Ә шулай да ярыйсы,
Эш һаман алга бара.

Егылса да еламый:
— Алай гына була, — ди.
Кайчак егылмыйча да
Ярыйсы ук шугалый.

Менә хәзер абыйлар
Син кечкенә, димәсләр.
Инде чаңгы турында
Ныклабрак сөйләшәм!

## Безнең урам чатында

Безгә бик тә якында,
Безнең урам чатында.
Морожныйлар саталар.
Туктыйлар анда абыйлар,
Әбиләр һәм апалар.

Малай-шалай муены
Гел шул якка борыла.
Колак салмый булмый шул,
Сатучының «җырына».

Морожныйлар,
Морожныйлар
Шикәр генә,
Бал гына.
Тик син аны
Берәр тапкыр
Татып кара,
Ал гына.
Шоколадлы,
Йөземле,
Карлыганлы,
Җиләкле.
Таза булып
Үсим дисәң,
Ул сиңа бик
Кирәкле!



Әнидән акча сорыйбыз,
Әтидән дә сорыйбыз
Сорап-сорап бирмәсәләр,
Юри генә елыйбыз.

Аннан барыбер бирәләр,
Бирмичә калалмыйлар.
Үзең дә морожный сыман
Туңмасаң ярар, диләр.

## Бала белән ата

— Әти сиңа
Бер сүзем бар,
Тыңла әле.
Ләкин кире
Җавап бирә
Күрмә, яме!

— Ярар, кызым,
Ни сүзең бар,
Әйтеп кара.
Лаек булса
Ярый ла ул
Игътибарга.

— Әй, әтием,
Ничек кенә
Лаек әле.
Миңа бер шәп
Пианино
Алыйк әле!

И уйнар да
Идем көйнең
Төрлеләрен.
Тыңлап туймас
Моңлыларын,
Серлеләрен.

— Алмыйммы соң!
Алыр идем
Кызым аны.
Мин үзем дә
Бик яратам
Музыканы.

Тик каралыр,
Клавишлары
Ап-ак аның.
Кулларың бит
Чиста түгел
Кызым-җаным.

— Акларына
Тимәс, әти,
Куллар минем.
Каралары
Белән генә
Уйнармын мин.

• • •

# яңа китаплар

## ҺӘРКЕМНЕҢ КҮҢЕЛЕНДӘ

*Шигырьләр, хикәяләр һәм истәлекләр җыентыгы*

*Бәясе 87 тиен*

Барлык хезмәт ияләренең бөек юлбашчысы Владимир Ильич Ленин һәркемнең күңелендә саклана. Аның тормышы һәм эшчәнлеге хакында бик күп әдәбият һәм сәнгать әсәрләре иҗат ителә, җырлар җырлана. Алар барысы да даһи Ильичка зур ихтирам һәм кайнар мәхәббәт хисләре белән сугарылган.




Октябрьның 50 еллыгына һәм В. И. Ленинның тууына 100 ел тулуга багышлап чыгарылган бу җыентыкта күп милләтле совет әдәбияты вәкилләренең сөекле юлбашчының якты образын чагылдырган, аның тормышыннан һәм эшчәнлегеннән аерым эпизодларны сурәтләгән әсәрләре басылган.

## ТОРМЫШ МАТУР ДУСЛАР БЕЛӘН

*Татар язучыларының шигырь һәм хикәяләре тупланган җыентык*

Бәясе 72 тиен

СССР халыкларының мәңгелек бердәм дуслыгы — Октябрь социалистик революциясе биргән тиңсез зур казанышларның берсе. «Тормыш матур дуслар белән» исемле бу җыентыкта язучыларыбыздан Г. Тукай, М. Гафури, М. Җәлил, К. Нәҗми, Г. Ибраһимов, Ш. Камал, Г. Гали, Һ. Такташ, Ә. Фәйзи, Г. Кутуй, М. Максуд, Ф. Кәрим,




А. Шамов, Ә. Еники, Ф. Хөсни, Г. Әпсәләмов, Ш. Галиев, З. Мансур, М. Садри, З. Нури, Г. Хуҗиев, Х. Туфан, С. Хәким, Ш. Маннур, И. Юзеев, Г. Ахунов, Ш. Мөдәррис, Л. Ихсанова, С. Сабиров, Ә. Маликов, Р. Төхфәтуллин, Н. Дәүли, Г. Минский, Ә. Давыдов, М. Хәсәнов, М. Хөсәен, Б. Камаловларның СССР халыклары дуслыгын, бөтен дөнья хезмәт иясе халыкларының интернациональ дуслыгын чагылдырып иҗат ителгән әсәрләре тупланган.

**Ләбибә Ихсанова**

## ТАУ ЧӘЧӘГЕ

*Хикәяләр җыентыгы*

Бәясе 20 тиен

Күп санлы хикәяләр һәм повестьлар авторы язучы Ләбибә Ихсанованың бу җыентыгында басылып чыккан хикәяләре (алар барысы унҗиде) нигездә лирик планда язылган



әсәрләр. Лирик геройларының хис-тойгылары аша автор безнең чор кешеләренең — хезмәт ияләренең рухи байлыгын, иҗади омтылышларын, шатлык һәм кайгыларын җанлы картиналарда бик мавыктыргыч итеп тасвирлаган.

**Әбрар Шәмин**

## САГЫНДЫРГАН СУКМАКЛАР

*Хикәяләр җыентыгы*

Бәясе 25 тиен

Әбрар Шәминнең бу җыентыгында соңгы елларда язган һәм башлыча тыныч шартлардагы Совет



Армиясе тормышын сурәтләгән яңа хикәяләре басылган. Җылы хис һәм оптимистик рух белән сугарылган бу хикәяләрендә автор истә калырлык матур-матур образлар тудыруга ирешкән.

**Габдрахман Минский**

**НЕЗАБЫВАЕМЫЙ РАССВЕТ**

**(Онытылмас таң)**

*Хикәяләр җыентыгы*

Бәясе 11 тиен

Язучы Габдрахман Минскийның Мәскәүдә «Советская Россия» нәшриятында рус телендә басылып чыккан бу җыентыгына төрле елларда язылган һәм тормышның төрле якларын чагылдырган җиде хикәясе урнаштырылган. Барлык әсәрләренең дә сюжеты киеренке, сурәтләнгән вакыйгалары мавыктыргыч.




**Сафа Сабиров**

**ПРИБОЙ**

*Хикәяләр җыентыгы*

Рус телендә

Бәясе 25 тиен

Сафа Сабировның Татарстан китап нәшрияты бастырып чыгарган бу җыентыгына унсигез хикәя урнаштырылган. Ул хикәяләр барысы да елгачылар — капитаннар, механиклар һәм порт эшчеләре тормышын, аларның омтылышлары, уй-хисләрен сурәтләүгә багышланган.



**Мансур Зәйнуллин**

**КҮНЕЛДӘН ЕЛМАЮЛАР**

*Хикәяләр җыентыгы*

Бәясе 7 тиен

«Күнелдән елмаюлар» — яшь язучы Мансур Зәйнуллинның беренче китабы. Аның бу җыентыгына юмористик хикәяләр урнаштырылган. Аларда автор, җиңелчә елмаю аша, кешеләрдә булган кимчелекләрдән: мактанчыклык, фикереңне туры әйтергә йөрәк җитмәү, тәнкыйтьтән курку, «кәкре куллылык» кебек тискәре якларны фаш итә.




*Хөрмәтле укучылар!*

Бу китапларны һәм, гомумән, татар язучылары китапларын түбәндәге адрес белән хат язып, соратып алдырырга мөмкин:
г. Казань, ул. Баумана 19, Таткниготорг, отдел «Книга-почтой».
Редакция укучыларга китап җибәрү белән шөгыльләнми.



**сатира һәм юмор**

*Шәукәт Галиев*

# ӘЗ-МӘЗ МӘЗӘК

*(Көен дәфтәреннән)*

## Алга китеш

Элек ул иртәнге зарядканы кырын төшеп радиодан гына тыңлап яткан. Хәзер алай эшләми. Телевизордан карый...

## Муллык

Камадан тоткан балыклардан нефть тәме килә. Камада үскән казлардан нефть тәме килә. Камада йөзгән кызларның иреннәреннән дә нефть тәме килә!..

## Әйтте...

Агайның эте чирләгән. Күршесе карый да:
— Бу эт кеше булмас инде, үләр... — ди.

## Гадәт

Кибет артына посып кына, як-якка каранып, өч карт кефир эчә. Пенсиягә чыккан милиционер күреп: «Ярамый!» — дип кисәтеп үтә...

## Беркатлы

Берәү ашханәдән чыкканда мөдирне күргән дә исе киткән:
— Ничек шулкадәр симергән бу мөдир — ашханәсендә бер дә рәтле ашамлык юк лабаса?! — ди икән.

## Тәүге адымнар

Исерек егетне иптәшләре култыклап алып кайталар. Бер бала әнисеннән сорый:
— Теге абыйны йөрергә өйрәтәләрме, әни?

## Күптән икән

Бер малай үзенең шигырьләрен укыта.
— Кайчаннан бирле язасың? — дим.
— Февральдән бирле ук инде!
— Ә-ә, шактыйдан икән, — дим мин дә сузып кына. — Үтә бит гомер дигәнең — кай арада март та җиткән!..

## Сайлаган

— Беренче хатыным бер дә сөйләшми иде, аердым.
— Бусы ничек?
— Бусы гел үзе сөйли, миңа авыз да ачтырмый...

## Игътибарлы егетләр

Бер әби трамвайда шатланып сөйләп бара:
— Бар бит яхшы кешеләр! Ике егет култыклап меңгезде, шушында китереп утырттылар. Һай рәхмәт!
Билет алырга дип кесәсенә тыгылса — акчасыннан җилләр искән...

## Чара

— Растрата ясаган сатучыны нишләттегез?
— Бәясе төшкән товарлар сатарга куйдык.

## Ихтыярлы кеше

— Тәмәкене ташладым.
— Бик әйбәт!
— Аракыны ташладым.
— Бик әйбәт!
— Хатынны да ташладым.
— Бик әй... Ах, юньсез!

● ● ●

*Газиз Мөхәммәтшин*

# ГАБДЕЛХӘЙНЕҢ БӘХЕТСЕЗ КӨНЕ

*Хикәя*

Уразай авылы тракторчысы Габделхәй Сәгыйтов төрле ырым-шырымнарга һич ышана торган кеше түгел иде. Беренчедән, ул әле асыл егет. Быел көз өйләнәм, дип, йөрәк ярсытып йөргән егет «әбием әкиятләре»нә ничек ышансын! Икенчедән, ул сугыштан соң гына туган, капитализмны тарих дәреслеге буенча гына белә. Димәк, аңа «капитализм калдыгы» дигән койрык бик теләсә дә иярә алмый.

Ә шулай да көннәрдән бер көнне аңа шул койрык очы тәки тиеп китә язды бит.

Казанда булды бу хәл.

Габделхәй ул көнне иртән «Волга» гостиницасының тимер юл ягындагы кечерәк кенә бүлмәсендә паровоз тавышыннан уянып китте. Уянып та китте, күзләрен ачканчы ук елмаеп та җибәрде. Аның күршесе — Шәргыя исемле кызны үземә каратмыйча кырынмыйм, дип ант иткән бакенбардлы егет — моны күргәч үзе дә елмайды.

— Исеңә төштеме? — дип сорады.

Габделхәй күзләрен ачып карады.

— Төште шул.

— Туегыз кайчан?

— Октябрь бәйрәмендә.

— Тагын бер айдан кыз куенына керәсең икән.

— Керә-әм!

— Бәхетле бала! — дип көрсенде күршесе.

— Бәхетле-е! — диде Габделхәй.

Бераз сүзсез тордылар. Габделхәй кинәт кымырҗынып:

— Кайсы кашым тарта? — дип сорады.

— Уңы, — диде бакенбардлы егет.

— Белмәдең. Сулы тартты. Тукта, хәзер кайсы колагым чыңлый?

— Сулы.

Габделхәй көлде һәм торып утырды.

— Тагын белмәдең. Уңы чыңлады. Күрәзә чыкмый синнән.

Бакенбард иясе ишек төбендә физзарядка ясый иде. Туктады да көзгедән үзенең елкылдап торган җирән сакалын җентекләп карый-карый:

— Күрәзә булмасам да әйтәм: бүген юлларың уңмас, парин, — диде. — Шушы исәр әйткән иде диярсең.

— Сарман егетләре бөтенесе дә синең шикелле күрәзәме?
— Һе! — диде егет, «һе»сенә серле бер мәгънә бирергә тырышып.
— Болар, малай, хәерлегә түгел.
— Чалбар балагыннан да курка башласаң, — диде Габделхәй һәм сөлге-сабын алып юынырга чыгып китте.

Бакенбардлы егет аның артыннан сакалын селкетә-селкетә кычкырып көлеп калды.

— Шаярам гына. Ышана күрмә. Мин шулай шаян кеше инде.

Ышанды, ди! Аллага шөкер, өйләнү нияте белән йөри, бала түгел. Эшендә дә кабык арбадан төшеп калмаган. Менә әле үзен республика активы җыелышына алып килделәр. Кичә министрлар белән бергәләп обкомның конференц-залында утырды, хөкүмәт эшләрен тикшерде. Хәзер юыныр-кырыныр да канатланып Фәтлиясе янына очар. Фәтлия кыска сроклы бухгалтерлар курсында укый. Ноябрь кергәч кайта. Ул кайткач бер атнадан туй. Егетең, бакенбард әйтмешли, унбер яшьтән бирле сөешеп йөргән җанкисәк кәләшенең куенына керә. Төрле колак чыңлаулар, чалбар балаклары һәм шуның ише нәрсәләр аның бәхетен урлый аламыни! Ю-ук, хәлләреннән килми андый эш!..




Габделхәй юынып керде. Бакенбард юк иде инде, үз йомышларын юлларга каядыр чыгып киткән иде. Габделхәй кырынырга әзерләнә башлады. Ике яклы түгәрәк көзгесен сулы чәйнеккә терәп кенә куйган иде, көзге, түгәрәк әйбер тәгәрәргә тиеш, дигәнне исенә төшерде, ахры, шома клеенка өстеннән тәгәрәп китте дә идәнгә төшеп чәлпәрәмә ватылды. Габделхәй аның кечкенә йолдызчыклар шикелле сибелеп яткан вак-вак кисәкләренә, гамәлдән чыккан каурый кысасына карагач, кинәт куршесен исенә төшерде. Хәзер ул ни әйтер иде икән? Мөгаен, берәр бәхетсезлеккә юрар иде. Габделхәй елмаерга итте, ләкин ерыла башлаган иреннәрен тиз генә җыеп куйды. Тукта, елмаерга ашыкма, тәти егет, нишләп сина гел кире килеп тора әле бүген, нишләп уңае да очрап куймый, дип уйлады.

«Һәй, ерунда,— диде соңыннан. — ерундалар белән маташыр заманмы!» Фәтлия-җанашы янына барасы, уй-киңәш итәсе бар, кыскасы, бу көннең минуты кадерле.

Көзгесез генә, ияк-битен бармак белән капшап кына кырынырга ниятләгән иде дә — ниятеннән кире кайтты. Дөрестән дә, көне нинди! Мондый көндә бармак белән генә капшау һич ярамый!..

Каршы бүлмәдән көзге алып чыгып кырынгач, хушбуй сөртенгәч, капкаларга кирәк, дип урамга чыгып китте.

Урам аны салкын яңгыр тамчылары белән каршылады. Ләкин күк йөзе болытлы, аяк асты пычрак булса да, Габделхәйнең моңа кәефе китмәде. Август, сентябрь айлары заказ биргәндәй искиткеч коры һәм җылы килде. Печәннәр кибәнгә, ашлыклар амбарга вакытында керде. Октябрь яңгыры куркытмый инде, туйганчы яусын, әйдә...



Габделхәй болоньи плащының төймәләрен каптырды, ботинкасы өстеннән кигелгән өр-яңа галошларын ялык-йолык иттереп базарга китте.

Хәер, «китте» дип раслау, йомшак итеп әйткәндә, ялган булыр. Вокзал чатында аның яңа галошлары, юеш асфальтка берекәндәй, шып туктады: урам аша, Габделхәйнең юлын аркылы кисеп, халыкка һәм трамвай-машиналарга бөтенләй илтифат итмичә, йодрык чаклы гына песи баласы чыгып килә иде. Габделхәй аңа соры күзләрен киереп карап торды. Чөнки бу песи баласы баштанаяк чем-кара, ә мыеклары, киресенчә, ап-ак иде Габделхәй мондый җанварны гомерендә беренче мәртәбә күрә иде. Мыегы ак булса да, төсе чем-кара! Шул чем-кара нәрсә, суга баскан сыен нәни аякларын күтәреп селки-селки, аның юлын аркылы чыгып бара!

— Тьфү! — диде Габделхәй. — Трамвай таптар, дип тә курыкмый, явыз. Ә нинди олы кешеләрне куркыта. Куркыта?!. Минеме?.. Уразай авылының мактаулы тракторчысынмы? Куркытмый торсын әле! Фәтлиягә сөйләргә көлке сүз булыр — шул! Менә, чәчәк кенә табарга да. Монда килгәч, шәһәр кызлары кебек, чәчәккә ихласланды үзе. Чәчәкләре дә нинди әле! Аристократ чәчәкләр — ал гладиолус белән тюльпан! Тормышка чыгып сыер сава, ипи сала башласаң һәм... һәм... Эһем... бала-чагаларың да итәгеңә асылынса, чәчәгең коелыр, чәчәк кайгысы калмас, мөгаен. Ә хәзер, что же, алырга кирәк, сөенсен...

Габделхәй чәчәк базарында озак тормады. Күзгә чәчәкләр белән дөнья тулса да, ал гладиолус белән тюльпан очратмады. Дөрес, алтын тешле сөйкемле генә ханымда гладиолуслар бар иде, тик алар юка бәрхет шикелле матур, купшы тажлы кара гладиолуслар иде. Ә Фәтлиягә ал кирәк, алын кайдан алырга?..

Базардан чыгып барганда бер апа аңа буялган әтәч койрыклары тәкъдим итте. Габделхәй кулын гына селтәде. Җиденче троллейбуска утырды да Арча кырына менеп китте...

Фәтлияләрнең барагына, аэропорт артындагы кирпеч заводларын узып, чокыр-чакырлар уртасына — җәһәннәм тишегенә барасы. Габделхәй элек килгәч тә адашып йөргән иде. Бу баруында толь түбәле озын баракны бөтенләй тапмады. Хәтта аның урынын да чамалый алмады. Таныш та, түгел дә иде бу ялан-япан җирләр. Табигать ярган ерганаклары гына җитмәгән, хәзер инде кешеләр дә яңа чокырлар казып бетергәннәр һәм, Әбугалисина тылсымы белән дигәндәй, бишәр катлы әллә ничә өй салып куярга да өлгергәннәр иде.

Өзлексез пыскаклап торган күзгә яңгырлар җебетеп кесәл иткән балчык өемнәренә карап, Габделхәй, монда күчкән кешеләрнең барысы да итек киеп йөри микәнни, дип аптырап торды. Аннан соң, ял көнс булгач, Фәтлияләрнең мәктәбендә дә вахтердан бүтән адәм юктыр югын, ләкин яңа тулай торакның кайда икәнен белсә ул гына белер, дип кайтыр юлга чыкты. Килгәндә юк иде, кайтканда ничек пәйда булгандыр — тая-тая йөз адым атларга өлгермәде, болганчык сулы киң генә канауга килеп бүленде. Сакланып кына канау аша салынган шома



һәм сыгылмалы басмага басты. Басты да тагын гаҗәпкә калды: бер аягында яңа галошы юк иде. Габделхәй тирә-ягын, аяк астын тикшереп чыкты — галош-мазар күренмәде. Мәте суырып алгандыр, хәзер аны кайдан табасың, сыңар галошы тагын нигә ярый, дип пошынып уйлады да, исән галошын аягыннан салып канауга ташлады. Галош, кер дә тияргә өлгермәгән кызыл эчен ялтыратып көлә-көлә, көймә шикелле салмак кына агып китте. Габделхәй ул борылышта күздән югалганчы карап калды һәм, кызганычка каршы, шунда гына «югалган» галошын күреп алды. Ул сыгылмалы такта башына гына кысылып торган икән. Габделхәй пышылдап кына галошның анасын исенә төшереп алды да бу сыңарын да тегесе артыннан агызып җибәрде. «Бар, иптәшеңне эзләп алып кайт, собака!» — диде. Төкерде дә яңа ботинкасы белән пычракның нәкъ күзенә баса-баса автобус тукталышына китте...

Ул Куйбышев мәйданына эттәй талчыгып, бүредәй ачыгып, атом бомбасы ясап та шушы эчпошыргыч янгырны туктату эмәлен тапмаган галимнәрне әрләп көчкә кайтып житте. Бетмәс монда разный Фәтлияләр, тамак ялгарга кирәк, дип «Ашханә»гә кереп китте. Кассага чираты җитә башлагач, куен кесәсеннән бер берлек белән бер өчлек чыгарды. Бер сум түләп кулына чеклар алгач, залга үтим дип борылган гына иде, нәкъ үзенең ике ботинкасы арасында бөгәрләнеп яткан бер өчлекне күрде. Аны иелеп алды да үзеннән артта басып торган чибәр кызга сузды.

— Акчагызны төшермәдегезме? Идәндә ята иде.

Кыз ридикюлен ачып карады да елмаеп акчаны алды.

— Ай, рәхмәт сезгә, бик зур рәхмәт сезгә! — диде.

— Ярый, ярый, ничего, — диде егет, зәңгәр күзләрнең җылы карашы астында шәмдәй эреп.



Яңа пластинкалар алу нияте белән «Мелодия» кибетенә сугылгач кына зәңгәр күзле кызга үз өчлеген алып биргәнен белде. Кибеттән кәефе кырылып һәм пошаманга төшеп чыкты. Аның инде троллейбуска утырырлык та акчасы калмаган иде. Болак күперен чыккач, Киров урамы буйлап сукранасукрана гостиницага кайтып китте. Юл буе кем беләндер бәхәсләшеп, очына чыгарга тырышып кайтты. Әллә дөньяда чынлап язмыш дигән нәрсә бармы? Бакенбардның юравы бүген ник гел килеп тора? Юлы, дөрестән дә, уңмады бит! Юри эшләсәң дә болай ук булмас. Вахтер хатынны кара, ни кылана! Яңа тулай торакның адресын әй-

тегез әле, зинһар, дигәч, ишеген дә ачып тормады. «Белмим, бер нәрсә дә белмим», дип пыяла аркылы гына кычкырып салды. Аннан тагын бәрәнге белән селедкасына ябышты да кабат башын күтәрмәде. Бүген Фәтлияне күрүләрдән өмет өзелде. Миллион халык яшәгән шәһәрнең кай урыныннан, кайсы йортыннан эзлисең аны! Ә галош? Ә чәчәк? Ә акча? Уңмады юл, уңмады, уңмады, уңмады. Ну, песи, тагын күземә чалынсаң, мыегыңнан тотып канауга чумдырмый калмам. Икенче вакыт, кәләше белән күрешергә ашыккан егетләрнең юлын кисү түгел — биш чакрымнан урап үтәрсең...

Шулай, ахры, дөньяда әллә ниләр бар, ахры. Бик белдекләләнеп борын чөеп йөрергә ярамый. Белмәстәйне барыбер белеп булмый. Дөньяда телепатия, магнетизм дигән гаҗәеп күренешләр бармы — бар. Аңа китсә, алласы да бардыр әле аның. Юк, димә. Ята торгандыр әле болыт артында лейкасыннан җиргә су сиптереп. «Юк ул анда, булса — Гагарин күрер иде», имеш. Гагариннардан да качып кала алмагач, алла була димени ул! Кодрәт иясе түгел — пүчтәк була.

Күкләр бик иркен, йолдызлар бик күп, галәмнәрнең иге-чиге юк. Безнең серле җиребез бер галактикада — бер тузан, ком бөртеге. Без — шул ком бөртегендә шатланып һәм кайгырып яшәүче җан ияләре. Уйламаган чакта гына бөтенесе аңлаешлы, гади кебек, уйлый башласаң, бала йоннарың кабарып, күзләр тонарлык.

Менә шуларны белә торып, язмыш юк, дип кычкыр син! Җитмәсә, авылларының исеме дә Уразай. Ураза, ураза ае дигән мәгънәсе әллә кайдан кычкырып тора түгелме? Монда да кеше акылы ирешмәслек сер булуы бик мөмкин. Сарманның бакенбардлы егетеннән көлгән булдым, тиле. Клоунмы әллә ул көләргә! Көлке көлә килер, артыннан куа килер, дигәннәрме — дигәннәр. Куа килдеме арттан — килде, каптырып та алдымы чабудан — алды. Казанда поезд гөжләгәнен тыңлап ят, үзен тагын бер айдан җылы куенына керәсе кәләшең белән кәлимә сүз сөйләшә алма, нурлы йөзенә карап куана алма. Тьфү! Әәәәй, бу көннең ямансулыгы! Әәәәй, күңелләрнең елавы, йөрәкләрнең сыкравы! Гомерендә иң бәхетсез көне бу Габделхәйнең! Ну, песи, алла сакласын, очрый гына күрмә...

Габделхәй шундый күңелсез уйлар белән гостиницага кайтып житте, лифт белән өскә күтәрелде, бүлмәсенә керде һәм йөрәге кысылып, ишек төбендә туктап калды: тәрәзә янында аның сөекле Фәтлиясе утыра иде. Габделхәйне күргәч, ул, язгы кояш шикелле балкып, урыныннан торды. Ике куллап урындык аркасына тотынды да шат кызарып:

— Кайттыңмы, Габделхәй? Мин сине көтеп утыра идем... Исәнме! — диде.

Егет аңа өнемме бу, төшемме, дип иссез калып карап торды да, исенә килгәч, куанычыннан елмаеп:

— Исәнме, Фәтлия! Минем монда икәнемне кайдан белдең? Мин бит сиңа сюрприз ясарга теләгән идем, — диде.

— Сезне кичә телевизордан күрсәттеләр ич, — диде кыз.

Бер-берсеннән күзләрен ала алмыйча сүзсез калдылар. Габделхәй, йомыш белән кергән кешедәй, өстен дә салырга онытып, ишек төбендә тик торды. Фәтлия эскәтерне сыйпап куйды, тәрәзәдән карады, аннан кинәт кенә исенә төшереп ридикюленнән капрон галстук алды. Серле елмаеп Габделхәй янына килде.

Габделхәй, менә сиңа... алдым. Кая, бәйлим әле.

Егетнең башына тай типкәндәй булды. Әле кызга, әле аның кулындагы галстугына карап тик торды. Аннан кинәт талпынды да кызны кочаклап алды.

— Синекесе-минекесе юк инде хәзер, Фәтлия, — диде.— Синекесеминекесе юк, — общий! Тагын бер айдан, яме?

— Я, — диде кыз, сизелер-сизелмәс кенә дерелдәп.



Шунда егет ишек ягына текәлеп карый башлады. Кыз да, аның күкрәгеннән башын алып, шул якка карады. Яртылаш ачык калган ишек янында, ак мыегын селкетә-селкетә, урындык аягын иснәштергәләп, чем-кара йонлы сылу песи малае утыра иде.

— Матур бит? — дип сорады егет.

— Мату-ур!

— Ул миңа бүген бәхет китерде. Сине — бәхет кошымны та́бып бирде. Рәхмәт, песи дус! Зур үс!

— Ничек итеп бәхет бирде ул сиңа, Габделхәй?

— Бүгенге хәлләрне бер сөйләрмен әле, Фәтлия.

Алар, сабыйлар шикелле кулга-кул тотынышып, тәрәзә янына килделәр. Урамга карадылар.

— Бүген минем иң бәхетле көнем, — диде егет, — кара, яңгыр да туктаган, көн аязырга итә бит!

— Аяза! — диде кыз, аның сүзен раслап.

*Август, 1967 ел*

• • •

# Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары

## ЖУРНАЛ ТУРЫНДА ФИКЕР АЛЫШУ

Татарстан язучылар союзы идарәсенең чираттагы киңәйтелгән утырышы «Казан утлары» журналының 1967 елгы 7—8—9 нчы саннарында басылып чыккан материаллар турында фикер алышуга багышланды. Әлеге саннарда басылып чыккан материаллар хакында сөйләү өчен, башта сүз язучы **Аяз Гыйләҗевкә** бирелде.

— Мин караган саннарда, — дип башлады ул, — проза әсәрләре өзек-өзек кенә туры килде. Ләкин мин журналның барлык саннарын да укып барам. Минемчә, бу елгы саннарда басылган проза йомшаграк булды. Бу — редакция гаебе түгел, бу — прозаиклар гаебе. Бездә вакыйга булырлык, журналны эзләп алып укырлык әсәрләр булмады быел. Менә күп еллар вәгъдә иткәннән соң, Г. Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» исемле әсәрен укыдык. Шушымы икән аның озак еллар язган әсәре? Без Гомәр агайны әдәбиятыбызның көзгесе итеп тәкъдим итәбез. Инде аның бу әсәрен алып карыйк. Г. Бәшировның бу автобиографик повестенда мин авторның үзен күрмим. Ул чордагы вакыйгалар аңа ничек тәэсир иткән? Боларны мин күрмим. Алыйк «Кунак кызы» бүлеген. Матур, кызыклы гына бүлек ул. Әмма ул кыз башка күренми. Миңа иң тәэсир иткән кеше Фазулла. Ләкин ул да югалып кала. Әсәрдәге бүлекләр — өзек-өзек новеллаларны хәтерләтә. Бу әсәрне бик озынга да сузарга мөмкин. Әсәр аерым новеллалардан гына торса да ярар иде шикелле. Аннары әсәрдә инде әдәбиятта сурәтләнгән вакыйгалар да бар. Әйтик, тегүче турында Ф. Хөсни язган иде инде. Гомәр абзыйдан яхшы әйбер көткәнгәдерме, миндә әсәр канәгатьсезлек хисе калдырды.

Проза әсәрләреннән бу саннарда берничә хикәя дә басылган. Шуларның берсе — Г. Минскийның «Мылтыклы кеше» исемле хикәясе дә ашыгыбрак басылган төсле. Әсәрнең кереш өлеше, минемчә, кирәк түгел. Аның берниндн нагрузкасы юк. Автор партячейка кешеләрен йомшак итеп, надан итеп биргән. Бөек революцион вакыйгалардан соң коммунистлар болай булмый. Тормыш чынлыгы җитеп бетми әсәрдә. Менә болар хикәянең дәрәҗәсен төшерәләр. Хәлбуки, хикәя көчле булырга тиеш булган.

Икенче хикәя — Әмирхан Еникиның сигезенче санда басылган «Мәчет җылый» хикәясе. Дөресен генә әйткәндә, мин бу әсәргә карата фикер әйтергә аптырап торам. Нигә язды икән моны Әмирхан абый дип тә, нигә язмаска тиеш икән дип тә уйлыйм.

Инде А. Расих романына карата берничә сүз. Ул әле басылып бетмәгән, шунлыктан аның турында өзеп кенә фикер әйтүе дә кыен. Әмма басылган кадәресен мин рәхәтлек тойгысы кичереп укыдым.

Ләкин кабатлап әйтәм: проза әсәрләре йомшаграк булды быел. Авылларда йөргәндә укучылар да шул ук фикерне әйттеләр.

Ә менә поэзия өлкәсендә эшләр башкачарак. Алар төрлечә, әйбәт язалар. Р. Фәйзуллин, Гәрәй Рәхим шигырьләре бик ошады. Х. Камаловның «Эскизлар»ы да җылы тәэсир калдырды. Тормышка оптимистларча карау, шуңа өндәү хас бу эскизларда. Бу әсәре Хисамның уңышы. Поэзиянең иң бай бүлеге — 9 сандагы Ш. Галиев шигырьләре. Тематикасы киңәя Шәүкәтнең. Балалар өчен дә, зурлар өчен дә. Шул ук санда Р. Фәйзуллин шигырьләре дә басылган. Уйланып яши торган шагыйрь, шигырьләре әйбәт аның.

Журналда минем эчемне пошыра торган бүлек — очерк бүлеге. Без бу бүлектә үткән көн белән яшибез. М. Хәсәновның Багманов турындагы очеркы бик йомшак. Анда кеше турында уйлану юк. Орден бирелгәннән соң түгел, орден бирелмәгән кешеләрне эзләп табып, орден бирдертерлек әйбәт очерклар язарга кирәк.

Журнал соңгы елларда тематик яктан төрләнде, материаллар тирәнрәк эчтәлекле була башлады. Ләкин шулар арасында йомшаклары да очрый иде. Кумысниковның «Җилкәнсезләр» әсәре турындагы мәкаләсе, мәсәлән, бик сай. Кумысниковныкы кебек үк йомшак мәкаләләр рәтенә мин Н. Фәттахның Р. Батуллин китабы турындагы мәкаләсен дә кертәм. Нурихандa өйрәтергә тырышучанлык сизелә.

Тәнкыйть мәкаләләреннән миңа ошаганы — Н. Юзиевның «Музалар туганлыгы» исемле мәкаләсе.

Бу саннарда Х. Вахитның «Соңгы хат»ы басылган. Әйбәт кенә әсәр ул. Х. Вахит иң эшлекле драматургларыбызның берсе. Әмма Розалия бик үк ошамады миңа. Мин моны авторга да әйткәнем бар...

Аяз Гыйләҗев чыгышыннан соң журналның тикшерүгә куелган саннары хакында фикер алышу башланды.

— Аяз, син Гомәр абый әсәре турында кыю гына фикерләр әйттең, — диде Хәй Вахит. — Минемчә, син бу әсәргә повестька куела торган таләптән чыгып карагансың. Гомәр абыйның бу әсәрендә халкыбызның этнографик детальләрен киң рәвештә сурәтләп калдырырга омтылу, фәнни әсәргә тартымлылык юкмы икән?

**Аяз Гыйләҗев:**

— Алай булгач, ник соң ул этнографик новеллалар язмаган? Ник автобиографик повесть дип куйган? Рас куйган икән, шуңа тартым итеп язсын иде. Үзен язучы иткән вакыйгаларны күрсәтсен иде.

**Нурихан Фәттах:**

— Мин Аяз чыгышына карата берничә сүз әйтмәкче булам. Аның чыгышы уйланып җитмәгән, минемчә.

Мин Гомәр абый әсәренә карата Аяз фикере белән килешмим. Автобиографик әсәрләр төрлечә булырга тиеш, минемчә. Мин бу әсәрнең соңгы өлешләрен көтеп алып укыдым. Бу, минемчә, чын сәнгать әсәре. Автор күренми, ди Аяз. Ә нигә аның күренүе, ни өчен авторлар бер төрле генә булырга тиеш? Аяз һәркемне үзе кебек булырга, үзе кебек язарга чакыра. Алай кирәкми.

Инде минем яшьләр иҗатына булган мөнәсәбәтем турында. Мин Р. Батуллинга күсәк күтәрергә теләмәдем. Робертны кимсетергә уем юк. Ничек уйлыйм — шулай язам. Мин ялганлый, алдаша алмыйм. Яшь шагыйрьләр мәсьәләсендә элекке фикеремдә калам: алар телгә салкын карыйлар. Моның белән килешмим, моңа читтән карап тора алмыйм мин.

Инде әдәби тәнкыйть мәсьәләсе. Мәһдиев белән Госмановның М. Гайнуллин китабы турындагы мәкаләсе бик әйбәт, бик тирән язылган рецензия. Н. Юзиев мәкаләсе дә бик шатлыклы тәэсир калдыра.

**Гөлшат Зәйнашева:**

— Мин журналда басылган эстрада әсәрләре турында әйтмәкче булам. Мин караган саннарда эстрада әсәрләре күп түгел. Катиевнең бер пәрдәлек «Ялкын» исемле драмасы ярыйсы язылган, әмма вакыйгалары тапталган. Кызны үтерергә җыену озынга китә, ышандырмый. Ш. Галиевнең сатира-юмор әсәрләрен мин яратам, әмма бу саннардагы соңгы шигыре бик ошамады. И. Юзеев белән М. Яруллин җыры урта кул җыр... Җыйнап әйткәндә шул: эстрада әсәрләрен күбрәк биреп барасы иде.

Мин докладчыга карата Н. Фәттах әйткән фикер белән килешмим. Аяз, минемчә, уйлап сөйләде. Әмма Бәширов әсәрен үзем яратып укыдым.

**Атилла Расих:**

— Мәнә мин нәрсә әйтмәкче булам. А. Гыйләҗев доклады миңа ошады. Эш шунда, ул бәхәсләр кузгатты. Рас бәхәс кузгалган икән, димәк, бу инде әйбәт. Аязның проза турындагы фикерләренә күз ташласак, бәхәсләшергә дә урын бар. Ул телгә алган хикәяләр йомшак иде. Моңысы белән килешәм. Әмма Гомәр агай әсәре турында фикере белән килешеп бетмим. Гомәр агайның бу әсәре «Намус»тан көчлерәк дияр идем мин. «Намус»тагы схематизм юк монда. Бервакыт Ф. Хөсни, Гомәр абыйның бу әсәре энциклопедия, дип әйтте. Мин дә шул фикердә, теле гаҗәп әйбәт. Бу әсәрнең теле яшьләр өчен гыйбрәтле. Инде әсәрнең жанрына килгәндә, минемчә, ул автобиографик повесть.

Г. Минский әсәренә карата: ул бу әсәрен ашыгыбрак язган шикелле. Әдәбиятчылык сизелеп тора аннан. Бу саннарда Ф. Хөснинең «Бар иде Балтачта бер этәч» исемле хикәясе бар. Без Балтачта бергә булдык. Ул әтәчне бергә күрдек. Йомшак аның бу әсәре.

**Барлас Камалов:**

— Докладчының зур таләпләр куеп сүз башлавы файдага булды. Инде Г. Бәширов әсәре турында. Тел ягыннан, халыкның рухи байлыгын бирү ягыннан, образлар ягыннан, чыннан да, әсәргә сүз әйтеп булмый. Әмма докладчының бер фикере белән килешми булмый. Укыган өлешеннән язучының үзе күренә башлавын көткән идем мин. Бәлки, киләчәктә моны күрербез. «Минем тәрәзәләрем», «Малайлыкта кунакта»лар белән урын алыр бу әсәр. Шулай да әсәрдә Гомәр абыйның үзен күрәсе килә. Ә Балтач әтәче турындагы хикәя Фатих абый язганга басылган әсәр ул. Шаккатарлык түгел. А. Расихның «Ямашев» романы турында сүз йөртергә әле иртә. Газетада басылган өзекләре шиккә төшерә иде. Ә менә журналда укый башлагач, әсәр әйбәт укыла. Аның турында соңыннан сүз булыр әле.

Инде очерклар турында. Язмыйбыз бит очеркларны! Олылар зур әсәрләр яза. Ә яшьләр, күрәсең, җитәрлек язмый. «Эш сөйгәнне ил сөя» дигән очерк бик йомшак.

Иҗат портретлары. С. Сафуанов И. Газиның портретын язганда Гази абыйны Гази иткән моментларны ачып җиткерә алмаган. Олылар турында иҗат портретлары языла. Бу әйбәт. Әмма урта һәм яшьрәк буын язучыларга да портретлар бирү кирәк иде. Журнал моны да истә тотсын иде.

**Габдрахман Минский:**

— Тәнкыйть яратмаудан түгел, әмма бүген хикәягә карата әйтелгән фикерләр белән килешә алмыйм. Менә монда әдәбиятчылык дигән сүз булды минем әсәр турында. Бу бик зур гаеп, иптәшләр. Синең коммунистларың надан дисең, Аяз, ә ул чакта чыннан да шулай иде бит. Әсәрдәге дүрт коммунистның берсе дә яхшылап укый белмәве гаҗәп тоелган сиңа. Ә бит ул заманда эшчеләр шулай иде. Тормыш дереслеге җитми әсәргә диләр. Тормыш дөреслеге юк дип әйтә алмыйм мин. Докладчының фикере мине ышандырмады.

**Флүн Мусин:**

— Тәнкыйть мәкаләләре «тәнкыйть» дигән дәрәҗәсен аклый башлады. Г. Халит, Н. Юзиев мәкаләләре бөтенсоюз дискуссиясендә катнашырлык дәрәҗәдә эшләнгән. Бигрәк тә Г. Халит мәкаләсе әһәмиятле. Мондый әйберләр күбрәк кирәк. Дискуссияләр оештырырга кирәк иде. Икенче мәсьәлә: язучы һәм тормыш дигән темага журналда

материаллар бирелми. Язучыларның тормыш турындагы материаллары баҫылсын иде. Ф. Хөснинең Балтачка баргач әтәч кенә күреп кайтуы гаҗәп мина.

Аннары журналның җаваплы редакторы **Рафаэль Мостафин** сүз алды:

— Бүгенге утырышта, — диде ул, — төп ике фикер әйтелде. Иптәшләр дөрес әйтә: проза әсәрләребез йомшаграк булды быел. Моның белән килешәм. Бүгенге тормыштан ераграк ул әсәрләр. Очерк һәм публицистика мәсьәләсендә дә эшләребез шәптән түгел. Без моны беләбез. Күрәсең, бу мәсьәләгә тирәнрәк игътибар итү кирәктер.

## АКТАНЫШТА ӘДӘБИЯТ АТНАЛЫГЫ

Узган елның октябрь аенда Актаныш районы авылларында татар әдәбияты атналыгы үткәрелде. Ашлык тапшыру буенча республикабызда беренче урынны яулап алган Актаныш хезмәт ияләренең уңыш бәйрәме көннәрендә үткәрелгән ул атналыкта язучылардан Габдрахман Минский, Илдар Юзеев, Хәсән Сарьян, Гөлшат Зәйнашева, Марс Шабаев һәм «Казан утлары» журналының әдәби сотрудникгы Вакыйф Нуруллин катнашты. Алар районның «Радио», Шәймәрдәнов исемендәге, «Авангард» һәм «Октябрьның 12 еллыгы» исемле колхоз клубларында колхозчылар белән, Теләкәй (сигезьеллык), Байсар (унъеллык), Чуракай (унъеллык) һәм Сәфәр сигезьеллык мәктәпләре укучылары белән әдәби кичәләр һәм очрашулар үткәрделәр. Үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар, иҗатлары һәм, гомумән, татар әдәбияты турында сөйләделәр. В. Нуруллин очрашуга килгән кешеләргә «Казан утлары» журналында 1968 елда басылачак әсәрләр турында да сөйләде. Язучыларны үзләре булган һәр авылда бик якын күреп каршы алдылар. Әдипләр чыгышыннан соң колхозчылар үзләре дә сүз алып сөйләделәр, «Казан утлары» журналында басылган әсәрләргә карата фикерләрен әйттеләр.

Атналык көннәрендә Сәфәр авылы клубында Габдрахман Минскийның «Яшенле яңгыр» повесте буенча укучылар конференциясе дә үткәрелде.

## ОЧРАШУЛАР, КОНФЕРЕНЦИЯЛӘР

«Казан утлары» журналы сотрудникгы, язучы Малик Хәмитов Кукмара районында булып кайтты. Ул район радиоузелы буенча журналның эшчәнлеге һәм татар әдәбиятының бүгенге торышы турында сөйләде.

Зур Сәрдек урта мәктәбендә «Казан утлары» журналы буенча укучылар конференциясе үткәрелде. Журнал һәм татар язучыларының хәзерге иҗат эшчәнлекләре турында М. Хәмитов чыгышыннан соң, бербер артлы, югары класс укучылары, укытучылар сүз алдылар. Хафизов, Әхмәтшин, Хәбибуллина, Фәйзрахманов журналда үзләре яратып укыган әсәрләр турында сөйләделәр, соңгы елларда редакциянең яшь һәм башлап язучылар иҗатына игътибары көчәюен билгеләп үттеләр. Укытучы Г. Каюмова тәнкыйть әсәрләрендә объективлыкны яклады. Аннары журналда авыл сәхнәләре өчен зуррак күләмле әсәрләрнең сирәк басылуын әйтте.

— Мин журналны егерме елга якын даими алдырам, — диде укытучы-агроном М. Нуриев. — Элекке елларда ул күбрәк әдәбиятчылар өчен чыга торган журнал кебегрәк тәэсир калдыра, анда киң катлау укучыларның таләпләре житәрлек искә алынмый иде. Соңгы елларда журнал тормышка да, укучыларга да шактый якынайды. Күп төрле тематикага багышланган очерклар, документаль әсәрләр моның ачык мисалы. Мемуарларга киң урын бирелү дә уңай күренеш. Аларны укучылар яратып, кызыксынып укыйлар, чөнки мондый материаллар белемне, дөньяга карашны киңәйтә.

Шулай ук кайбер теләкләр дә белдерәсе килә. Журналда маҗара жанрына, фәнни фантастикага аз урын бирелә, гомумән, татар әдәбиятында бу жанр белән язучылар бик аз кызыксына. Галимә Каюмова бик дөрес әйтте: авыл сәхнәләре өчен күп пәрдәле пьесалар бик кирәк. Хәзер колхозлар бүгенге барлык таләпләргә җавап бирерлек зур-зур клублар, культура сарайлары салалар. Аларда сәхнә мөмкинлекләре шәһәр клубларыннан ким түгел. Үзешчән түгәрәкләргә катнашучы һәвәскәрләр дә шактый. Аларны хәзер бер пәрдәлек әсәрләр генә канәгатьләндерми.

Авыл укытучысы турында әсәрләр татар әдәбиятында бөтенләй юк диярлек. Авыл укытучысы — ул тәрбияче генә түгел. Аңарга вакыты белән сыер да саварга, йомырка да жыярга, артист та буларга, иген дә игәргә, балта остасы буларга да туры килә. Аның хезмәте, тормышы, омтылышлары әдәби әсәрләрдә дә үзенә урын алсын иде...

Аннары иптәш Нуриев журналда басылган кайбер әсәрләргә карата үзенең тәнкыйть фикерләре белән уртаклашты, Ф. Хөснинең «Яз галәмәте» хикәясен ул «максатсыз язылган әсәр» дип бәяләде.

## КЫЗЫКЛЫ ОЧРАШУЛАР КЛУБЫ

Узган елның октябрь аеннан «Казан утлары» журналы редакциясе каршында «Кызыклы очрашулар клубы» эшли башлады. Клубның беренче утырышы Казан финанс-экономика институтының өлкән укытучысы Нияз Хәкимуллин белән очрашуга багышланды.

Нияз Хәкимуллин — разрядлы альпинист һәм сәяхәтче. Ул Европа тирәли сәяхәттә катнашкан, дөньяның бик күп илләрендә булып кайткан кеше. «Мин юлда йөреп үткәргән көннәрнең барысы, — ди ул, — өч елга якын».

Нияз Хәкимуллин шул ук вакытта бик оста фотограф һәм әйбәт журналист та. Киноаппараты да бар һәм аның белән дә яхшы эш итә. Н. Хәкимуллин «Казан утлары» укучыларына «Европа тирәли сәяхәт» һәм «Фотообъективта — Непал» исемле фотоочерклары белән таныш. Ә бу сан-

да аның «Һиндстанга сәяхәт» исемле фотоочеркы урнаштырылды.

Журнал редакциясе хезмәткәрләре, редколлегия членнары һәм язучылар белән уздырылган әлеге очрашу кичәсендә Нияз Хәкимуллин башта үзенең нинди илләрдә булып кайтуы, кайсы альпинистик экспедицияләрдә катнашуы турында сөйләде. Аннары төрле илләрдә төшереп алып кайткан бик күп фоторәсемнәрен проекцион фонарь белән күрсәтеп, һәркайсына аңлатма биреп барды. Очрашуга килгән кешеләрнең сорауларына җаваплар бирде. Җыеп кына әйткәндә, «Кызыклы очрашулар клубы»ның беренче кичәсе бик кызыклы үтте, анда катнашкан кешеләрдә әйбәт тәэсир калдырды.

Нияз Хәкимуллин бу ел үзенең өч иптәше белән Камчаткага барып, андагы искиткеч вулканнар иленә сәяхәт ясап кайтты. Хәзер ул шул сәяхәте турында журнал өчен фотоочерк әзерли.

* * *



Клубның икенче утырышы да үткәрелде инде. Ноябрь аенда үткәрелгән ул утырышта филология фәннәре докторлары Хатип Госман һәм Мөхәммәт Гайнуллин, филология фәннәре кандидаты Резеда Ганиева үзләренең Финляндиядә булып кайткан вакытта алган тәэсирләре белән уртаклаштылар. Фин халкының тормышы, көнкүреше, Хельсинки университеты һәм фин галимнәре хакында сөйләделәр. Финляндиядә төрле вакытларда һәм төрле язмыш аркасында урнашып калган меңгә якын татарлар да яши икән. Галимнәребез аларның тормышы хакында да сөйләделәр. Хельсинки университеты китапханәсендә безнең китапханәләрдә булмаган байтак кына китаплар булуын һәм алардан файдаланырга мөмкин икәнлеген дә әйттеләр.

* * *

Октябрь аенда шагыйрьләр секциясенең чираттагы утырышында шагыйрь Сибгат Хәкимнең яңа шигырьләре укып тикшерелде. Фикер алышуда катнашучы Ф. Хөсни, З. Нури, Г. Ахунов, Ш. Галиев, Ә. Юныс, Х. Вахит, И. Юзеев һ. б. иптәшләр гражданлык пафосы белән сугарылган, Германиягә барып кайтканнан соңгы тәэсир белән язылган бу яңа шигырьләрне шагыйрь иҗатында яңа бер баскыч дип бәяләделәр.

## БАТЫРЛАР ИСТӘЛЕГЕНӘ

Октябрь революциясенә 50 ел тулган көннәрдә Совет власте өчен көрәштә корбан булган кешеләр истәлегенә Казан шәһәренең Горький исемендәге культура һәм ял паркында кырык метр биеклегендәге обелисктан һәм аның янына куелган батыр көрәшче образын гәүдәләндерүче кеше сыныннан гыйбарәт булган мәһабәт һәйкәл ачылды. Һәйкәл янына мәңгелек ут кабызылды. Рәсемдә: һәйкәлнең гомуми күренеше.

Җаваплы редакторы **Рафаэль Мостафин**
Редколлегия: **Хәй Вахит, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники, Гази Кашшаф, Шәйхи Маннур, Габдрахман Минский, Сибгат Хәким, Нил Юзиев**

Производствога бирелде 15/XI-1967 ел. Басарга кул куелды 27/XII-1967 ел. ПФ 09054. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 10(14). Тираж 63746 экз. Заказ М-1844. Бәясе 40 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казань, Бауман урамы, йорт 19. 1968 ел.

# КАЗАН КЫЗЫ

**А. Ключарев** музыкасы
**Н. Арсланов** сүзләре

*Узган ел журналыбызның 2 санында яңа җырларга ябык конкурс игълан ителү турында язылган иде. Конкурс нәтиҗәсендә «Сезне яратам» җыры (Р. Яхин музыкасы, Н. Арсланов сүзләре) икенче бүләк, «Казан кызы» (А. Ключарев музыкасы, Н. Арсланов сүзләре), «Илең турында уйла» (Ж. Фәйзи музыкасы, Г. Зәйнашева сүзләре) һәм «Татарстан таңнары» җырлары (Ш. Капкаев музыкасы, Г. Афзал сүзләре) өченче бүләк алдылар.*

*Түбәндә без шул җырлардан берсен урнаштырабыз.*




Казан кызы, сылуым, иркәм,
Иделдәге акчарлак.
Уйнап очкан акчарлактай
Син барасың уйнаклап,
Җилфердәп, вак-вак атлап.

Атлыйсың тиз-тиз генә,
Аякларың тиз генә,
Укчаларең без генә лә,
Тимәс минем күз генә...
Үзәкләрем өзелә лә,
Әйтсәнә бер сүз генә.

Үзе чая, үзе тыйнак —
Бер сүз әйтсәң кызара...
Кемнәр генә гашыйк түгел
Безнең матур кызларга,
Синең кебек кызларга!

Атлыйсың тиз-тиз генә,
Аякларың тиз генә,
Укчаларең без генә лә,
Тимәс минем күз генә...
Үзәкләрем өзелә лә,
Әйтсәнә бер сүз генә.

Чибәрләр күп безнең илдә,
Әгәр санап карасаң...
Мин шулай да татар кызын —
Казан кызын яратам,
Иркәм, сине яратам.

Атлыйсың тиз-тиз генә,
Аякларың тиз генә,
Укчаларең без генә лә,
Тимәс минем күз генә...
Үзәкләрем өзелә лә,
Әйтсәнә бер сүз генә.

Бәясе 40 тиен
Цена 40 коп.

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

# Казан утлары

(ОГНИ КАЗАНИ)

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210